ИНДУС ТАНИРОВ

БӘЙСЕЗЛЕК БАСКЫЧ-ЛАРЫ

«Парламент демократиясе» сериясеннән

ИНДУС ТАҺИРОВ

БӘЙСЕЗЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1994

ББК 63.3Тат.
Т28

Таһиров И. Р.

Т28 Бәйсезлек баскычлары / Суверенлык турында уйланулар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.— 279 бит.
ISBN 5—298—00446—6

Китапка тарихчы-академик, җәмәгать эшлеклесе һәм публицист И. Таһировның соңгы елларда язылган мәкаләләре, уйланулары тупланды. «Татар милләтендә яшәү көче бармы?», «Керәшчеләребезне искә төшерик!», «Бәйсезлеккә ничек ирешергә?» дип аталган өч бүлектә автор милләтебезгә хас төп сыйфатлар, татарның нинди милләт булуы, тарихи язмышлары хакында фикер йөртә. Шулай ук күренекле шәхесләребез — Садри Максуди, Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Мирсәет Солтангалиевләр эшчәнлеген күздән кичерә. Ахыргы бүлектә ул Татарстанның суверенлык юлында үткән этапларын барлап чыга, Татарстан — Россия сөйләшүләрен алып баручы дәүләт делегациясенең даими әгъзасы буларак, әлеге процессның яктыртылмаган якларын ачып сала.

Т $\frac{5030209000-012}{М132(03)-94}$ **168—94** **ББК 63.3Тат.**

ISBN 5—298—00446—6

© Татарстан китап нәшрияты, 1994

КЕРЕШ СҮЗ

Хөрмәтле укучым!

Кулыңа алган китапка минем соңгы вакытта язылган мәкаләләрем, чыгышларым-уйлануларым тупланды. Аларны җыеп бер китап итеп бастырып чыгару тәкъдиме миңа төрле яклардан килә торды. Язмаларның күбесе матбугат битләрендә басылган булуга һәм газеталарның җәмгыять тормышында искиткеч зур роль уйнавына да карамастан, аларның кыска гомерле икәнлеген дә онытырга ярамый. Шунлыктан минем күп мәкаләләрем киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм түгелдер дип уйлыйм.

Газета һәм журналларда басылып чыккан язмаларымның төп идеясе — татар халкының бәйсезлеккә хаклы булуын исбат итү һәм шул бәйсезлеккә ирешүнең кайбер юлларын эзләү, ачыклау булып кала.

Бәйсезлеккә ирешү өчен иң элек татарның үз хәлен-халәтен белүе зарур. Ул бүгенге көндә нинди? Аның яшәү көче сакланганмы? Шушы сорауларга җавап йөзеннән китапның беренче өлешенә әлеге проблемаларга багышланган мәкаләләр керде. Минем фикеремчә, милләтебез никадәр авыр язмышка дучар булуына да карамастан, үзенең төп сыйфатларын саклап кала алган. Дөрес, аның холкына бик күп үзгәрешләр дә кергән. Аларның кайберләре халкыбызга яңадан билен турайтырга нык комачаулый. Тик шулай да гүзәл сыйфатлары өстенлек ала. Алар бездә милләтебезнең киләчәгенә өмет тудыра.

Шул ук вакытта татарның беркайчан да азатлык идеясеннән баш тартмаганлыгын да истән чыгармыйк. Аның арасыннан һәр дәвердә төрле каһарманнар үсеп чыга торган. Аларны халыкка бәян итү үзе бер мөстәкыйль бурыч. Шуңа күрә китабымның икенче

өлеше кайбер милләтпәрвәр шәхесләрнең эшчәнлегенә багышланган.

Бу очракта мин милләтебез каһарманнарга бик бай булганлыктан чыгып эш итәм. Шушы уңайдан 1911 елны жандармнар төзегән 28 кешелек панисламистлар исемлеген искә төшереп үтәсем килә. Ул мәшһүр Рәшит казый Ибраһимов фамилиясе белән ачыла. Икенче булып исемлеккә аның улы Мөнир язылган. Киләчәктә бу исемлек тулысы белән тасвирланырга тиеш дип уйларга кирәк. Безнең тагын әллә кемнәребез бар! Аларның исеме, эшчәнлеге шулай ук халыкка мәгълүм булырга тиештер. Мин исә милли каһарманнарның кайберләрен генә тасвирлауны үземә бурыч итеп куйдым.

Әйтергә кирәк, бу шәхесләрнең язмышлары төрлечә. Алай гына да түгел, аларның кайберләре бер-берсенә карата капма-каршы позициядә торган. Муса Бигиев белән Садри Максудига Мирсәет Солтангалиев һәрвакыт диярлек каршы булган. Муса Бигиев белән Садри Максуди да кочаклашып кына йөрмәгәннәр. Тик шулай да бу шәхесләр арасында уртаклык бар. Ул да булса милләт өчен, аның киләчәге өчен җаннарын-тәннәрен кызганмау. Тик менә милләтебезнең киләчәген аларның һәрберсе үзенчә күргән, аңлаган. Шунлыктан алар бердәмлеккә ирешә алмаганнар.

Бөек шәхесләребездән Гаяз Исхакый белән Галимҗан Баруди да бер-берсенә шулай ук охшамаган. Бу китапта аларга да урын бирелде.

Без бу кешеләрнең берсен дә даһига әверелдерергә тиеш түгелбез. Чын даһилык ул Аллаһы тәгаләнең үзендә генә. Кешеләр исә һәрвакыт ялгыша, һәрвакыт зур һәм кечкенә хаталар җибәрә. Китабым геройлары да шулай ук идеалдан ерак торалар. Тик шулай да аларның тарихтагы рольләре шактый зур. Аларның төп хаталары — милли бердәмлекне булдыруны вакытында аңламау. Иң көчле һәм йогынтылы вакытында Мирсәет Солтангалиев большевистик позициядә торган, сыйнфыйлык принципларын яклап чыккан. Азатлык өчен көрәш алып бара торган милләт исә, сыйнфыйлык һәм башка шуның ише халыкны бүлгәли торган нәрсәләрне читкә алып ташлап, берләшү юлына басарга тиеш икәнлеген ул тәмам алданганлыгын күргәч кенә аңлаган.

Шуңа күрә милли бердәмлекнең җиңүнең төп шарты икәнлеген безгә васыять итеп калдырган. Шушы васыять Азия һәм Африка илләрендәге азатлык сукмагына баскан халыкларга иртәрәк барып ирешкән. Алар Солтангалиев мирасын яхшылап өйрәнгәннәр, аны үзләренең рухи остазы, идеологы итеп таныганнар. Солтангалиевнең бөеклеге менә шуннан гыйбарәт.

Гомумән XX гасыр башындагы милли каһарманнарыбыз Россия сәяси күгендәге партияләрнең эшчәнлеге белән кирәгеннән артык мавыкканнар. Шул ук Садри Максуди да кадетларга бик якын була, аларның эшчәнлеген идеаллаштырудан да ерак тормый. Әмма ләкин безнең татарда башкачарак фикер йөрткән кешеләр дә барын искә алмасак, бу һич тә дөрес булмас иде. Шуларның берсе — Җамал Вәлиди. Бу кеше татарлар бернинди сәяси көчләргә дә ышанмастан, тик үз-үзләренә генә ышанып хәрәкәт итәргә тиешләр дигән. Мәшһүр Фуат Туктаров исә татарларны, сыйнфый принципларны читкә алып ташлап, бер өстәл артына утырырга өндәп килгән. Ни эшлисең бит, ул вакытта мондый кешеләрнең сүзләренә колак салынмаган. Ә менә бүген исә тиешле нәтиҗәләр ясар вакыт җитте. Дөрес, бу ике зирәк әһелгә багышланган очерклар бу китапта юк. Ләкин минем һәр язмамда аларның алга сөргән төп идеяләре, ягъни милли бердәмлек идеясе ята.

Шул сәбәпле китапның өченче өлешенә кергән мәкаләләр бүгенге сәясәткә багышланган. Китапның авторы 1990 елның 30 августында кабул ителгән Татарстанның дәүләт суверенлыгы декларациясенең текстын әзерләүдә катнашты, Россия делегациясе белән икеяклы килешү төзү буенча 1991—1993 еллардагы сөйләшүләрдә Татарстан делегациясенең җитәкчесе урынбасары булարак эш алып барды. Шуңа күрә бу өлешкә кергән язмалар теоретик эзләнүләр яки практик тәкъдимнәрдән генә тормый. Монда авторның төп позициясе, яки аның иманы чагылган. Шунлыктан аларга эмоциональлек хас.

Тик шулай да бер нәрсәне ачыклап үтү кирәк, мин беркайчан да реальлек принцибыннан читкә тайпылмадым кебек. Бәйсезлеккә ирешүнең төп шартларын һәм ысулларын билгеләүгә үземнән практик өлеш кертергә тырыштым. Гомумән, бу китап үзе дә шул

максатны тормышка ашыру йөзеннән барлыкка килде. Укучыларым аңа үткән тарих итеп кенә карамасыннар иде. Минемчә, анда бүгенгә катлаулы чынбарлык чагылган.

Шулай да бу китапка тупланган мәкаләләрне укучылар нинди дә булса акыл өйрәтү дип кабул итмәсеннәр иде. Андый дәгъвам юк. Шуны гына теләр идем: әгәр дә язганнарым кемнәрнедер уйландыра, җаннарына рухи азык бирә, көрәшебезгә күпмедер өлеш кертә икән, шуннан башка миңа берни дә кирәкми.

Автор

ТАТАР МИЛЛӘТЕНДӘ ЯШӘҮ КӨЧЕ БАРМЫ?

ТАТАР НИНДИ МИЛЛӘТ?

Бу сорауга бүгенге көнгә кадәр әле берәүнең дә җавап бирә алганы юк. Мин дә моны үз өстемә алмыйм. Шулай да бер-ике фикер әйтеп китмәкче булам. Тарихчы буларак, тарихи фактларга таянып эш итүне дөресрәк булыр дип саныйм.

«Аң» журналының 1913 елгы 21 санында «Милләтне ничек аңлыйсыз?» исемле баш белән мәкалә бастырып чыгарып, дискуссия ачып җибәрелә. Дискуссиягә катнашучылар алдына 16 сорау куела. Анда укучылардан «милләт» төшенчәсенә фәнни бәя бирү, «вөждан»ны ничек аңлаулары хакында сорала. Милләт һәм дин, милләт һәм ватан төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләре ничек булырга тиешлегенә дә игътибар ителә. Шул ук вакытта халыкның тарихы, киләчәге, милли мәктәп һәм әдәбият та читтә калмыйлар. Төрек, татар, мөселман төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләрен яктыртуга да зур урын бирелә.

«Аң» гына түгел, бигрәк тә «Шура» журналы, шушы мәсьәләләргә бик күп урын биреп, милләт оешуның теория һәм практикасы хакында шактый зур мәгълүмат туплый алды. Революциягә кадәр чыккан татар газеталары милләт мәсьәләсен читләтеп үтмиләр. Бу фактлар татар милләтенең үзаңы шактый югары торганлыгын исбатлый.

Әгәр дә теге яки бу халык үзенең кем икәнлеген аңларга тырыша, дөнья халыклары арасында үз урынын билгеләргә омтыла, шул халыклар арасыннан үзенең туганнарын сайлап алырга тели икән, димәк, ул инде милләт булып өлгерүнең югары баскычында тора.

Татар милләтенең өлгергәнлек баскычларына басуын конкрет тасвирлауга кадәр милләт төшенчәсенә тукталып үтәсем килә. Чөнки бу төшенчәгә карата фәндә нинди дә булса уртак караш юк. Билгеле булганча, милләтне экономик бердәмлек, җир-территория бердәмлеге һәм психик тамырлар бердәмлеге дип карый килделәр. Милләтне шулай аңлауның авторы Сталин санала. Күрәсең, мондый карашка Ленин да каршы булмагандыр, чөнки ул Сталин урнаштырган кануннарга каршы бер генә сүз дә әйтмәгән.

Ә бит Сталин милләткә мондый карашны күктән алмаган. Ул аны австрияле социал-демократ Отто Бауэрны тәнкыйтьләү юлында тапкан. Бауэр милләтне тик мәдәни бердәмлек дип кенә саный. Шул мәдәни бердәмлек астында килеп чыгыш, кан-кардәшлек бердәмлеге, уртак психик кичереш бердәмлекләре ята. Тарихи язмыш уртаклыгы да шушыңа керә. Чөнки бер кандагы кешеләр уртак тарихи юл үтү дәверендә уртак психик кичерешләргә, уртак телгә, уртак җиргә ия булалар.

Сталин исә боларның һәммәсен дә икенчел дип күрсәтмәкче була. Аның фикеренчә, экономик бердәмлек беренчел. Аннан соң шушы ук рәттән территория бердәмлеге, тел бердәмлекләре бара.

Ләкин хакыйкать моның дөрес түгеллеген күрсәтә. Аңа тик күз генә йоммаска кирәк. Яһүд, әрмәннәрнең экономик тормыш бердәмлеге дә юк, инде аларның күбесе күп гасырлар буена үз ватаннарында да яшәми. Шулай булуларына да карамастан, алар үзләрен бер милләт итеп хис итәләр. Бер тамырдан чыккан-

лыкны нык тоеп, уртак язмыш белән яшәп, бер төрле хисләр кичереп, охшаш тойгылар дөньясында яшәүне аңлау — милләт булып өлгерүнең ачык бер күренеше дип карарга кирәктер. Әлбәттә, бу шулай ук тел берлеген дә таләп итә. Телнең, чыннан да, үзара аңлашу, аралашу чарасы булуына китерә.

Моның бергә яшәгәндә генә булганлыгын исбат итеп торуның кирәге юктыр. Чөнки туфрак бердәмлеге бу процессның төп нигезе.

Тарихи аң исә этносның милләт булып оешу юлында барлыкка килә. Кичәге көнне бүген искә алу шул аңның нигезе. Үткәндәге күренекле вакыйганы язусызу барлыкка килгәнче үк еллар, гасырлар буе искә төшерәләр. Шул вакыйга, яки шуңа охшашлы күп вакыйгалар этносның тарихи аңына нигез сала. Тарихи аң никадәр тирән, никадәр тотрыклы булса, этнос шул кадәр милләт булып оешуга якын тора. Тарихи аңның үсешенә язма тарих зур ярдәм күрсәтә. Чөнки ул, үткәннәрне системага салып, аны халык мирасына әверелдерә. Мирас исә инде тик уртак кына була ала. Монда шушы уртаклык турында да бер-ике сүз әйтеп китү урынлы булыр дип уйлыйм.

Тугандаш халыкларның уртак мирасы, аларның бергә гомер кичергән чорларына туры килеп, аларның туганлыкларын билгели. Бу очракта гомумтөрки мирас булуын әйтеп үтү кирәк. Бу мираска барлык төрки халыклар да тигез мөнәсәбәттә. Ул бүленергә мөмкин түгел, чөнки ул тарихи кан-кардәшлегеннән ваз кичү булыр иде. Бу мирасны һәммә төрки халыклар да бертигез хокукта сакларга тиеш. Ул бүгенге туганлыкның да нигезе. Әгәр дә инде халыклар шул уртак мирасны бүлә башласа, туганлык дошманлыкка әверелә.

Берничә төрки халыкның уртак мирасы булырга мөмкин. Бу халыклар, кагыйдә буларак, чыгышлары белән бер-берсенә бигрәк тә якын булалар. Әйтик,

казакъ белән кыргыз, азәрбайҗан белән төрекләр, татар белән башкорт әнә шундый якынлыкта торалар. Шунлыктан аларның уртак һәм бүленмәс мираслары бар. Ул мирасны бүлә башлау шулай ук дошманлыкка гына китерәчәк. Уртак мирас булу бу халыкларның борынгы бабалары якын туганлыкта булган, бер йортта туып, бер йортта үскән, дигән сүз.

Ә менә инде милләт булып оешканнан соң һәр халыкның үзенә генә хас аерым мирасы барлыкка килә. Бу аның өлгереп җиткәнлеген күрсәтә. Ул тик үзенә генә хас сыйфатларга ия була. Алар арасында төрлесе булырга мөмкин — яхшысы да, яманы да. Әйтик, 1552 елдан бирле коллыкта яшәү татарда коллык сыйфатлары да китереп чыгара. Монысын да инкяр итеп булмый. Ләкин бу аның үз тарихы, үз язмышы салган сырлар. Мәшһүр миссионер Ильминский татарларда шул коллык сыйфатларын булдыруны, үстерүне үзенең төп бурычы итеп санаган. «Алар,— дип язган ул,— үзләрен хаким халыктай хис итәләр, үткән тарихлары белән горурланалар». Ләкин, кемнең нинди этлек кылырга тырышуына да карамастан, татарда азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылу, гомумән, дәүләтчелек сыйфатларының генетик бер кодка әверелгән булганын күрәсең. Ә моны инде аның үзен юк итеп кенә бетереп була. Әйтеп үткән сыйфатлар үзләрен бер милләт итеп хис итеп яшәүчеләрнең бабалары бер җирдә, бер ата-анадан туып, бер кичерешләр белән, бер язмышка буйсынып яшәүне, тел, лөгать, гореф-гадәтләре бер булуны шарт итеп куя.

Шундый бабалардан туган балалар исә дөньяның төрле җирләренә таралып яшәргә дә мөмкин. Кайда яшәүләренә дә карамастан, алар үзләрен бер милләт итеп тоя. Идел буйларын моннан алты йөз ел элек ташлап киткән татарлар бүген Польшада, Литвада, Белорусьта яшиләр. Саннары кими барганга да карамастан, алар үзләрен татар уллары һәм кызлары итеп

хис итәләр. Татарстанны үзләренең тарихи ватаннары итеп таныйлар. Аларга үз-үзен саклау инстинкты искиткеч нык сеңгән.

Бу урында дин хакында да бер-ике фикер әйтеп үтү кирәктер. Чөнки чәчелгән татарларны татар итеп дин саклаган. Моңарчы динне милләт оешуда, аны саклап калуда хисапка алмыйлар иде. Ә кайчак аны турыдан-туры тискәре фактор рәвешендә күрсәтә килделәр. Бу, әлбәттә, дөрес түгел. Беренчедән, дин этносны милләт итеп оештыруда берләштерү факторы булса, икенчедән, ул аның теленә, гореф-гадәтенә зур, әйтергә мөмкин, хәлиткеч йогынты ясый. Ислам дине исә дистәләрчә ислам милләте барлыкка килүгә сәбәп була. Татарлар да ислам милләте булып оеша. Дин милләтнең үз-үзен саклау инстинктының бер мөһим факторы итеп каралырга тиеш.

Диннең халык мәдәниятен үстерүгә ясаган уңай йогынтысын әйтми үтү шулай ук тарихи гаделлеккә туры килмәс иде. Татар авылларында, шәһәрләрдә һәрбер мәчет каршысында мәдрәсә булган. Анда балаларны дингә генә түгел, уку-язуга да өйрәтәләр, дөньяви белем бирәләр. Мәчетләр, гомумән, мөселман дине татарларның иң алдынгы ислам милләте булып өлгерүенә сәбәп була. Пушкин заманында Казанда яшәгән мәшһүр немец галиме К. Фуксның татарларның үз араларында укый-яза белмәүне хурлык итеп санаганнарын әйтеп үтүен искә алыйк.

Ислам дине татарларга әхлакый яктан үсү өчен зур этәргеч була. Гомум чисталык, пөхтәлек татарларны башка халыклардан аерып тора. М. Горький да, шушы чисталыкка, әхлакый матурлыкка исе китеп, Болак артындагы татарлар искиткеч чиста тормыш белән яшиләр, дип күрсәтә.

Ислам дине татарларны аерым милләт итеп саклауда зур роль уйнаган. «Аң» журналында бервакыт шушы турыда махсус мәкалә дә басылып чыга. Анда

әгәр дә ислам дине, Чынгыз заманында ук ныгып, Алтын Урдада дәүләт диненә әверелә алган булса, бәлки, ул дәүләт юкка да чыкмаган булыр иде, диеләә. Ләкин Казан ханлыгы руслар кулына күчкән чорларда дин инде халык тормышына нык кереп урнашкан була. Халыкка шушы авыр заманнарда иманыр көч бирә, руслар белән кушылуга комачаулык тудыра. Бу фикерне дөрес дип танымыйча булмый.

Билгеле ки, ислам диненең универсальлегеннән чыгып, гомум ислам милләте булырга тиеш диючеләр дә булган. Бу очракта без кавказлы Әхмәт бәк Цаликовны искә алырга тиешбез. 1917 елда 1 Бөтендөнья мөселман съездында ясаган докладында ул ислам милләте тәгълиматын алга сөреп карый. Ләкин бу барып чыкмый. Тарихи хакыйкать ислам милләте юклыгын һәм беркайчан да була алмаячагын күрсәтте. Ислам милләте түгел, ислам милләтләре бүгенге дөньяда күпләп яшиләр.

Татар милләтенең тарихы әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Хәтта әле аның этносы да тиешле рәвештә билгеләнмәгән. Берәүләр татарларны борынгы болгарга бәйләп, аны бүген «болгар» итеп игълан итүгә кадәр барып җитә. Икенчеләр исә татарларны тик Алтын Урдага гына бәйләмәкче һәм шунлыктан аны килмешәк халык итеп күрсәтмәкче була.

Мондый тайпылышларның үз сәбәпләре бар, әлбәттә. Ләкин алар икесе дә берьяклы караш. Бүгенге көндә татарны тик «болгар» гына дип күрсәтергә тырышу, раса сафлыгы теориясенә тәңгәл килеп, борынгы болгарның ниндидер бер географик изоляциядә, ниндидер бер пыяла савытта ятарга тиешлеген күрсәтә. Ә бит без яшәгән җирләр аша борын-борын заманнан бирле халыкларның «бөек күчеш» юллары үткән. Шул күченүләр вакытында болгарлар кайда да булса качып ятылар микәнни? Ә Чыңгыз, Бату яулары килгәч, алар белән килгән төрки кавемнәр арасында ту-

ганлык мөнәсәбәтләре булмады микәнни? Ә монгол-лар үзләре болгарлар белән каннарын кушмадылар микәнни? Юк, татарны ниндидер бер «раса ягыннан саф халык» дип күрсәтергә тырышу — ул бернинди кысага да сыймый.

Бүгенге татарларның болгарлыкка тайпылуы, ул — татарны кимсетүләргә, аны яулап алучылар, изүче-талаучылар белән бер дәрәҗәгә куярга тырышуларга җавап кына. Дөреслектә исә, болгарлык ул — татарның бала чагы гына. Ә бала чакка кире юл юк. Аның турында тик сагынып сөйләргә генә кала. Ул турыда тарихчылар сөйләсеннәр. Тик дөрес итеп кенә сөйләсеннәр.

Алтын Урда чоры — халкыбызның аерым бер яшәү дәвере. Ул — аның бер сыйфатын югалтып, икенче сыйфатка ия булу дәвере. Минем уйлавымча, Алтын Урда дәүләтендә болгарлар, иң алга киткән мәдәниятле халык буларак, цивилизаторлык ролен уйнаганнар. Алар бүгенге татар теленә якын булган телләрне дәүләт теле итеп тарата алганнар. Килгән кавем-кабиләләрне ислам диненә күндергәннәр, ислам мәдәнияте булдырып, аны шушы дәүләтнең нигез ташына әйләндергәннәр. Кыскасы, алар Алтын Урдада мәдәни өстенлекләрен тормышка ашырып, үзләре дә килгән кавем-кабиләләргә кушылып, уртак бердәмлек хасил иткәннәр.

Алтын Урда дәүләтенең соңгы чорындагы шушы бердәмлек татарлыкның нигезен тәшкил иткән. Юкка гына түгел, бүгенге татар теле, шул вакытта татарларның төрки халыклар арасында уйнаган роленә бәрабәр буларак, төрки телләрнең уртасында тора. Ул, шул телләрнең дәрәҗәле илчесе буларак, дөньядагы 14 халыкара аралашу телләренең берсе санала.

Шулай булгач, бүгенге татарны тик болгар баласы гына дип карау — һич тә дөрес булмас иде. Шул ук вакытта аны татар-монгол кавеменә кайтарып калдыру да гаделлеккә туры килмәстер. Бүгенге татар ул —

шушы төп ике һәм башка төрле, шул исәптән угро-фин компонентының да синтезы булса кирәк.

Татар халкының килеп чыгышын бүгенге көн таләпләреннән генә чыгып хәл итү төп фәнни принципларга каршы килә. Монда бернинди сәясәткә дә карамастан, тик дөреслек юлыннан гына бару зарури-дыр.

Ләкин татар милләтенең барлыкка килүен моңа гына кайтарып калдырырга ярамый. Монда татар кайчан үзен шушы Алтын Урда халыкларыннан аерып алып карый башлавын ачыклау зарур. Шул ук вакытта «татар» дигән төшәнчә бу чорда киң таралган булганлыгын да исәпкә алырга кирәк. Бүгенге Казан татары гомергә татар бердәмлеген сизеп яшәгәнме, әллә инде үзен баштан ук «болгарлы» яки «казанлы» татар итеп хис иткәнме? Болары шулай ук зур сораулар. Чөнки теләсә кайсы җирдә, теләсә кемне «татар» итеп игълан итүләргә таянып, дөньядагы һәрбер булган һәм булмаган этлекне бүгенге татар халкына ябыштыру — чын хакыйкатькә берничек тә туры килми. Әле бит күптән түгел генә казанлы һәм кырымлыларны гына түгел, хәтта азәрбайҗаннарны, Төньяк Кавказ төркиләрен дә «татар» дип йөртәләр иде. Моны шулай ук онытырга ярамый.

Татар халкының үзен аерым милләт итеп хис итүе кайчан башлана соң? Кабатлап әйтәм, бу — зур сорау. Моңа җавап бирү өчен башка ваграк сорауларга җавап бирү кирәк. Аларның беренчесе: татарлар үз-үзләрен кайсы вакыттан бирле «без» дип сөйли башлыйлар? Бүгенге татарлар болгар тарихын сөйләгәндә бу сүзне кулланмыйлар диярлек. Ә менә инде Казан тарихына килгәндә, бу сүз киң кулланыла. Бу халык тарихының сагынып сөйли торган дәвере. Димәк, халыкның үз-үзен аңлап, үткәндәге кичерешләрне бүгенгегә күчереп яшәү чоры әнә шул Казан тарихыннан, бигрәк тә аның соңгы чорыннан башлана.

Монда халыкның уртак трагедия кичерүен шушы «без»лекне, аның милләт булып оешуын тизләтүгә сәбәп дип карау да дөрес булыр иде. Чыннан да, Казан трагедиясе бүген дә зур фаҗига итеп кабул ителә, халыкта бабаларыбызның 1552 елгы кичерешләрен күңелендә уянуына китерә. Ә бит Казан ханлыгының бетүе ул — татар трагедиясе генә булмый. Ул шулай ук чуваш, мари, мукшы өчен дә фаҗига була. Ләкин бүген аны үзе өчен трагедия итеп бары тик татар гына кабул итә. Ә бит әйтеп үткән халыклар да шул вакыт уртак дошманга каршы аяусыз көрәшәләр, меңләгән корбан бирәләр. Марилар Казан алынганнан соң да әле берничә дистә ел буе азатлык хәрәкәте алып баралар. Ләкин болар берсе дә бу халыкларның тарихи хәтерендә сеңеп калмаган. Бу инде татарларның үзаңы шул вакытта ук бик алга киткәнлеген, 1552 ел трагедиясенең аны үстерүгә этәргеч фактор булуын раслый. Халык шагыйре Тукайның үлеме дә шундый этәргеч фактор итеп каралырга тиеш. Әйе, бу үлем — дөньядагы һәммә татарның уртак кайгысы була. «Кояш» газетасы «бу көнне барлык татар җылый, алар бүген үзләренең бөек сүз остасын югалттылар»,— дип язды. Бакуда чыккан «Каспий» газетасы Дагестани псевдонимлы журналистның Тукай үлеменә багышланган мәкаләсен бастырган. Ул анда: «Мөселман йөрәкләрен сүз белән яндырган шагыйрьнең истәлеге һәркем өчен кадерле»,— дип язды. Ул үзенең ун ел буе җәмәгать эше белән шөгыльләнү дәверендә мөселманнарның сәнгать әһелен югалтуда бу кадәр кайнар катнашканнарын күргәнем юк иде әле, ди. Чыннан да, Тукайны күмү, аны югалту — милләт кайгысына әйләнә. Харбиннан, Читадан, Оренбургтан һәм башка җирләрдән бөек шагыйрь турында лекцияләр укылганы турында хәбәр килә. Татар студентлары өчен аның исемендәге стипендияләр булдырыла.

Ләкин без татарларның милләт булып оешуы туктаусыз рәвештә, бер чама белән алга тәгәри барган дисәк, бу шулай ук дөрес булмас иде. Кайбер чорларда халыкның үзаңы дистәләрчә еллар йоклау рәвешен кичерә дисәк дөресрәк булыр.

Монда, минемчә, Казан алынганнан соңгы ике йөз елны күрсәтеп үтү кирәктер. Бу чор, татарларның югары катлаулары, зыялылары юкка чыгарылып, халыкның зур афәттә япа-ялгыз калган вакыты. Иске югары катлам вәкилләренең күбесе, я руска күчеп — чукынып, я үтерелеп-кырылып, я булмаса крестьян дәрәҗәсенә төшерелеп, гади халык арасына ыргытылып, аның белән бергә җир сукалаган вакыты. Бу — алга китү чоры түгел. Бу — халыкны физик яктан исән калу кайгысы биләгән чор. Ләкин бу чорны да юкка үткән дәвер дип атау дөрес булмас иде. Бу — татарда каршылык күрсәтү сыйфаты үсеп чыккан еллар. Үзен саклау өчен халык, беренчедән, үзе дә каршылык күрсәтү, оешу сыйфатларын булдыра. Моңа корал белән көрәшә алу да керә. Пугач, Разин яуларында катнашу, Батырша һәм башка баш күтәрү фактлары шуны раслыйлар. Бу — юлбашчы эзләү дәвере. Үз-үзен саклау хаҗәтенә дин дә зур өлеш кертә. Халыкта татарлык түгел, мөселманлык хисе күбрәк өстенлек итә. Ул заманда «сез татармы?» дигән сорауга, күбрәк «Без мөселман» дип җавап бирелгән.

Бу чор — этник чыгыш, дин һәм язмыш уртаклыгын ныгыту чоры. Әгәр дә халык шушы чыныгуны лаеклы рәвештә үтә алмаган булса, христиан дәүләтенең аны бетерергә юнәлдерелгән сәясәте бәлки уңышка да ирешкән булыр иде.

Менә шуннан соң инде татарның милләт булып алга таба атлый башлау дәвере башлана. Аның зыялылары да үсеп чыга, югары катлавы да барлыкка килә. Аңарда яшәү көче арта.

Әгәр дә без татар милләте оешу тарихын тасвир-

лаганда Россиянең капитализмга таба борылышын күздә тотмасак, татарларның шушы хәрәкәткә барышын дөрес аңлый алмас идек. Татарлар өчен ике гасыр чиге, бигрәк тә XX гасыр башы чын мәгънәсендә яңару дәвере була.

Беренчедән, татарларда үз-үзенә ышану көче ныгый.

Икенчедән, алар мөселман халыклары арасында үзләрен лидер итеп танытталар.

Өченчедән, аларның мәдәнияте чын мәгънәсендә чәчәк ату чорын кичерә. Бигрәк тә китап чыгару, газета-журналлар бастыра башлау, болар белән тыгыз бәйләнгән дистәләрчә әдәбияты, язучылар үсеп чыгу, милли тел туу, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең яңа юлга басып, дөньяви белемне икътисади үсүгә юнәлдерә алуы ярылып ята.

Дүртенчедән, милләт үсешенә зур матди ярдәм итә алырдай промышленниклар барлыкка килә, чын мәгънәсендәге татар зыялылары мәйданга чыга. Бу зыялылар татарның үзе арасында гына түгел, бәлки башка мөселман халыклары арасында да мәгърифәтчелек белән шөгыльләнәләр.

Бишенчедән, татар халкы тоташ уку-язу белә торган халыкка әйләнә.

Алтынчыдан, халыкның үзаңы татарның элеккеге данын кайтаруга таба йөз тота.

Әлбәттә, монда татарлар арасындагы сыйнфый үзгәрешләрне күрми китү дөрес булмас иде. Буржуазия белән бергә татарда эшче сыйныф барлыкка килә. Авылда да кискен үзгәрешләр булып үтә. Дөрес, татар пролетариаты үз милләтенең капиталисты белән бик сирәк йөзгә-йөз очраша. Моның сәбәбе, беренчедән, татар пролетариатының күбесе үз төбәгендә яшәмичә, Россиянең башка җирләрендә гомер итүендә, икенчедән, бары тик татарлар гына эшли торган предприятиеләр бик сирәк була. Эшчеләрнең күпчелеге рус

капиталистлары кул астында эшли, капиталистлар исә милли пролетариат белән эш итми диярлек. Шунлыктан, татарлар арасында сыйнфый бәрелеш бик сирәк очрый. Андый фактлар инде бөртекләп диярлек тикшерелгән.

Ләкин татар җәмәгатьчелеге, аның сәяси актив өлеше үзен шактый нык сиздерә. Татарлар арасында гомумроссия сәяси партияләренең әгъзалары ишәя. Алар бер яктан кадет партиясендә булсалар, икенче яктан, эшче халыкка якын зыялы яшьләр социал-демократия сафларында күп була. Татарлар арасында бигрәк тә социалист-революционерлар йогынтысы зур була. Хәтта милли эсерлар партиясе дә төзелә.

Ләкин иҗтимагый хәрәкәтнең төп факты итеп, мөгаен, «милли фирка» барлыкка килүне санарга кирәктер. Сүз «Мөселман иттифагы» партиясе турында бара. Мәгълүм булганча, ул 1906 елны барлыкка килеп, үзенең биш съездын үткәреп өлгерә. Дөрес, бу партия «татар партиясе» дип аталмый, ул чыннан да гомуммөселман фиркасы була. Ләкин ул, бер яктан, кадетлар партиясенә якын булса, икенче яктан, гомумтөрки, гомуммөселман фиркасы итеп карала ала. Бу яктан чыгып караганда аны пантюркизм, хәтта панисламизм партиясе дип карау да дөрестер. Әлбәттә, бу төшенчәгә царизм биргән мәгънәне салып карарга кирәк түгел. Бу нинди дә булса карагруһчылык, нинди дә булса ачы милләтчелек түгел. Бу тик Россия мөселманнарының ихтыяҗларын чагылдырган, аларны бер көч итеп азатлык көрәше юлына өндәгән фирка. Шулай булуга да карамастан, жандармерия 28 кешелек панисламистлар исемлеге төзеп, шунда бу партиянең барлык активистларын да кертеп, алар артыннан махсус күзәтү оештыра.

Татар милләтенең оешу тарихында 1905—1907 еллардагы рус революциясенең әһәмияте искиткеч зур була. Моны инкяр итеп булмый. «Аң» журналының

1912 елда чыккан бер санында бу инкыйлаб татарларга башка халыкларга караганда күбрәк файда китерде, диелә. Моның белән килешми булмыйдыр. Инкыйлаблар халыкларга оттырыш кына түгел, отыш та бирә алалар. Монысы да факт. Татарларга карата беренче рус революциясе — нәкъ шундыйлардан була.

Бу инкыйлаб мәдәни үсешне генә түгел, милли аңны да моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә күтәрә. Чын мәгънәсендә җәмәгать тормышы барлыкка килә. Милли идеяләр тудыручы учаклар үсеп чыга. Монда бигрәк тә җәдитчелек хәрәкәтен искә алырга кирәк. Бу хәрәкәт уку-укыту ысулларын үзгәртеп коруга, дөньяви белемгә омтылуга гына кайтып калмый. Бу укытуда яңа ысуллар кертү өчен көрәш кенә түгел, аңа гомумән татар дөньясына ислях (реформа) үткәрү, татарның дөньядагы ролен билгеләүгә юнәлдерелгән хәрәкәт дип карау дөресрәк булыр.

Монда, әлбәттә, милли идеяләрне билгеләүче учаклар мәсьәләсен карап китү кирәктер. Чөнки идеяләр үзеннән-үзе тумыйлар. Аларны кемнәрдер, кайдадыр тудыра. Дөрес, бу мәсьәлә махсус тикшерену таләп итә. Ләкин аны бөтенләй әйләнеп үтү дә ялгышлык булыр иде.

Милли идеяләрнең учагы булып Казандагы «Мөхәммәдия», Оренбургтагы «Хөсәения», Уфадагы «Галия», Вятка губернасының Иж-Буби авылында урнашкан Габдулла һәм Гобәйдулла Буби мәдрәсәләре хезмәт итеп килгән. Монда татарның бик күп зыялылары укып чыккан һәм укыткан. Милли идеяләр шушы уку йортларыннан бөтен Россия буйлап таралган. Әйтеп үтелгән Иж-Буби мәдрәсәсе шәкертләре, башка мәдрәсә шәкертләре кебек үк, революция хәрәкәтендә катнашалар. Милли аңны уятуга юнәлдерелгән җырлар таратала р *. Аларның берсендә татарларның үткән

* Җырлар рус чыганакларыннан алынып, эчтәлеге генә сөйләп чыгылды.— Авт.

тарихлары мактала һәм бүгенге мескенлек белән чагыштырыла. «Безгә рус патшасы изүендә күпме ятарга мөмкин, безнең бит элек үз патшаларыбыз булган һәм без моны һич тә онытырга тиеш түгел». Җырларда Сөембикә манарасына зур урын бирелә. «Син һәммә нәрсәдән дә биексең, синең башың күккә тия, ә минем күзләремнән яшь ага, чөнки синең һәрбер ташың минем йөрәгемне телгәләп җылый сыман». Җырда үткәнне сагыну зары тоела: «Монда кайчандыр ислам гаскәре торган, ә хәзер кайда соң ул? Безнең бөеклегебезнең инде меңнән бере дә калмаган, ислам җире бөтенләй башкага әверелгән». Җырларның берсендә татарларга шундый мөрәҗәгать бар: «Ник соң татарлар баш күтәрми? Башкалар бит инде күтәрелеп богауларын салдылар. Нигә татарлар да шулай эшләми? Безнең милләтебез шул кадәр йөдәп, инде үз-үзенә ышанычын югалткан. Нигә соң татарлар моны тоймый? Без бит татар балалары, ә кайда безнең башкалабыз? Бар да беттеме икәнни, без хәзер нишлик инде?» Җырда, бер әйбер дә яшермәстән, ачыктан-ачык үткән заман һәм бүгенге көнне тикшереп карарга тәкъдим ителә.

Шушы чорда халыкның тарихи хәтерен кузгатып, аңарда уртак кичереш-тойгылар уяту максаты белән язучы зыялылар күбәя. Шул ук Иж-Буби мәдрәсәсендә язылган, жандармнар кулына килеп эләккән бер хатта болай диелгән: «Бездә милләт өчен канлы яшь коючылар бар. Аларның исеме беркайчан да онытылмас». Вакытлы матбугат шулай ук милли бердәмлекне, тарихи аңны уятуга зур урын бирә. Бигрәк тә «Вакыт» газетасы, «Шура» һәм «Аң» журналлары милли көрәшнең алгы сызыгында булалар. «Вакыт» газетасы үзенең 1911 елгы 120 санында болай дип яза: «Үз тарихы, үз әдәби теле, искиткеч тарихы булган халык, ул беркайчан да югалмас. Аны баскан коточкыч хәл — вакытлы хәл генә. Болар бар да юкка чыгар. Менә

безнең халык уяныр: бик озак хәрәкәтсез яткан кабер тузанын кагар. Татарларның киләчәге томанлы түгел, ул бик тә ышанычлы». Шул ук газетаның 118 номерында «халык бер гомум масса булып, оешырга тиеш. Шул вакытта аның теләгенә каршы берәү дә бара алмас... Ул теләккә таянып кайчандыр югалган хокукны кайтарып булачак. Кыскасы, халык теләге шул кадәр көчле ки, аны берәү дә җиңә алмый»,— диелгән.

Бездә әле шушы фактларга тиешле бәя бирелгәне юк. Ә бит нәкъ менә халыкның бердәм масса булып, кайчандыр тартып алынган, тапталган хокукларын кире кайтару өмете белән яшәвен милләт булып өлгерүнең бер факторы итеп караганда гына дөрес юлга чыгу мөмкинлеге туачак. Өмет, гомуми өмет булу халыкның милләт булып өлгерүен күрсәтә. Югалган дәүләтне торгызу өмете күпләрне биләп ала. 1911 елда төзелгән жандарм документларының берсендә «Казан губернасында, кайчандыр дәһшәтле Казан патшалыгының тарихи үзәге булган Казанда бик күп алдынгы татар элементы җыелган»,— диелә. Чыннан да, нәкъ менә шушы дәүләтчелекне кире кайтару, халыкны гомум бер массага әверелдерү уе, беренче буларак, Казанның үзендә барлыкка килә, аннан Петербург, Мәскәү, Оренбург, Әстерхан һәм башка җирләргә таралып, бердәм милли хәрәкәт тудыра. Властьлар әнә шуннан курка. Алдынгы татар элементына каршы көрәш ачалар. 1911 елда 28 кешелек панисламистлар исемлеге төзеп һәммә жандармерия идарәләренә тараталар. Исемлектәге һәм тагын башка йөзләгән кеше артыннан күзәтү оештыралар.

Милли аң төшенчәсе әле безнең фәнни әдәбиятта тиешенчә өйрәнелмәгән. Ләкин шуннан башка, тик сыйнфый аңга гына таянып, милләт тарихын дөрес аңлап булмастыр. Шушы уңайдан XX йөз башында киң таралган партюркизм (төркичелек) концепциясе хакында бер-ике сүз әйтеп китү урынлы булыр. Чөнки

татарның милләт буларак оешуында бер-ике тенденция яшәп, арадан «гомумтөрек милләте» дигән агымының шактый көчле булганлыгы тарихи хакыйкать. «Төрекме, татармы?» дигән сорауга күпләр «без төрек» дип җавап биргәннәр. Бу агымны татар өчен гел зарарга гына булган дип карау шулай ук дөрес түгел. Чөнки монда да бердәмлеккә өндәү, татарны гомумтөрек кавеменең бер өлеше итеп күрсәтү беренче урында тора. Монда милләтне, халыкны таркату түгел, киресенчә, аны гомумтөрки байрак астында җыю, укмаштыру максат итеп куела.

Әлбәттә, инде бүленеп, таралып беткән, күптән инде үз телләренә, үз тарихларына ия булган, ата йортыннан бүленеп чыгып, үзләре күптән инде ата гына түгел, бабага әйләнеп беткән төрки халыкларны кире җыю утопиягә тиң нәрсә. Халыкларны түгел, хәтта төп йорттан бүленеп, аерылып чыккан балаларны да кире җыеп булмый. Ләкин төркичелекнең рациональ орлыгы шунда ки, ул бер тамырдан чыккан халыкларны дуслыкка, туганлыкка өнди. Монда, әлбәттә, бер-береңне аңлау беренче урында тора. Бер-береңә аңлашыла торган китаплар булдыру, уртак нигездә төзелгән алфавит һ. б. Әлбәттә, һәммә төрки халыклар гарәп шрифтын кулланган заманнарда аларга үзара аңлашу җиңелрәк булган. Уртак диярлек орфография, бик күп уртак сүзләр, төшенчәләр халыкларның бер-беренә юлны киң ачкан. «Тәрҗеман» газетасы, мәсәлән, укырга авыр булуына да карамастан, Россиядәге төрки халыкларның барысына да аңлаешлы булган. Бәлки, аны чыгару дәвам иткән булса, уртак әдәби тел барлыкка килүе дә реальрәк булган булыр иде.

Дөрес, монда идеалист булуның кирәге юк. Һәрбер төрки милләт үз юлы белән барырга тиеш. Аларның һәммәсенең дә үз дәүләт структурасы булу кирәк. Аларның һәрберсе бәйсезлеккә мохтаҗ. Ялгыш аңлаган төркичелек идеясе исә әнә шул бәйсезлеккә, мөстәкыйль-

леккә богау гына. Аны кире кушылу, бер милләт тәшкил итү коралы дип түгел, ә бер-берең белән аңлашып, аралашып яшәү ысулы итеп карау дөресрәк булыр. Төркичелек тарихы турында сүз алып барганда, бу идеологияне бөтен төрки халыкларны Төркиягә буйсындырырга омтылу дип карау һич тә дөрес булмас иде. Әйе, заманында Төркия, бердәнбер мөстәкыйль төрки дәүләт буларак, төрки халыкларда ниндидер өметләр уята килгән. Ләкин татарлар арасындагы төркичелек, төреккә, Төркиягә табынуга әйләнеп калмый. Татарлар мәдәниятләре алга киткән саен, әдәбиятлары, телләре ныгыган саен үзләрен аерым көч итеп тоя башлыйлар Жандармнарның бер документында «Төркиядә Гаяз Исхаков, Фатих Кәрими, Галиәсгар Камал, студент Габдрахман Мостафа булып кайттылар» диелә. «Ләкин алар аннан Төркия инде беткән һәм аңарга таянырга мөмкин түгел дигән ышаныч белән кайттылар» диелә. «Алар, шималь төрекләре, ягъни татарлар, төрекләргә караганда һәрьяктан да өстенрәк торалар һәм шунлыктан үз язмышларын үз кулларына алырга тиешләр» диелә. Монда әйтелгән сүзләргә ышандырырлык дәлилләр татар дөньясында инде күптән өлгергән була.

Милләт булып оешуның бер фазасы, бер яктан, үзен төрек, мөселман дөньясында хис итү булса, икенче яктан, шул дөньяда мөстәкыйль көч булуыңа тулы ышанудан тора. Әгәр дә теге яки бу кавем үзенең инде ана куеныннан чыкканлыгын аңламаса, ул әле милләт түгел. Аның милләт булу өчен шактый юл үтәсе бар, дигән сүз. Ул әле мөстәкыйль яши алмый. Аның әле теле дә юк. Әдәбияты, мәдәнияте булу — алдагы бер максат кына булып кала.

Әйе, татар милләтенең үзаңы — үзенең төрки кәвемнән чыкканлыгын тоеп үскән һәм өлгергән. Төрки бердәмлек, төркиләр дөньясында татарларның роле — бу

мәсьәләләр киң җәмәгатьчелек тарафыннан һәрвакыт җентекләп тикшерелә килгән.

Инде панисламизм (исламчылык) хакында да берике сүз әйтү кирәктер. Татар милләте үзен ислам дөньясының әгъзасы хис итеп дөньяга килә. Дөньядагы мөселманнарның язмышы татарларны һәрвакыт кызыксындырган. Шунысы кызыклы, кайдагыдыр гарәп кабиләләре татарның барын-югын да белмәгән дәвердә татарлар шул гарәпләрне яхшы белеп, аларның язмышлары белән кызыксынып яшәгәннәр.

«Маяклы юллардан юлчы бара, печән белән күмгән чанасын. Юлчы, кая болай ашыгасың, нинди хәбәр алып барасың? Чемберлинның сатыйм анасын, тупка тоткан Мәккә каласын!» (Һ. Такташ). Менә шушы шигъри юлларда да әлеге дини туганлыкны тоеп яшәү чагыла. Мөселманлык, дини берлек кайдадыр чүлдә яшәүче, беркайчан кар күрмәгән гарәп язмышы — кар көртенә чумган татар мөселманның кайгыруына, ачу-нәфрәтенә сәбәп булып тора.

Әлбәттә, исламчылыкның да сәяси аспекты бар. Анысы халыкка кагылмый диярлек. Халыкны тик әнә шул дини бердәмлек, бер Аллага ышанып яшәүче дини кардәшләр булу гына кызыксындыра. Ул моннан бернинди сәясәт ясамый. Югары катлауларда исә, әнә шул табигый бердәмлекне зур сәясәт дәрәҗәсенә күтәреп, аны хөкүмәткә каршы көрәш коралына әверелдерү тенденциясе беренче урында тора. Исламчылык — дөньяви идеология. Ул, гомумән, колониализмга, империализмга каршы юнәлдерелгән. Мөселман дөньясы әле күптән түгел генә бөтенләе белән чит ил колониализмы кул астында яшәгән. Күп мөселман илләренең дәүләт бәйсезлеге дә юкка чыгып, алар шул Көнбатыш илләре төзегән империяләргә буйсынып беткән булалар. Мөселманнарны шушы империализмга каршы оештыру, мөселман дөньясының бердәм булып, үзенең азатлыкка омтылуын бер агымга әйләндерү алдынгы

мөселман зыялыларының миләренә нык сеңгән була. Моның шаукымы Россиягә дә килеп җитә. Идарәче даирәләр күңеленә шом сала. Без монда исламчылыкның тарихын яки идеологик нигезләрен күрсәтү кирәктер дип санамыйбыз. Безгә тик, татар милләтенең оешкан дәверендә шушы идеологиянең ясаган йогынтысын күрсәтеп үтү дә җитә. Рухи бердәмлекне тиешенчә аңламаганда, милләтнең килеп чыгышына бәя бирү бер яклы булуы мөмкин.

Бүгенге сәясәт ислам проблемасын яңадан күтәрде. Дин тормышта үзенә тиешле урынны дәгъвалый. Шулай булырга тиеш тә. Шунсыз милли яңару юк һәм булмас та. Ләкин бу инде исламчылык түгел. Мөселман илләре һәм халыклары белән элемтә һичшиксез яңарырга тиештер. Бу, әлбәттә, алар арасында ниндидер махсус элемтәләр булуын сорый. Ләкин мөселман илләрен берләштереп, нинди дә булса ислам дәүләте төзү турында сүз бармый. Монда да мөстәкыйльлек, бәйсезлек принциплары беренче урында торырга тиештер. Тик шулай булганда гына мөселман халыклары үз араларында гаделлек урнаштырыр дип уйларга кирәктер.

Мин татар милләтенең килеп чыгуын тулы тикшерүне үземә бурыч итеп куймадым. Шул ук вакытта монда әйтелгән фикерләрне дә бәхәссез дип саный алмыйм. Шунлыктан нинди дә булса каршы сүзләр әйтелә икән, аларны тиешле рәвештә кабул итеп, аларга җавап бирү хокукын үземдә калдырам.

МИЛЛӘТЕБЕЗГӘ ХАС ТӨП СЫЙФАТЛАР

Милләтнең сыйфатлары бик күп төрле. Алар арасында төрле милләтләр өчен уртак булганнары белән бергә билгеле бер төбәктә яшәүчеләрнең үзләренә генә хас булган холык һәм яшәү үзенчәлекләре дә бар.

Шулай да татар халкының кайбер гомум холык

билгеләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Бередә сүз, башлыча, әнә шул хакта булыр. Шушы уңайдан кайбер шәхси фикерләремне дә әйтеп үтәрмен.

Гәрчә бездә халыклар тигез дип әйтеп киленсә дә, асылда бер халыкка карата һәрвакыт диярлек өстенлек биреп киленде — ул да булса бөек рус халкына. Ул гаделлекнең, бөеклекнең, зирәклекнең һәм башка күркәм сыйфатларның өлгесе итеп каралды. Мондый караш агитация һәм пропаганда эшендә дә чагылыш таба килде. Ә инде Сталинның 1946 елда Кремль курсантлары алдында ясаган чыгышы бу яктан идеологиянең төп нигезенә әйләнде.

Шик юк, һәммә халык үзенә күрә бөек, үзенә күрә зирәк. Ләкин алар теге яки бу халыкка башкалардан күчмәгән. Бу сыйфатлар аларда тарихи яшәеш юлында туган. Алай гына да түгел, шул сыйфатлар яшәешнең гарантиясенә әверелгән.

Милли холык — милләтнең тарихи яшәеш җимеше. Ул аның үз-үзен милләт итеп саклау чараларыннан үсеп чыккан. Шунлыктан халыкның үз тарихына тәңгәл булган милли сыйфатлары була. Шулар сакланып калса, милләт милләт булып яши. Әгәр дә алар бетү юлына борылган икән, милләтнең яшәп калуына куркыныч туган дигән сүз. Милли сыйфатларның җуелуы — милләтнең юкка чыгуын белдергән сигнал. Менә ни өчен милли сыйфатлар, гореф-гадәтләр халыкның мирасына әйләнеп, милләт язмышын кайгыртучылар өчен махсус проблема булып килгән.

Без, халыклар барысы да бөек, барысы да зирәк, барысы да уңган, дип әйткәнбез икән, бу төшенчәләргә милли эчтәлек салынганлыгын да истә тотарга тиешбез. Чыннан да, яһүдләрнең бөеклеге аларның хәйләкәрлегендә, башкалар белән эш иткәндәге тапкырлыгында, бер-берен яклый алуында, оеша һәм укмаша белүендә булса, татарларның бөеклеге аларның мөстәкыйль рухлылыгында, сугышларда баһадирлыгында,

теләсә нинди эштә уңган һәм һәвәс булуында күбрәк чагылыш тапкан. Кечкенә генә халыклар булган чукчә яки эвенкларның бөеклеге — аларның кар-боз арасында ваемсыз табигать белән аралашып яши алуында чагылыш тапкан. Башкалар алар яшәгән шартларда бөтенләй яши алмаслар иде. Ә болар исә яшәү генә түгел, үзләренә хас мәдәният, әдәбият һәм башка төрле кешегә хас кәсепләр дә тудырып килгәннәр.

Һәр халыкның үз яшәү рәвеше була, үзенә генә хас сыйфатлары барлыкка килә.

Мин нинди дә булса расачылык принципларын аклаудан ерак торам, аларны берничек тә кабул итә алмыйм. Тик шулай да чыгышлары белән төрлечә булган халыкларның үзенчәлекләрен күрергә һәм танырга кирәктер дип саныйм. Әйтик, славяннар бердәм яши башлаган чорларда алар әле бер-береннән әллә ни аерылып тормаганнар. Һәм шул дәвердә аларның һәммәсенә хас нindидер уртак сыйфатлар хасил булган. Семит халыклары да шулай. Әгәр дә безнең бүгенге заманда гарәпләр белән яһүдләр үзара сугышалар икән, бу факт аларның кайчандыр бер гаиләдә яшәмәгәнлекләренә дәлил түгел. Киресенчә, бу үзара дошманлыкта яшәүләренә дә карамастан, аларда ниндидер сыйфатларның уртаклыгына ишарә ясый.

Борынгы төрек (төрки) кавемендә дә шулай булган. Кайдадыр кар-боз арасында яшәгән якутлар белән җәннәттәге кебек шартларда яшәгән төрекләр арасында да уртаклык бар. Ә бит аларны меңнән артык еллар аерып тора. Әгәр дә шушы ике халыкның милли сыйфатларын чагыштырып карасак, һичшиксез, шактый уртаклык табар идек.

Чыннан да, әгәр дә без бүген татар халкының милли сыйфатларын тикшерә башласак, һәммә төрки халыкларга да хас сыйфатларны табачакбыз. Мин аларның бер-икесен генә күрсәтеп үтәсем килә. Аларның берсе — мөстәкыйльлек. Төрки халыклар шушы сый-

фатлары белән баштан ук башкалардан нык аерылып торганнар. Бу башкаларга карата мөнәсәбәттә һәм үзара мөстәкыйльлеккә бүленә һәм күп вакыт шәхси холыкка кадәр килеп җитә.

Мөстәкыйльлекне сакларга тырышу аларны утка-суга да керткән, үзләренә генә хас һөнәр-кәсеп иясенә дә әверелдергән. Юкка гына түгел, төркиләрдән, шул исәптән татарлардан, тарихка кереп калган атаклы сугышчылар һәм юлбашчы — гаскәр башлыклары чыккан. Татарларның һөнәрчелек, сәүдәгәрлек кәсепләре дә шуннан килә булса кирәк.

Төркиләр өчен, никадәр авыр шартларда калуларына да карамастан, мөстәкыйль тел, мәдәният булдыруга омтылу хас. Фәндә кытайларның башкаларга зур йогынты ясавын гел күрсәтеп киләләр. Төркиләр, имештер, алардан бик күп нәрсәне алганнар. Монысы да шулайдыр. Төркиләр, шул исәптән татарлар да, алдынгы эш алымнарын, фән ачышларын, аларның кайдан чыгуына, кем тарафыннан кертелүенә карамастан, үзләштерә килгәннәр. Алай гына да түгел, үзләре белгәннәрне башкаларга да өйрәткәннәр. Мәсәлән, һуннар кытайлардан дөге аракысында кәбестә саклау ысулын өйрәнгәннәр. Үзләре исә, шул дөге аракысын тоз белән алыштырып, кәбестә тозлауны уйлап чыгарганнар. Һуннар үзләренең Европага ясаган походлары вакытында немецларны, ә алар аркылы бөтен Европаны, кәбестә тозларга өйрәткәннәр.

Әйе, төркиләр кытайлардан шактый күп нәрсәгә өйрәнгәннәр. Ә менә алар үзләре кытай кавеменә төрки җан салганнар, яки аларга үз музыкаларын бирә алганнар. Кытайдагы Тан династиясе чорында анда төрки мәдәният рухы көчле булган: төрки җыр дисеңме, төрки бию дисеңме, төркиләрчә киенү дисеңме. Гомумән, Тан Кытаенда төркилек модада була. Императорлар күчмә төркиләр белән якынлашырга омтыл-

ганнар, император оркестры төркиләр музыкасын гына башкара торган булган.

Кытайлар бүген дә татарча җырлыйлар кебек. Музыкаларыбызда шул кадәр охшашлык, шул кадәр уртаклык! Ә менә кытайлар үзләре, шушы төрки музыканы Япон утрауларына җиткереп, аларга да төрки җан өргәннәр. Күрәсең, кайсыдыр без күрә алмаслык тарихи ераклыкта кытайлар төркиләр белән туганлыкта булганнар. Төркиләр белән кытайларның кайсыдыр бабалары бер оядан чыккан булса кирәк.

Әмма бу тарихи яктан бәхәссез факт музыка тарихына гына кайтып кала алмый. Ул төрки халыкларның мөстәкыйльлеккә омтылуын раслый. Ләкин кайсы төрки халыкта ни рәвештә сакланып кала алган икән бу гүзәл сыйфат? Бәйсезлектә яшәгән төркиләрдә ул, әлбәттә, бөтен тулылыгы белән сакланган булса кирәк. Ә инде бәйсезлеген югалткан халыкларда ул сыйфат индивидуальләшкән, таралган, таркалган. Ләкин бөтенләе белән ул югалып бетә алмаган.

Димәк, татар милләтенең кайбер сыйфатларын билгеләгәндә без әнә шул еректан килгән гомумтөркилек билгеләрен, бер дә булмаса, аларның теге яки бу чагылышын искә алырга тиешбез.

Татарның төп милли сыйфатлары аның мөстәкыйль һәм бәйсез яшәгән чорында формалашкан. Монда сүз беренче чиратта аның гүзәл һәм матур яклары турында бара.

Беренче чиратта, татарның башка халыклар белән аралаша белү сыйфатын күрсәтәсе килә. Чөнки монысы бүгенге көндә бик яхшы чагылыш таба. Ул гомуми һәм шәхси мәсьәләләрне тыныч ысул, аңлашу юлы белән хәл итүне хуп күрә. Бәлки, аның бу сыйфаты әнә шул күчмә булып яшәгән чорында ук барлыкка килгәндер. Татарларның тарихи язмышы башкалар белән аралашып яшәүдән гыйбарәттер, күрәсең. Шунлыктан ул үзе кабул иткән ислам динен дә башкаларга

һөҗүм итү, башка диннәрне кысу-изү өчен кулланмаган. Ул аны да үзенең әнә шул тынычлыкка, аңлашуга омтылуына буйсындырган булса кирәк. Берәүләр моңа каршы чыгып, ничек алай булсын инде, татар гомергомергә сугыш чукмары, башкалар белән орышып, аларны яулап килгән, дияр. Монда да дөреслек юк түгел. Бер нәрсәне дә абсолютлаштырырга ярамый. Гомумән, табигатьтә, шул исәптән кеше табигатендә дә, халыклар табигатендә дә әнә шундый капма-каршы нәрсәләр бер-берсе белән янәшә яши. Бу исә кеше акылының табигатькә караганда никадәр зәгыйфь икәнлеген күрсәтә.

Әйе, төркиләр, шул исәптән татарлар да, үз тарихларында аз сугышмаган. Татарлар мөстәкыйльлекләрен булдыруда тыныч ысулларга өстенлек бирсәләр дә, кирәк чагында сугыш юлыннан да баш тартмаганнар. Гомумән, алар өчен чарага караганда максат һәрвакыт өстен торган булса кирәк.

Мөстәкыйльлекнең төп юлдашы мәгърифәт, аңа омтылу һәм аны нигезләү булган. Заманында күренекле этнограф Карл Фукс та үзенең «Казан татарлары» дигән хезмәтендә, татарларның Европадагы бик күп халыкларга караганда мәгърифәтлерәк икәнлеген билгеләп, алар үз араларында укый-яза белмәгән кешегә җирәнеп карыйлар һәм андый кеше гражданин булаpx ихтирамга лаек булмый, дип язып калдырган. Бу, чыннан да, һәрвакыт шулай булган. 1917 елга кадәр татарлар укый-яза белү, китап бастыру буенча иң алдынгы урыннарны алып торганнар. Алай гына да түгел, алар башка халыкларга да, бигрәк тә Казагыстан, Урта Азия халыкларына, ислам нуры белән бергә мәгърифәт тә илткәннәр. Татар укымышлылары шул халыкларның милли мәдәниятен булдыруга зур өлеш керткән.

Мөстәкыйльлек һәрвакыт диярлек үз көнеңне үзең күрә белүгә кайтып кала. Ә бу исә хуҗалыкны нәтиҗәле

итеп алып бара белүгә китерә. Татар халкы үз вакытында моңа ирешә алган. Ул төзегән Болгар дәүләте, Казан ханлыгы чын мәгънәсендә чәчәк аткан дәүләтләр булган. Анда яшәгән халык беркайчан да чабата кимәгән. Аңарга чабатаны соңрак кидергәннәр. Ул бай һәм мул тормышта яшәгән. Юкка гына түгелдер, Мәскәүдәгеләр безнең җирләрне оҗмахка тиң дип атаганнар. Ул җирләр үзләреннән-үзләре генә шундыйга әйләнмәгән, әлбәттә. Аны мөстәкыйльлеккә, байлыкка, муллыкка омтылган кешеләр җәннәт иткәннәр. Алар зур тырышлык куеп иген иккән, бакча үстергән, төрле-төрле кәсепләр үзләштергән. Безнең бабалар эшкәрткән «болгари» тиреләр дөньяда дан тоткан. Алар шулай ук төрле ерак илләргә дә сәяхәт иткәннәр, Татарлар данлыклы сәүдәгәр булу дәрәҗәсенә ирешкәннәр. Ә сәүдә итү өчен теләсә кайда үтеп керә алырлык товарлар җитештерә белү кирәк булган. Татар шундый булган да. Шуның өчен дә аның шәһәрләре дөньяда дан тоткан. Болгар шәһәрендә су үткәргеч, канализация булганлыгы мәгълүм. Ә Казанда данлыклы Таһир мунчасы булган.

Ә сугышлар? Әйе, сугышлар да булып торган. Аларның һәммәсендә дә татарларның үзләрен генә гаепләү дөрес булмас иде. Татарларның мул тормышта яшәвеннән көнләшүчеләр, байлыгына кызыгучылар да аз булмаган. Аларны тартып алу өчен яу белән килүчеләр дә еш булып торган.

Әйе, татар халкы баһадир халык булып оешкан. Батырлык — милләтебезнең горурланырлык сыйфаты. Аның тарихындагы кайсы гына сугышны алма, берсендә дә татар куркаклык күрсәтмәгән. Җиңелгән чакта да ул хурлыклы рәвештә җиңелмәгән. Мин монда татар халкының бәйсез дәүләте яшәгән чорны гына күздә тотмыйм.

Бүген кемнәр ни генә әйтмәсен, татар беркайчан да үзе яшәгән ватанга хыянәт итмәгән. Кайберәүләр

татарның рус яки башка дәүләтләрне яклавы белән торуланырга кирәк түгел диләр. Мин моның белән һич тә килешә алмыйм.

Рус дәүләте белән булган тарихи бәрелештә татарлар оттыралар. Ләкин хурлыклы рәвештә җиңелеп түгел. Аларның батырлыгына бөтен дөнья таң кала. Ә җиңелүнең сәбәпләре — икенче мәсьәлә. Вакыты җиткәч, алар турында да сүз алып барырбыз. Ә хәзер исә батырлык сыйфаты турында сөйләшүне дәвам иттерик.

Сугышларда Мәскәү өстен чыкканнан соң татарлар Россияне үзләренең ватаны итеп кабул итәргә мәҗбүр булдылар. Шуннан соң инде алар шушы ватанга һәрвакыт турылыклы булып килделәр. Шуңа күрә аларны куркаклыкта, батырлык җитмәүдә гаепләргә берәүнең дә акылы җиткәне юк әле. Берлиндагы рейхстаг гөмбәзенә байрак кадаучының татар егете Гази Заһитов булу һәм шуңа охшаган йөзләгән факт һич тә очраклы гына хәл түгел.

Татарларның бер өлешенең ватаны булып Польша, Литва һәм кайбер башка илләр калды. Алар шул ватаннарына да турылыклы хезмәт итеп килделәр. Монда дистәләгән фактлар китерергә булыр иде.

Кыскасы, татарларның бүгенгәчә югалмый сакланып калган милли сыйфаты буларак аның сугышчан батырлыгын күрсәтергә мөмкин.

Татарларны берәүләр кунакчыл дисә, икенчеләр аларның кысмырлыкка тартымлыгын билгеләп үтә. Монысын ничегрәк бәяләргә мөмкин булыр иде икән соң? Чыннан да, төркиләргә кунакчыллык хас. Урта Азия халыкларын, бигрәк тә кыргыз, казакъны алсак, моның шулай икәнлеген күрү кыен булмас. Ә инде кавказ кунакчыллыгы — ул инде бөтен дөньяда билгеле нәрсә.

Төрки халык буларак, татарларда андый сыйфат, әлбәттә, киң таралган. Аны без бигрәк тә К. Фуксның телгә алынган китабыннан беләбез. Ләкин безнең кул-

да татарларны кысмырлыкта, саранлыкта гаепли торган фактлар да бар. Ничек кенә булмасын, татарларның кунакчыллыгы Кавказ кунакчыллыгы түгел. Ул — башка.

Татарларның кунакчыллык сыйфаты зур сынаулар аша үткән. Аларның шаулап торган бай дәүләтләргә хуҗа булган вакытлары да күп булган. Шул вакытларда аларның юмартлык, кунакчыллык кебек сыйфатлары легендаларга кереп калып, дөньяга таралган. Ә инде иленнән, җиреннән, барлык мал-мөлкәтеннән мәхрүм калганнан соң, аларның бу сыйфатлары башкачарак юнәлештә үсә, үзгәрә. Әйе, үсә, үзгәрә. Ул беркайчан да бетми. Аңа бары тик чама хисе дигән нәрсә өстәлә. Гомумән, татар кәсепче, сәүдәгәр халык буларак, санау эшен яхшы өйрәнә һәм моны башкаларга да өйрәтә. Чөнки татар һәрвакыт үлчи, саный, хисап алып бара. Һәм бу аның яшәү рәвешенә әверелә.

Татарның кунакчыллыгы, төркиләр кунакчыллыгы буларак, Көнбатыш халыклары гадәтләре белән очрашып, андагы халыкларның гореф-гадәтләренә яраклашкан. Ул инде иксез-чиксез, чамасызлыкка нигезләнгән кунакчыллык түгел. Ул кешенең табигатенә, мөмкинлекләренә таянган, һәр нәрсәгә тормыш мөмкинлегеннән чыгып таләпчән караучан кунакчыллык. К. Фукс язып калдырган сыйфатларның инде байтагы юкка чыккан.

Юклык һәм кунакчыллык. Менә болар татарда икесе бергә кушыла. Чөнки аның муллык заманыннан мохтаҗлыкка, юклыкка күчүе 1552 елдан соң берничә ай, күп дигәндә берничә ел эчендә хәл ителә. Байлар кунакчыллыгы белән хәерчеләр кунакчыллыгы яраклашырга мәҗбүр була.

Тарихи шартлар татарның шушы сыйфатына үз «мөһерен суга». Элек-электән татарның йорты юлчыларга, адашып йөрүчеләргә, хәерчеләргә һәрвакыт ачык

булган. Анда туңган-күшеккәнәргә урын сәндерә, пич башында, күпләп керүчеләргә идән-сәкедә була. Аларга ястык-юрганы да һәрчак табылган.

Татар халкының бу сыйфаты бүген дә саклана. Ләкин ул инде, башка төркиләрдән аерымрак, үзенең үткән язмышына яраклашкан төс алган.

Әйе, милләтебезнең бар халыкта да ихтирам тудыра торган уңай сыйфатлары бик күп. Шундыйларның берсе — аның чисталыгы, пөхтәлеге. Аның бу сыйфатлары, һичшиксез, махсус тикшеренүләргә лаек һәм ул шулай булыр дип уйларга кирәк.

Ләкин без аның күркәм сыйфатларын гына күрсәк, аларга гына мәдхия җырласак, аның киләчәгенә зур зыян китерер идек. Чыннан да, әллә инде безнең милләт гел гүзәл сыйфатларга гына ияме? Шулай булгач, ул нигә шушы хәлгә калган?

Юк шул. Никадәр бөек булмасын, бер генә халык та, аерым шәхес кебек үк, тискәре сыйфатлардан да азат түгел. Югыйсә барлык халыклар да гел гүзәл һәм асыл, аларның берсенең дә тискәре сыйфатлары булмаса, алар үзара сугышырлар, кан коештырлар, берәүләре — хаким, икенчеләре — кол, яки берәүләре — артта калган, икенчеләре алга киткән булыр идемени?!

Бер халыкны да идеаллаштырырга ярамый. Тулы камиллек ул Аллаһы тәгаләнең үзендә генә. Ә халыклар исә фани дөньяда яши. Кешеләр изгелек кенә түгел, гөнаһ кылып та гомер кичерәләр.

Безнең милләтебез дә гел изгелекләр генә кылып яшәмәгән. Аның да тискәре яклары җитәрлек. Хәтта чиктән ашкан дияргә дә урын бар.

Шуларны аңлап, без әлеге сыйфатларның чыгышына, табигатенә игътибар бирергә тиеш. Аларның кайберләре борынгы төрки бабаларыбыз белән бергә туган булса, икенчеләре — төрле гадәтләрдән үсеп чыккан. Өченчеләрен безгә тарих «бүләк» иткән һәм ха-

лыкның канына сеңдергән. Без исә шуларның кайбер кирәкмәгәннәреннән арыныйк, ә арынып булмый торганнарын аңлап-белеп торыйк, дисәк, аларның табигатен тикшерергә тиешбез.

Мин шушы җитешсезлекләрне шартлы рәвештә икегә бүләр идем. Ни өчен шартлы дим? Чөнки алар арасында ызан юк. Алар бер-берсенә бәйләнгән. Аларның берсе икенчеләренең тууына сәбәп булган.

Шуларны искә алып, кайберләрен күздән кичереп үтик.

Милләтебезнең беренче төркем җитешсезлекләре аның хаким милләт булып мөстәкыйль яшәгән чордан килә, ә икенчеләре исә коллык заманында туган, үскән. Тик шулай да коллык заманы халыкка гел коллык сыйфатлары, гел тискәре гадәтләр генә биреп торгандыр дип уйлау дөрес булмастыр. Чөнки халкыбыз ул чорда да үзендә коллык тырнагыннан чыгарырдай сыйфатларны тудыра килгән.

Кайсы гадәтләребезне мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән заманда туган тискәре сыйфатлар дип әйтә алабыз соң?

Мин шуларның беренчесе итеп борынгы төрки бабаларыбыздан калган *көнчелек* сыйфатын атар идем. Бу сыйфат, әлбәттә, үзеннән-үзе барлыкка килмәгән. Ул халкыбызның мөстәкыйльлеккә омтылуының икенче ягы. Әлеге сыйфат кешеләрнең бер-берсе белән ярышып, аны уздырып яшәргә тырышуыннан барлыкка килгән. Шунлыктан төрки кабиләләр үзара ызгышып, күп вакыт бер-берсеннән көнләшеп яшәгәннәр. Әйтик, Чыңгыз гаскәренең авангардында кыпчыкларга, болгарларга каршы төрки кабиләләр килгән. Шулай итеп, алар үзләренең кан-кардәшләрен иректән мәхрүм иткән, аларның канын койган.

Шуны да әйтергә кирәк, төркиләрнең әнә шул сыйфатларыннан (ягъни бер-береннән көнләшүләреннән) аларның күршеләре оста файдаланган. Баштарак төр-

киләр шушы сыйфатларын үзара мөнәсәбәтләрдә чарлаган булсалар, соңрак моны аларның күршеләре дәвам иттерә. Бу хакта үзенең «Тарихи сәхифәләрне ачканда» дигән китабында күренекле татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин болай дип язып калдырган: «Әгәр бер урдадан куылган ханзада вә тәэсирле морза качып Россиягә сыенырга килсә, Мәскәү хөкүмәте ул кешене бик яхшы кабул итә, аңарга идарә кылырга шәһәрләр, иген игә торган җирләр, урманлыклар бирәдер иде. Шулай ук аларны чукындыру өчен дә тырышалар иде. Чөнки мондый ханзадәләрнең чукынуы белән аларның кайтып хан була алуыннан һәм халыкның башында торуыннан котыладыр иде; шулай ук мондый ханзадәләр аркылы төрле урдаларның хәлләрен, сәясәтләрен белеп торадыр иде».

Русларда, бигрәк тә алраның «фәнни» дип аталган әдәбиятында төркиләр белән булган мөнәсәбәтне «Кыргый кыр» («Дикое поле») белән мөнәсәбәт дип атыйлар. Шул хезмәтләрне укыган кешедә руслар алга киткән, зур-зур шәһәрләрдә яшәгән, ә төркиләр исә тирмәләрдә генә гомер кичергән икән дигән ялгыш тәэсир кала. Бу нәрсә чеп-чи ялган. Ләкин сүзне бу юнәлештә озынга сузмыйк. Руслар, чыннан да, күршеләре — төркиләр белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәгәннәр. Аларда да, төркиләрдәге кебек үк, бер-береңә карата көнчелек көчле булган. Аларның менә шушы тискәре сыйфаты үзара чарлану чорын да үткән.

Көнчелек хисе бер-береңне күрә алмау сыйфатын үстерә килгән. Дөрес, бу сыйфат теге яки бу күләмдә һәрбер милләткә хас. Шуңа күрә аны бары тик татарга яки руска гына хас сыйфат дип карарга ярамастыр. Әмма шунысы бар, кайбер милләтләр ул чирне җиңел кичергәннәр һәм аны милли аң, уртаклык тойгысы үсә бару белән җиңгәннәр. Руслар исә шушы көнчелек аркасында, үзара ызгышып-сугышып, монголлар коллыгына да эләгәләр. Ләкин шул ук Алтын Урда аларга,

көнчелек авыруыннан арындырып, милли рус дәүләте төзергә дә булыша.

Ә менә татарларны бу чирдән арынуга ярдәм итә торган андый фактор булмый. Киресенчә, әлеге сыйфатны тагын да көчәйтүче сәбәпләр барлыкка килә. Шундыйлардан берсе — үсеп, ныгып бара торган Рус дәүләтенең, көнчелек тойгыларын көчәйтә барып, татар ханнарын, морзаларын үзара сугыштырып, аларның үзара дошманлыгын иң югары дәрәҗәгә җиткерергә омтылуы, шул юнәлештә зур тырышлык куюы.

Әлбәттә, мондый «нечкә» эшне башкара белү үзе зур бер сәнгать. Аның нигезен татарлар үзләре салган. Ә менә аны иң югары ноктасына Алтын Урда ханнарының өйрәнчеге саналган рус кенәзләре, бигрәк тә Мәскәү кенәзләре җиткерә.

Шулай итеп, көнчелек сыйфаты русларда тарихи вазгыять аркасында юкка чыгарыла, ә татарда ул халыкның мөстәкыйльлеген гүргә кертүче сәбәпләрнең берсенә әверелә. Шулай итеп, татарлар үзләрен үзләре ашаган булып чыга. Шулай булгач, монда русларны гаепләргә урын бармы? Билгеле бит, һәр халыкның да дошманнары, аны юк итәргә омтылучылар була. Ләкин берәүләре үзләрендә моңа каршы көрәшерлек көч таба, ә икенчеләре исә моны булдыра алмый.

Сүз уңаеннан милләтебезнең тагын берничә сыйфатын күздән кичерик. Шул сыйфатларның берсе — масаючанлык. Әйе, бу сыйфат көнчелеккә «ияреп үсә». Бу ике сыйфатны хәтта бер-берсенең дәвамы итеп карарга да мөмкин.

Шулай да көнчелек һәр милләтне дә масаючанлыкка китерми. Бу нәрсә — хаким милләтләргә генә хас күренеш. Мөстәкыйль булмаган милләт исә тик үзара ызгышып-талашып кына яши. Ул күкрәк кага, үзенең кем икәнлеген күрсәтү, исбатлау тойгысы белән яна. Татарның күкрәк кагардай заманы күп булган, әлбәттә. Һәм, күрәсең, ул моны кирәгеннән артык эшләгән.

Баштарак бу, әлбәттә, үзара масаешу гына була. Ул төрле кәсептәге кешеләрдә төрлечә чагыла. Сәүдәгәрләр, әйтик, үзләренең ни рәвештә уңышлы эш алып бара белүләре, алыш-бирештәге маһирлыклары белән, һөнәрчеләр исә үзләренең осталыгы, власть ияләре дан-шөһрәтләре белән мактана торган булган.

Билгеле, һөнәр кешесенең мактануы табигый нәрсә. Бу шулай булган һәм моннан соң да шулай булыр. Тик менә шунысы яман: ил белән идарә итүче хакимият әһелләренең масаюы, мактануы милләткә зарар итә, илне фаҗигагә китерә.

Без күп вакыт бәйсезлегебезне югалтуда рус патшаларын, бигрәк тә Явыз Иванны гаеплибез. Әлбәттә, ул вәхшине мактарлык урын юк. Халкыбызга аннан да күбрәк зыянны бирәү дә китермәгәндер. Ләкин безнең үзебезнең дә ил язмышы өчен җаваплы кешеләребез булган бит. Алар да үзләренең хаклы бәясен алырга тиешләр.

Әгәр дә без масаюны тискәре милли сыйфат итеп күрсәтәбез икән, монда сүз читек һәм кәләпүш тегүдә ике һөнәрченең кайсысы остарак булуы турында бармый. Моннан милләткә бернинди дә зыян тимәгән. Бирердә сүз югары катлауларның үзара масаешуы, үзара хакимият бүлешә алмыйча, уяулыкларын югалтуы, хәтта нинди батыр халык булган татарларны да дошманга каршы сугышка тиешенчә оештыра алмаулары турында бара.

Ханлык башкаласы Казан каршында ике еллап Свияжск крепостен салалар, ә морзалар, ханнар бу вакытта масаешу, үзара ызгышу-талашу белән мәшгуль булалар. Бәлки, инде шул вакытта ук татарларның милли дәүләте, тарих тарафыннан һәлакәткә дучар ителгән Казан ханлыгының сәгате суккан булгандыр? Бәлки, моңа югарыда телгә алынган тискәре сыйфатлар сәбәп булгандыр? Тарихчы М. Худяков, мәсәлән, монда башка сәбәпләрне дә китерә. Аныңча, та-

тарлар, картайган милләт буларак, яңарак формалашкан руслар белән көч сынашканда табигый рәвештә оттырганнар булып чыга. Ләкин биредә татарларны — карт, ә русларны — яшь халык дип әйтү һич тә урынлы түгел. Чөнки славяннар һәм төркиләр дә, бер-берсе белән аралашып, һәрвакыт кан яңартышып килгәннәр. Шуңа күрә аларның берсен дә карт яки яшь дип әйтү дөреслеккә туры килмидер. Аларның биологик яктан тәңгәллекләрен, минемчә, Л. Гумилев бик дөрес билгеләгән...

Җиңелүнең төп сәбәпләре башка булса кирәк. Шул ук М. Худяков сүзләренә караганда, Казан ханлыгы мәйданы 300 мең квадрат чакрым булып, күп еллар буе ул үзенең җирен арттырырга омтылмаган. Русларның Мәскәү кенәзлеге исә үз җирен елдан-ел арттыра килгән. Аңа һаман җир җитмәгән. Тиз арада аның җире Казан ханлыгы белән тигезләшеп, тора-бара аны узып та киткән.

Бу ни өчен шулай булган соң? Җавап бер генә: татарлар хуҗалыкны интенсив рәвештә алып барырга өйрәнгәннәр. Шул сәбәпле үзләренә мул тормыш төзегәннәр. Аларга инде кеше җире кирәк булмаган. Сугышып тормагач, татарларның, хәрби осталык һәм әзерлекләре дә кимегән булса кирәк. Тора-бара сугыш алып бару мөмкинлекләре дә саеккан. Халык исә күбрәк һөнәрчелек, сәүдәгәрлек кәсебе белән мәшгуль булган. Татар милләте картаймаган. Ул экономик яктан ныгыган, һәм чыннан да М. Худяков әйткәнчә, үз-үзеннән канәгать төстә ниндидер тынычлану халәтенә чумган. Идарәче даирәләрне исә хәрби эшләр кызыксындырмый башлаган. Алар бу өлкәдәге яңалыкларны үзләренә кертергә ашыкмаганнар һәм нәтиҗәдә артта калганнар. Казан хөкүмәтенең гаскәре бик аз санлы булуы да юкка гына түгелдер. Күрәсең, бик тиз генә гаскәр җыю өчен мөмкинлекләре дә калмаган булгандыр.

Яңа дәүләт булып формалашып килгән Мәскәү Русе исә үсүнең төп яшәү чыганагы итеп сугышларны сайлаган. Ул баштарак үз тирәсенә барлык рус кенәзлекләрен җыя, аннары чит җирләргә күз ата башлый. Шул рәвешчә биредә хуҗалык эшләрен алып бару турында уйлаудан бигрәк, чит дәүләтләрнең җир-байлыкларын тартып алу хакында кайгыртуны өстен күрә. Гомумән, бу чорда сугыш алып бару Мәскәү Русенең яшәү рәвешенә әверелә. Нәтиҗәдә, мондагы халык хуҗалык эшләрен интенсивлаштыру ысулларын үзләштерә алмый. Аңарга бер җирдә иркенләп яшәргә мөмкинлек тә бирмиләр, аны яңадан-яңа җирләргә куалар. Шулай итеп, рус крестьянына көчләп диярлек үзенчәлекле яшәү рәвеше тагыла. Моның, әлбәттә, җир арттыру, яулап алуларны дәвам иттерү өчен файдасы гаять зур була. Рус империясенең барлыкка килүендәге императив көч — энә шул экстенсивлыкның яшәү рәвешенә әверелүендә.

Моның руслар өчен, файдадан бигрәк, зыяны да күп була. Чөнки ул милли характерда чаманы белмәү хисен үстерә. Шулай итеп, татарларның бу заманда санау, үлчәү белән мәшгуль булуына контраст рәвештә русларда икенче төрлерәк милли сыйфат үсеп китә.

Әгәр дә Казан ханлыгы белән алып барылган тарихи көрәштә руслар җиңеп чыкмаган булса, бәлки, аларга моның файдасы күбрәк тә тигән булыр иде. Сугышу, җир яулау, басып алу гадәте урынына эшчәнлек сыйфатлары үскән булса, руслар цивилизацияле дөньяга башкачарак килерләр, бу юлда уңышка да күбрәк ирешерләр иде. Аларга бәлки Көнбатышка «тәрәзә уярга» да туры килмәгән булыр иде.

Чыннан да, әгәр дә руслар үз милли территорияләрендә, үзләренә генә хас яшәү рәвеше булдырып, халыкның бөтен осталыгын яхшы һәм нәтиҗәле хуҗалык итү ысулларын үзләштерүгә юнәлтсәләр, аларның тарихи язмышы башкачарак булыр иде. Чөнки алар био-

логик яктан икенче сортлы халык түгелдер. Нигә соң әле Көнбатышка тәрәзәне руслар уеп чыгарга тиешләр? Нигә ул тәрәзәне Көнбатыш үзе уймый?

Мәгълүм булганча, хәтта М. Ломоносов та Россиянең байлыклары Себер хисабына үсәчәк дип инанган. Хәтта зур акыл иясе булган әлеге кеше дә хуҗалык итүнең экстенсив ысулларын хуп күргән. Ә бит ул, фән әһеле буларак, башкачарак фикер йөртергә тиеш иде.

Юк, татарның җиңелүе — ул аның көчсезлеге генә түгел. Ул көрәштә руслар үзләре дә җиңелә. Чөнки Казанны яулап алу нәтиҗәсендә русларда экстенсив ысул белән яшәү милли характер һәм фикер йөртү рәвешенә әйләнә. М. Горькийның бер герое авызыннан әйттерелгән «без аларны юкка гына җиңдек, алар бездән яхшырак» дигән сүзләре дә, бәлки, әлеге шул экстенсив яшәү рәвеше һәм фикер йөртү ысулларыннан уфтану дип аңларга кирәктер?

Шик юк, татарның тарихи җиңелүенә аның холкындагы көнчелек, үзара тыныша алмау, масаю, тәкәбберлек кебек тискәре сыйфатлар гына сәбәпче булмагандыр.

Монда татарларның күршеләренә артык ышанган булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Мәскәү кенәзләренең мәкерле сәясәтен тиешенчә аңлап бетерә алмаганнар, күрәсең. Татарның җиңелүе аның милли сыйфатларына гына бәйле түгел. Әмма ул сыйфатларның беренче урында торганлыгын да инкяр итеп булмастыр.

Инде татарларның коллык дәверендәге сыйфатларына тукталып үтик. Алар элеккечә каламы, яки аларга яңа сыйфатлар да өстәләме? Бу турыда без инде азмы-күпме сүз алып барган идек. Сүз уңаеннан шунысын да искәртик, сыйфатларны бүлгәндә ызанны тик шартлы рәвештә генә салып булачак.

Вакытлар үтү белән татарларның эшчәнлеге, холкы-фигыле дә үзгәргән. Моңа, әлбәттә, беренче чиратта, аларның яшәү шартларының кискен рәвештә үзгә-

рүс сәбәп булган. Алар бер-ике ел эчендә буйсындырылган халык статусына күчкәннәр. Үз ватаннарында яшәүләренә дә карамастан, аларга «инородецлар» дигән исем тагылган. Шул рәвешчә, алар үзләренең мөстәкыйльлек психологиясен үзгәртергә, җимерергә тиеш булганнар. Әле кичә генә мөстәкыйль булган, бүген исә колга әверелгән халыкны мыскыллау рәвешендә «князь» дигән кушамат белән атый башлаганнар. Янәсе, син бүген үзеңнең кем икәнлегеңне бел! Икенче сәбәп итеп рус көхүмәтенең татарларны да колонизацияләү процессына кушып җибәрүен күрсәтергә кирәк. Яңа гына яулап алынган җирләргә инде руслар белән бергә мәҗбүри рәвештә татарлар да җибәрелә торган булган. Димәк, татарлар да телиме-юкмы экстенсивлык алымнары белән эш итеп яшәүгә җәлеп ителәләр. Ә бит бу хәл аларда эшкә һәвәслек сыйфатының кимүенә китергән.

Тарихи әдәбиятта без «йомышлы татарлар» дигән төшенчә белән очрашабыз. Ә бит бу катлам татарларның яшәү рәвеше башкаларныкыннан шактыйга аерыла. Алар кем файдасына күбрәк эшли: рус хөкүмәтенәме, әллә үз милләтенәме? Моңа ачык кына җавап юк. Ләкин шушы катламның барлыкка килүе һичшиксез татарларның яңа яшәү шартларына яраклашырга тырышуына бәйле. Шикләнмичә әйтергә мөмкин, бу үзенчәлек татар халкындагы яшәү көченең бер чагылышы. Татарлар үләргә җыенмый. Алар яшәргә, исән калырга йөз тота.

Ләкин ничек? Әлбәттә, зәгыйфьләнгән, имгәнгән, гарипләнгән, башкалардагы тискәрелекне үзенә сеңдергән хәлдә. Мөстәкыйльлеге кимү халыкның инициативасына да кире йогынты ясаган. Шулай итеп, инициативасызлык күп вакыт милли холыкка да сеңә килгән.

Татарлар аракы, хәмер эчмәгән. Бары тик югары катлау кешеләре генә ул эчемлек белән аз-маз «шаярган» булырга мөмкин. Ни дисәң дә, алар бит руслар

белән күптән аралашып, кайбер очракта хәтта туганлашып та яшәгәннәр. Ә менә гади халык исә ул нәрсәгә бирелмәгән. Коллык дәвере килгәч, бу чир милләтебезне хроник авыруга сабыштырды.

Коллык психологиясе — яңа төшенчә түгел. Гражданлык җәмгыятенә кучкәнче буйсыну рухы һәр илгә дә, һәр җиргә дә, һәр кешегә дә хас булган. Мондый психологияне феодаль система үзе тәрбияли.

Тәркиләргә килсәк, заманында сугышчан кабиләләр буларак, алар кирәгендә буйсынуны яшәү рәвеше, тормыш кагыйдәсе итеп кабул иткәннәр. Татарлар да җиңелә белмәүләре белән үзләренең батырлыгына һәм яшәү кануннарына буйсына белүгә бурычлы.

Әйтергә кирәк, биредә сүз милләтнең үз эчендә, үзара мөнәсәбәтләрендә чагылыш тапкан сыйфаты турында бара. Татарлар үз-үзләрен һәрвакыт ирекле, мөстәкыйль итеп хис иткән. Чөнки алар, халык буларак, беркайчан да, беркемгә дә буйсынмаган.

Бу хис тора-бара үзгәргәнме соң? Атаклы миссионер Ильминский, мәсәлән, татарлар үзләрен һаман да хаким халык итеп хис итәләр, дип язып калдырган! Бу күрәсең, чыннан да, шулай. Физик яктан коллык хәленә куелган булсалар да, татарларның рухы сынмаган. Алар үзләрен һаман да мөстәкыйль дәүләтле милләттәй хис итә биргән. Дәүләтчелек хисе, күрәсең, татарның канына сеңгәндер.

Ләкин тормышта аңа инде буйсынып яшәргә туры килгән. Ул рус хөкүмәтенә, аның җирле администрациясенә буйсындырылган. Күпләп салым түли килгән. Мәҗбүри эшләргә тартылган. Рус армиясенә хезмәткә алынган. Монда аның рухын сындырырга тырышканнар. Бу уңайдан Л. Толстойның «Балдан соң» дигән хикәясен искә төшерү дә җитә. Ә инде шуның өстенә төрле хатларны, язма истәлекләрне, бәетләрне күздән кичерсәк, моның ни дәрәҗәдә дөрес икәнлегенә ышанырбыз. Теләсә-теләмәсә дә татарга акрынлап изелгән,

буйсындырылган халык психологиясе дә сеңгән. Күп вакыт аның фикер йөртүендә, сөйләшүендә русларга ярарга тырышу, иярү сизелә. Телиме-юкмы ул хаким милләт русларның өстенлеген танырга мәҗбүр булган. 440 ел буенча Россиянең рәсми пропагандасы татарларны халык буларак кимсетеп килде. Алай гына да түгел, бигрәк тә Ак Урда чорын русларның тарихи яктан артта калуына сәбәпче итеп күрсәтү сәясәте алып барылды.

Бу нәрсә татарларның эчке кичерешләренә ничек тәэсир иткән соң? Әлбәттә, аның тәэсире төрлечә булган. Элек-электән балда-майда йөзеп яшәргә өйрәнгән татар морзаларының, хан нәселенең бер өлеше башта ук рус-ка хезмәткә күчә һәм хәтта христиан динен дә кабул итә. Алга таба әнә шулардан туган мөртәтләр рус идеясен үткәрүдә иң агрессив эш итүчеләр булып китә. Алар бүген дә шактый дәрәҗәдә интенсив эшлиләр.

Чукынырга, халкына хыянәт итәргә теләмәгән морзалар иң кыен шартларга куела. Бигрәк тә Петр I башлаган сәясәт кырыс була. Шуның нигезендә әлеге морзаларны, крестьяннар белән тигезләп, лашманлык (мәсәлән, урман кисү, аны ташу, эшкәртү, кораблар төзү) эшенә тарталар. Гаять авыр шартларда, юньләп ашамыйча, ач-ялангач килеш эшләү була бу. Ләкин шушы катлауның күпчелек өлеше әлеге сынауга бирешми. Әмма рус хөкүмәтенең рухны сындыруга юнәлдерелгән бу чарасы бөтенләй үк нәтиҗә бирмәгән дип тә әйтеп булмый. Руслар азмы-күпме үз дигәннәренә дә ирешкән. Шунысы да бар, әле «чабаталы морзалар» аларның язмышлары әлегәчә фәндә тиешенчә өйрәнелмәгән. Монысы да тарихчыларның бурычы булып кала.

Гади татар халкы ничек яшәгән соң? Билгеле булганча, көчләп чукындыру кампаниясе әллә ни зур уңыш китермәгән. Бүгенге көндә көчләп чукындырылганнарга караганда, чукынуга үзләре ризалык биргәннәре күбрәк булса кирәк. Бу очракта чукынган татарлар өчен

билгеле өстенлекләр, шул исәптән үз динендә калган татарлар өстеннән хакимлек итү хокукы бирелә килүен дә искә алырга кирәктер. Чукынган татарлар, гомумән, үзләрен җиңелрәк хис иткәннәрдер дип уйларга нигез бар.

Казан тирәсеннән сөрелгәннән соң да татарлар христиан руханилары тарафыннан эзәрлекләнәләр. Мондый басым арта барган саен татарлар үзләренең борынгыдан яшәп килгән җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булганнар. Аларның күбесе Көнчыгышка юнәлгән. Яңа җирләрдә кача-поса гына авыллар салып, тормышны яңабаштан башлап җибәргәннәр. Шактый күп татар башкорт якларына барып урнашкан. Әлбәттә, аларны монда да талаганнар, буйсындырганнар. Көрәсең, чукындыру эше дә туктатылмаган. Шул якларда хәзер дә очрый торган керәшен авыллары моның бер дәлиле булып тора.

Язучы Ж. Рәхимов, ул авылларның тарихын өйрәнүгә шактый зур өлеш кертеп, мин әйткән фикерләргә тиешле дәлилләрне булдырды да инде. Ләкин әле бу эш тә ахырынача җиткерелмәгән. Татарстан, Башкортстандагы, шулай ук күршедәге башка республикалар һәм өлкәләрдәге татар авылларының тарихы тулысы белән тикшерелеп бетсә, халкыбыз өчен бу бик зур файда булыр иде.

Шул рәвешчә, яңа төбәкләргә килеп урнашкан татарларның мөстәкыйльлеге шактый нык сакланган. Гомумән, андагы татарларда милли гадәтләр һаман да яши бирә.

Күп еллар дәвамында барган үзгәрешләрдән соң татарлар күпчелек урында руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, мукшылар белән аралашып яши торган булып киткәннәр. Татарларның башка халыклар белән аралаша, аңлаша белә торган бик борынгы заманнардан килә торган сыйфаты аларның тормышын шактый җиңеләйткән. Шунысы да бар, татарлардан күршеләре

күп кенә файда да күргән. Хуҗалык итүнең күп кенә ысулларына алар шул татарлардан өйрәнгәннәр.

Бу урында татарларның әлеге халыклар белән байтак кына уртак сыйфатлары булуы турында да бер-ике сүз әйтеп китү зыян итмәстер. Андый уртаклыкның чагылышы бу телләрдә уртак сүзләр булуда күренә. Әйтик, ат җигү дирбиясе исемнәре бу халыкларга татар теленнән кергән. Охшаш әйтемнәр дә очрый. Бу нәрсә холыклар уртаклыгы, эчке кичерешләрнең якынлыгы турында сөйли. Болар да әле бездә тиешенчә өйрәнелмәгән.

Күп гасырлар буенча татарларның холкында мөстәкыйльлек рухы сакланып килгән һәм ул яшәү рәвешендә чагылыш тапкан. Биредә халкыбызның аеруча түземлелеген күрсәтергә кирәк. Әйе, татарлар эшчән генә түгел, алар искиткеч түземле дә. Моны сугыш вакытында командирлар еш билгеләп үтә, басым ясап әйтә торган булалар. Бу сыйфат, гадәттә, башкаларга да күчкән. Шулай итеп, күршеләре татарлардан түземлелеккә дә өйрәнә килгәннәр. Татар кешесе беркайчан да акырып-бакырып йөрмәс. Ул тыныч кына, түземле генә үз эшен эшләр.

Тик шулай да коллык дәверендә татарның өлкәннәргә, зурларга буйсыну сыйфаты кирәгеннән артып киткән. Түрәләргә, начальникларга, хакимияткә буйсынуны татар күп вакытта өстән төшкән әмер дип кабул итә килгән.

Совет чорында бу сыйфат тагын да тирәнәйде. Тора-бара инде хакимият әмере генә түгел, партия әмере дә шулай кабул ителә башлады. Билгеле, бу нәрсә кинәт кенә урнашмый. Совет властеның татарларга каршы берничә мәртәбә көч куллануын искәртеп үтми булмый. Ул нәрсәләр татарларның рухын җимерү максатында эшләнә. Бу уңайдан һәркемгә дә билгеле булган сәнәкчеләр восстаниесен генә искә төшерик. Инде бүген аның Совет властеның крестьян халкын бөтен-

ләйгә ач-ялангач калдырырга тырышуына каршы протест буларак күтәрелгән фетнә икәнлеген беләбез. 1921 елгы ачлык та корылык афәте генә түгел, ул большевикларның аңлы рәвештә эшләнгән акциясе. Менә шуларга каршы күтәрелгән дә инде сәнәкчеләр. Ләкин властьлар аны гаять рәхимсез рәвештә бастыралар. Шул замандагы бер күренекле чекист Б. М. Эльцин, аны Россия Президенты Б. Н. Ельцинның агасы диләр, әлеге фетнәне бастырганнан соң Татарстан республикасын гомумән төзетмәскә тырышып йөри. Әйтергә кирәк, әле ул көннәрдәге корбаннарның саны тулысынча ачыкланмаган. Шулай да фаҗиганең зурлыгын күз алдына китерү өчен бер венгрлар отрядының Чистай өязендәге ерткычлыгын күздән кичерү дә җитә. Анда терелэтә күмү, утта яндыру, авыл-авылы белән яндыру дисеңме — барысы да булган.

Тагын шундый бер массакүләм чара куллану коллективлашу елларында үткәрелә. Дистәләгән, йөзләгән татар гаиләләрен туган җирләреннән Себер якларына сөрүләр татар милләтенең җелеген суыруга тиң булган. Чөнки репрессиягә, башлыча, иң эшлекле, иң булдыклы, иң тапкыр кешеләр эләгә. Бу инде милләтнең генетик сыйфатларын яхшыртмый. Киресенчә, аның генофондын кимерә. Татарга курку, шомлану хисе керә. Халыкта кычкырып сөйләшүләр бетә, пышылдашып сөйләшү гадәте керә.

Татар зыялыларының эзәрлекләнүе дә шулай ук милли сыйфатларның яхшыруына булышмый. Ул курку хисләрен тудырып кына калмый, татарларның идеяләр тудыру, мәдәниятне үстерү мөмкинлекләрен дә киметә. Гомумән, совет чорында рәсми пропаганда да, властьларның реаль эшләре дә татарларны кыерсытуга, кимсетүгә юнәлдерелгән була. Татар булып яшәү рухи яктан да, матди яктан да авырлаша. Шунлыктан халыкта татарлыктан качу хисе көчәя. Моның бер чагылышы — татар исемен болгарга алыштырырга омты-

луда күренә. Монда шулай ук башка милләтләр арасына кереп югалырга тырышу да үзен нык сиздерә. Шуңлыктан читкә киткән татарлар җирле халык белән туганлашалар. Нәтиҗәдә алардан туган балалар инде татар булмый һәм үзенең татар булуына рәнҗеп яшәми. Руслар белән аралашу бигрәк тә совет чорында нык көчәйде. Элекке СССРдагы милләтләр арасында уртак никахлар саны ягыннан татарлар беренче урында тора. Шәһәр татарны йөзләп кенә түгел, меңәрләп, йөз меңләп йотып кына тора. Әле мондый хәлнең бүгенге көндә дә әллә ни үзгәргәне юк. Татар һаман да иң интернациональ рухлы милләт булып кала бирә.

Моның тагын бер сәбәбе бар. Монысы аның, бәлки, әле иң мөһимедер дә. Ул да булса властьларның халыкларны, шул исәптән татарларны диненнән читләштерүендә. Билгеле булганча, ислам дине, мөселманлык татарларның тарихында искиткеч зур роль уйнаган. Алай гына да түгел, татарлар ислам милләте булып оешканнар. Исламга таянган милли кичерешләрне чагылдырган мәдәният һәм әдәбият булдырганнар. Гомумән, татар халкының милли холкын формалаштыруда ислам диненең әһәмиятен без әле тиешенчә бәяләп бетермибез булса кирәк.

Ә бит тарихның иң авыр чорында да ислам дине татарларны милләт буларак саклап калды. Әгәр дә татарлар шушы дингә турылыклылык саклап кала алмаган булсалар, алар инде бүгенге көндә яшәмәсләр дә иде. Шушы дин аларны башка халыклар белән кушылудан, бүтән дингә күчүдән һәрвакыт саклап килде. Шуңлыктан дингә, аерым алганда ислам диненә булган һөҗүм, мәчетләрне җимерү, Коръәннәрне яндыру милләтнең үзен яндыруга тиң дип каралган.

Аллага ышанмаган кешеләр өчен башка дин вәкилләре белән туганлашу бер нәрсә дә түгел. Ә инде интернационализм идеясе, милләтләр барыбер бөтенесе кушылып бетәчәк, дип тукып торган рәсми пропаганда

динсезләргә ирекләрне мул бирә. Әхлак, алладан курку дигән нәрсә бетә. Йөзсез, үз шәхесе булмаган кешеләр арта. Дин генә түгел, аның белән бергә тел дә бетүгә йөз тота. Кеше милли мохиттән аерыла. Ә аерылгач, аңа тик бер юл — русча гына сөйләшергә кала. Ул инде татарча белми һәм шуның белән хәтта горурлана да. Татар телен, татар милләтен яклаучылардан ачыктан-ачык көлүчегә әйләнә.

Татарлардан шәһәрдә яшәгән өлешендә әнә шундыйлар даими ишәя бара. Шул ук вакытта шәһәрләр саны да арта килде. Бигрәк тә Хрущев заманында бөек төзелешләр, чирәм җирләрне үзләштерү кампанияләрендә милләткә битараф кешеләр күбәйде.

Ә милли сыйфатларга килсәк, алар да интернациональ сыйфатлар белән алышына килде. Бу исә үз нәүбәтендә эчүчелеккә, бозыклыкка, фахишәлеккә юл ачты. Милләтебез төрле халыклардагы тискәре сыйфатларны җыеп алды, ә үзендәге иң изге хисләрне буды.

Татар таркалды, чәчелде. Күп җирдә үзенең яшәү рәвешен, динен, телен онытты. Татарстанда хәзерге вакытта татарларның нибары дүрттән бере, ягъни 1 млн. 800 меңе генә яши. Аның да 70 проценты шәһәрләрдә урнашкан. Татарларның 1 млн. 300 меңе Башкортстанда. Монда да аларның 40 процент чамасы гына авылда яши. Халкыбызның ярты миллионлабы күрше-тирә өлкәләрдә гомер итә.

Аллага шөкер, әле татар авыллары бетмәгән. Ләкин шунысы кызганыч, ул инде чын татар авылы түгел. Милли йолаларга, гореф-гадәтләргә анда урын калмаган диярлек. Аулак өйләр ясау юк, кичке уеннарны да белмиләр. Бик күп авылда гармун тавышлары бөтенләй яңгырамый.

Болар милли сыйфатларны саклап калуга йогынты ясыймы икән соң? Әйе, шәһәрдә дә, авылда да кайбер тискәре якларыбызның артуы, ишәюе өчен мөмкинлекләр туып кына тора. Һәркайда диярлек эчүчелек хөкем

сөрә. Татар татар белән тыныша алмый. Электән канына сеңгән көнчелек сыйфаты һаман көчәя бара. Шул ук вакытта масаю, мин-минлек кебек сыйфатлар да үзенлык сиздерә.

Милли уяну башлангач, соңгы елларда тормышыбызда күңелгә хуш килердәй үзгәрешләр барлыкка килде. Элекке таркаулык милли бердәмлек белән алышына башлады. Татар хәзер үзенең ерак тарихына мөрәҗәгать итә, үзен борчыган сорауларга җавап эзли.

Ә бу исә искиткеч мөһим нәрсә. Чөнки тарихтан бүгенге сорауларга җавап эзләү — ул үзебезнең татарларга хас милли холыкны, үзенчәлекне өйрәнү дигән сүз. Ә холыкны өйрәнү исә татарның тарихи җиңелүенә сәбәп булган сыйфатларын ачыкларга ярдәм итәр.

Әгәр дә бүгенге көнне азатлыкка, бәйсезлеккә таба йөз тотканбыз икән, без үзебезнең милли холкыбызны яхшы белергә тиешбез. Аның гүзәл якларын да, тискәреләрен дә ныклап тикшерергә мәҗбүрбез. Милли аңны торгызу шуны таләп итә.

Әйе, татар милләте уянып килә. Ләкин әле тәмам уянып бетмәгән. Ул әле үз мәнфәгатьләрен тулысынча аңлап җиткерми. Тизрәк аңласын иде ул аларны! Тизрәк уянсын иде ул!

Югыйсә милли бәйсезлекне кире кайтару өчен килеп туган әллә нигә бер була торган тарихи шанстан, мөмкинлектән тизрәк файдаланып калмасак, без бәлки мәңге кол хәленнән котыла алмабыз.

Татар бүген коллык богауларын өзәргә үзенең искиткеч оешу сәләтен торгызырга тиеш. Моны эшләмәсәк, уңайлы вакытларны кулдан ычкындыруыбыз мөмкин.

Шөкер, татарның милли холкы исән калган. Гүзәл сыйфатлары әле бөтенләй үк югалып, җуелып бетмәгән. Шуларны бергә туплау вакыты җитте. Әгәр дә шул гүзәл сыйфатларны бергә җыйнасак, без азатлыгыбызга, бәйсезлегебезгә һичшиксез ирешербез.

ТАТАР КЕМ ҖИРЕНДӘ ЯШИ?

1. Татар үз җирендә яши.

Күрәсез, кадерле укучым, бу сорауга бик кыска да җавап биреп була. Ләкин мондый җавап һич кенә дә тулы була алмый. Чөнки аның беръяклы икәнлеге ачыктан-ачык күренеп тора.

Без милләтебезнең җир шарында чәчелеп яшәгәнлеген яхшы беләбез. Соңгы елларны безгә АКШ һәм Канададагы, Япония һәм Австралиядәге, Финляндия һәм Германиядәге, Кытай һәм Төркиядәге милләттәшләребез белән аралашып яшәргә мөмкинлек туды. Шуннан без, милләт буларак, үзебезнең йөзебезне тулырак төсмерли башладык.

Ә бит моңарчы без тик Үзбәкстан, Кыргызстан, Казагыстан, Төрекмәнстан һәм Таҗикстандагы татарларның гына хәл-әхвәлләрен белеп яши идек. Шушы илләр белән азмы-күпме бәйләнештә тора идек. Хәзер горизонтыбыз киңәйде, мөмкинлекләребез артты. Милләтебезнең яшәү рәвешен киңрәк күзаллый алабыз.

Чыннан да, бөек милләт икән татар. Үткән тарихы белән генә түгел, бүгенге потенциалы белән дә. Бер-ике фактка гына игътибар итик. Күптән түгел генә гасырның бөек балет остасы, гений дип билгеләнгән Рудольф Нуриев үлде. Аны Парижда җирләделәр. Ә бу кеше үзен гомер буе татар итеп хис иткән икән. Ул, татар буларак, икенче балет йолдызы, Лондон балетының труппа җитәкчесе Ирек Мөхәммәдовка сәнгатьтә үз урынын алырга юл ачышкан икән... Балет дөньясында тагын шундый берничә йолдыз бар. Алары да милләтебез горурлыгы.

Шахматчыларны алыйк. Монда да бер төркем татар гроссмейстерының шахмат дөньясын шаулатканын күрербез. Җир шарының иң яшь гроссмейстеры Гата Камский үзе генә дә ни тора.

Инде кино сәнгатенә күз ташлыйк. Вадим Абдрашитов, Булат Мансуров тудырган фильмнар бөтен дөньяга шаулады. Мәшһүр кинойолдыз Сергей Шакуров та үзен татар итеп хис итә икән. Шул турыда ул инде күп тапкырлар әйтте дә. Мин инде фән дөньясын әйтеп тә тормыйм. Роальд Сәгъдиевнең исеме үзе генә дә ни тора!

Сез, хөрмәтле укучым, миңа, болар бит берсе дә татарның үз җирендә яшәгәнлегенә дәлил түгел, диярсез. Ләкин мин моңа җавап итеп, әгәр дә татар шундый ачы язмышлы милләт булмаса, аның менә шундый дөньякүләм шөһрәтле кешеләре дә үз җирендә, үз милләтенә хезмәт итеп яшәгән булыр иде, дип әйтер идем. Мин атап киткән бөек шәхесләр үзләрен туган җиргә, ата-баба туфрагына нык бәйләнгәнлекләрен тоя килделәр. Бәлки, нәкъ шул туган туфрак, тарихи ватан аларга илһам биреп, тик татарга гына хас холыклы үз шөгыльләре аркылы дөньяга бәян итәргә мөмкинлек тудыргандыр.

Әйе, әгәр дә татар үзенең тарихи ватанын җуйган булса, аны тоеп яшәмәсә, чегәннәр кебек илсез-җирсез калса, бәлки, аның әнә шундый бөек ул һәм кызлары да булмас иде. Бүгенге болганчык заманда милләтебезгә җылы караштa булмаганнар, Татарстанның бәйсезлегенә аяк чалырга тырышучылар: татарлар үз ватаннарында яшәмиләр, алар Татарстанда тик 49 процент кына тәшкил итәләр, аларның дүрттән бере генә тарихи ватаннарында яши, дигән уйдырма тараталар.

Бу шулаймы соң?

Чыннан да, бүгенге Татарстанның 3 млн. 800 мең халкының тик яртысына якыны гына татар милләтеннән. Алар, чыннан да, милләтебезнең тик дүрттән берен генә тәшкил итә. Ләкин бу әле татарлар үз тарихи ватаннарыннан читкә таралышып беткәннәр, дигән сүз түгел. Татарстан — ул Мәскәү тарафыннан шартлы һәм субъектив рәвештә билгеләнгән административ

бирәмлек кенә. Татарның тарихи ватаны бүгенге Татарстан гына түгел. Борын-борыннан инде аның шундый ватаны Идел-йорт булып килгән. Әнә «Идегәй» дастанын гына ачып карагыз.

Әй Идел-йорт, Идел-йорт!
Идел буе имин йорт!
Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәгъзим кылган йорт,
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам биргән йорт,
Ҡендегемне кискән йорт,
Ҡерем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Ҡымыз эчкән котлы йорт.
Идел — Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Ҡазан — Болгар арасы
Ҡала белән тулган йорт.

Әйе, Идел-йорт — татар өчен тарихи Ватан. Татарстанга терәлеп Ульяновск һәм Самара өлкәләрендә 236 мең милләттәшебез яши. Инде Мари Республикасының Бәрәңге районын алыйк. Моның да 30 мең халкы бөтенләе белән дирлек татардан тора. Чувашиянең Батыр районы да Татарстан белән чикләшә. Монда да татарлар зур процент тәшкил итә. Алар да килмешәкләр түгел, үз җирләрендә, үз илләрендә яшиләр. Әстерханның үзендә генә түгел, аны ураган авыллар гел татарларныкы дисәк тә хата булмас. Царицын да «царь» атамасыннан алынган түгел, ә татарның «сары су» атмасыннан чыккан сүз. Волгоградтагы кечкенә Мечетка елгасы, Мамай курганында да безнең бабаларыбызның эзләре ярылып ята. Бүген исә Иделнең аскы ягында 40 мең татар яши. Самара, Сембер сүзләре дә, шул өлкәләрдәге авыл, елга исемнәре дә татар өчен ят түгел. Анда да ата-бабалары салган эзләр

калган. Чыннан да, әнә Җигули тавына гына карагыз. Ул бит, чыннан да, җигүле атны хәтерләтә. Ә бит нәкъ менә шушында 1223 елда безнең болгар бабаларыбыз монгол гаскәрләре белән беренче тапкыр очрашкан һәм аларны тар-мар иткәннәр.

Юк, Идел-йортта татар килмешәк түгел. Ул — аның үз Ватаны.

Инде Уралга күчик. Киров өлкәсе, Удмуртия Татарстанга терәлеп ук торалар. Малмыж шәһәренең яртысы, районы исә бөтенләе белән диярлек, безнең милләт кешеләреннән тора. Кайвакыт Киров өлкәсендә дә, бездә дә охшаш исемле авыллар очрый. Болар берсе дә очраклы хәл түгел.

Ижевск шәһәре бистәләрен тутырып татар яши. Монда милли рух хөкем сөрә. Ижевскидан бөтен Уралга диярлек татарча тапшырулар яңгырый. Мин аларны да татар җирләре дип әйтәсем килми. Удмурт халкының бу җиргә, аның табигый байлыкларына булган суверен хокукларын берәү дә инкяр итмәс. Ләкин бит монда борын заманнардан бирле шушы төп халык белән татарлар да яшәгән. Аларның гасырлар буе уртак, дус тормышта яшәгәнлегенә ике халыкның уртак атамасы булган «бисәрмән» дигән этник төркем дәлил булып тора.

Башкортстанда, аның Татарстанга терәлеп торган көнбатышында 1 млн. 100 мең милләттәшләребез яши. Алар үз җирләрендә, үз ватаннарында яшиләр. Пермь өлкәсендә 157,7 меңгә якын татар бар. Бу өлкәнең Барда районы тулысы белән татар-башкортлардан тора. Мондагы кешеләр саф татар тормышы белән яшиләр. Аларда халкыбызның башка җирләрдә инде онытылып бара торган кайбер гореф-гадәтләренә кадәр сакланган. Екатеринбург өлкәсендә 179 мең татар кешесе яши. Болар да шәһәрләрдә генә түгел, авылларда көн күреп, үзләрен милләтебезнең бер өлеше итеп тоялар.

Чиләбе өлкәсендә 219,7 мең, Оренбург өлкәсендә 151,4 мең татар кешесе яши.

Гомумән алганда, ике миллионнан артык татар кешесе үз җирендә Татарстанга терәлеп үк яши. Димәк, дүрт миллионга якын татар бер территориядә тупланып гомер кичерә.

Шулай булгач, хөрмәтле укучыларым, татарларның кем җирендә яшәгәнлекләрен бик ачык төсмерләргә мөмкин. Кыска гына итеп әйткәндә: татарларның күпчелеге үз җирләрендә яши.

2. Татар тагын кайларда гомер итә?

Әйе, Идел — Урал төбәге — татарның гомер иткән төп урыны. Ләкин аны ачы язмыш һәрвакыт иленнән куа килде. Аны көчләп патша хөкүмәте дә сөрде. Мәҗбүри ысуллар кулланып, Совет хөкүмәте дә план нигезендә татарны Карелиягә, Бурятиягә, Мурманскига һәм тагын әллә кайдагы җәһәннәмнәргә озата килде.

Татар һәрвакыт сөрелде-себерелде. Себердәге татарлар кем җирендә яши? Алар да үз җирләрендә, үз ватаннарында гомер итәләр. Кайчандыр төркиләрнең оясы булган Орхон-Енисей буйлары, чал Алтай да татарлар өчен ят җирләр түгел. Алар шунда төрки халык булып яралганнар, шушы җирдә үзләренең язмышларын билгеләгәннәр.

Себер ханлыгының хаким халкы татар булган. Ләкин ул беркайчан да үзенең өстенлеген камчы-корал белән раслап-ныгытып йөрмәгән. Башка җирле халыклар татарларга һәрвакыт ихтирамлы булганнар, аларны беркайчан да үзләрен изүче итеп санамаганнар.

Себердә бүген ике төрле татарлар яши. Аларның беренчесе — җирле халык, Себер татарлары. Красноярск, Тобол тирәсендәге татар авылларына күпләр соклана. Мәсәлән, Самара профессоры Ленар Васильевич Храмков шушы авылларның искиткеч чиста һәм пөхтә

булуына, ә халкының кунакчыл һәм тыйнак икәнлегенә аеруча басым ясап сөйли. Бу татарлар үзләренә хас диалектта сөйләшәләр. Чыгышы буенча шул татарлардан булган күренекле тел галиме академик Д. Тумашева шул диалектны өйрәнеп, күп кенә хезмәтләрен аңа багышлап, бу халыкның чын мәгънәсендә җирле халык икәнлеген исбат итте.

Икенче төр татарлар монда патша заманында сөрелгән, шулай ук Сталин дәверендә кулак рәвешендә куылган Идел-Урал татарларыннан тора. Туган-үскән җирләреннән сөрелгән татарларның шактый өлешен хәзерге көндә Төмән нефтьчеләре тәшкил итә. Бүген Себердә 100 меңнән артык татар яши. Аларның монда сөрелеп китерелгәннәре дә чит илдә һәм чит җирдә түгел. Алар үз милләттәшләренә килеп сыенган һәм инде алардан туган яңа буыннар шушы җирне үз ватаннары итеп саныйлар.

Калган татарлар кайларда яши соң? Алары, чыннан да, кеше җирендә. Иң күп татар, ягъни 648,8 меңе Үзбәкстанда яши. Казагызстанда 313,5 мең милләттәшебез бар. Таҗикстанда 80 мең, Кыргызстанда 70 меңнән артык татар бар. Алар монда кайчан һәм ничек килеп чыкканнар соң? Заманында төрки халыклар арасында бәйләнешләр бик тыгыз булган, әйтик, Алтын Урда чорыннан ук килә бу аралашу. Татарлар өчен бу җирләрнең, гомумән, беркайчан да ят булмаганлыгын әйтеп китү урынлы булыр. Ә инде бу халыклар, татарлар кебек үк, Россия империясе тозагына эләккәннән соң татарлар күпләп шушы җирләргә йөри, сәяхәт итә торган булганнар.

Татарлар монда сәүдәгәрләр, мәгърифәт нурын таратучылар булып килгәннәр. Кыргыз, казакъ арасында ислам динен тарату да татарлар тарафыннан эшләнгән. Гомумән, татарлар бик күпләп үзбәк, казакъ, кыргыз, төрекмән балаларын укытканнар. Соңрак монда газета-журналлар чыгарып, милли музыка һәм театр-

лар ачканнар. Бу очракта профессиональ казакъ музыкасына нигез салучыларның берсе Латиф Хәмиди белән казакъ сынлы сәнгатенә юнәлеш бирүчеләрнең берсе Бакый Урманче исемнәрен атау да җитә.

Җирле халыклар, яки төрки кардәшләр татарларны яхшы кабул иткәннәр. Авыр вакытларында аларга ярдәмгә килгәннәр. Әгәр дә татар шәкерте, казакъ даласына чыгып, балаларга дәрес укыткан икән, бу аның үз мәнфәгатенә дә хезмәт иткән. Ул монда үзенең матди хәлен җиңеләйтү нияте белән килгән. Кардәшләре исә аны кабул иткән, үз янына сыендырган. Аларга рәхмәтле булыйк. Татар һәрвакыт гаделлекнең кадерен белгән. Әгәр бүгенге заманда кемнәрдер, милләтара низаглар чыгарып, таякның бер очы татарга эләгә икән, без монда үзбәк, казакъ һәм башкаларны гаепләргә ашыкмыйк. Мөнәсәбәтләребезне бозмыйк. Безнең әле иртәгә дә шушы халыклар белән бәйсез, бердәм төрки гаиләдә яшисебез бар. Юк, татарлар беркайчан да үзләре яшәгән җирләрнең, андагы халыкларның дошманы булмаган һәм булмаслар да.

Татарлар төрки халыклар арасында гына түгел, башкалар арасында да тату яшиләр. Алар турында да берничә сүз әйтеп китү кирәктер. Сүзне Мәскәүнең үзеннән башлау дөрес булыр иде. Чөнки аның үзендә һәм өлкәсендә 183,5 мең татар яши. Аннан килә иң күп татар яшәгән җир — Украина. Монда 90,5 мең татар яши. Аларның бик күбесе шахтерлар, гомер буе авыр хезмәттә, михнәтле тормышта яшәгән кешеләр. Алар монда үткән гасырның 60 нчы елларыннан башлап күпләп килеп урнаша башлаганнар.

Татарлар шулай ук Литва һәм Польшада да яши. Бу илләрнең халыклары татарларга чыгышлары һәм диннәре белән ят. Шулай да Польша һәм Балтыйк буе дәүләтләрендә татарларга карата ихтирам зур. Анда татарның гомуми саны 11 меңгә якын. Литва һәм Польша җирләренә татарлар моннан 600 еллар элек килә-

ләр. Литваның бөек кенәзе Витовт аларны монда немец орденнарына каршы көрәштә ярдәм итү өчен чакыра. Шушы максат белән татарларның зур бер өлеше Җәләлетдин исемле гаскәр башлыгы җитәкчелегендә Алтын Урда ханы Туктамыш боерыгы буенча күчеп килә. 30 меңлек татар гаскәре Грюнвальд сугышында хәлиткеч роль уйный. Шушы сугыштан соң Витовт, рәхмәт йөзеннән татарларга дворян титуллары һәм җир бүлеп биреп, аларны бөтенләйгә монда калдыра. Алар һәрвакыт Польша һәм Литваның бәйсезлеге өчен батырларча көрәшәләр. Шушы җирдә үзләренчә тормыш корып, җир эшкәртеп һәм төрле кәсепләр үзләштереп, җирле халык белән дустанә гомер итәләр.

Татарлар күрсәткән иң соңгы батырлык үрнәкләренең берсе итеп, алардан торган хәрби частьларның 1939 елны Польшага немецлар бәреп кергәч, Варшаваны саклауга керткән өлешләрен күрсәтергә була. Поляклар татарларны ихтирам итәләр, аларны яраталар.

Бүгенге Польша һәм Литва татарлары инде телләрен югалтканнар, ләкин ислам динендә нык торалар. Шушы дин аларга татарлыкларын югалтмыйча, тарихи ватаннары Идел-йортның сулышын тоеп яшәргә мөмкинлек тудыра.

Финляндиядәге татарларны алсаң, аларның саны меңнән артык түгел. Шуңа да карамастан алар үзләренең чын татар һәм мөселман булып яшәүләренә нык нигез салганнар. Мин фин татарлары милли мәдәни мохтариятне сүздә түгел, ә тормышта кулланып яши торган бердәнбер татар төркеме дисәм, ялгышмам дип уйлыйм.

Фин татарлары Төркиядәге милләттәшләребез белән гел аралашып яшәде. Күп вакыт нәкъ алар безне төрек дөньясындагы шөһрәтле татарлар белән очраштыра килде. Алар шулай ук Япониядәге һәм Америкадагы татарлар белән дә бәйләныш булдырды. Алар аркылы безгә шушы илләргә юл ачылды.

Әйе, Япониядәге, АКШтагы, Австралиядәге, Кытайдагы татарлар бу илләргә төрле вакытта килеп урнашканнар. Төп сәбәп монда Совет империясенең татарны эзәрлекләве. Андагы татарларның төп дулкыны эмигрантлардан тора. Болары да илләрен, газиз ватаннарын ташлап качып китүчеләр түгел. Киресенчә, алар гомерләре буенча Татарстанга табынып яшәүчеләр. Бүген аларның күбесе дәүләтебезнең мөстәкыйль һәм бәйсез булуы өчен барган көрәштә катнаша. Безгә 1992 елны узган 21 март референдумы вакытында тәүлекләр буена керфек какмый Татарстаннан килгән хәбәрләрне көтеп торучылар мәгълүм.

Гомумән, без читтәге милләттәшләребезгә карата игътибарлырак, мәрхәмәтлерәк булырга тиешбез. Алар бит ватаннарыннан аерылып яшиләр. Ничек тә булса аның белән багланышларын арттырырга тырышалар. Әгәр дә без татарларның бу төркеме кайда яши дигән сорауга, күңелләре, изге тойгылары белән аларның күбесе үз ватаннарында яши дисәк, һич тә ялгышмабыз, дип уйлыйм. Әйе, татарлар үз ватаннарында яки уйда аның белән яшиләр.

Сүземне тәмамлар алдыннан Татарстанга әйләнеп кайтучы татарлар турында да бер-ике сүз әйтеп китүне кирәк саныйм. Әйе, кайтучыларның саны арта. Әле тагын да артачактыр. Аларны ничек кабул итәргә? Беренчедән, киң күңел белән. Милләттәшләребез ватаннары һәм мондагы туганнары тарафыннан мәрхәмәткә лаеклылар. Алар өчен җиңел булмаган чорда милләтебез үзенең иң гүзәл сыйфатларын ачсын, шуның белән башка милләтләргә дә үрнәк булсын иде. Безнең әле бүгенге көнгәчә дәүләт тарафыннан төзелгән качакларны кабул итү, урнаштыру программабыз юк. Бу эштә әле максатчанлык җитми. Күп вакыт башлаган эшебезне ахырына кадәр җиткерә алмыйбыз.

Бүген милләтебез яңарыш, күтәрелеш чорын кичерә. Безнең аның рухи һәм матди яшәеше, үсеш перспекти-

васы кызыксындыра. Хәзер безнең өчен татарның кайда горуына да карамастан, үзен бер милләт кешесе итеп хис итүе әһәмиятле, шуңа мөмкинлекләр тудыру кирәк.

Татар әле тулысы белән уянмаган. Аның күп катлауларында, шул исәптән интеллигенциясе арасында да битарафлык күзгә ташлана. Милләтебезнең зыялылары аз түгел. Ләкин аның сан һәм сыйфат ягын белеп житкермибез. Моны ачыкламасак, милләтебезне торгызуга халкыбызның бөтен сәләтен җигә алмаячакбыз.

Милләтебез тулысынча уянгач кына, аның үзаңы тиешле дәрәҗәгә җиткәч кенә, без һәммә татар да үз ватанында яки үз ватанының язмышы белән бергә яши дип әйтә алачакбыз.

АЛТЫН УРДА: МИФ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Горур халык һәрвакыт үзенең үткән юлы белән горурлана. Хәтта иң хурлыклы дәверләрне дә үз тарихыннан чыгарып ташламый. Әнә, немец халкын карагыз: әллә ул Гитлер чорыннан баш тартканмы? Юк, тартмаган һәм тартмаячак та. Яисә япон халкын алыгыз: әллә ул үзенең соңгы сугыш чоры тарихын каһәрләдеме? Юк, ул моны эшләмәде һәм эшләмәячәк тә. Бер халыкның да тарихы гел данлыклы, гел шөһрәтле сәхифәләрдән генә тормый.

Инде Россия тарихын алыйк. Монда билгеле булмаган бер генә кенәз дә калмаган. Мәктәп укучылары аларның һәммәсен белергә тиеш. Ә бит империя тарихы гел алтын чылбырдан гына үрелмәгән.

Бу ни өчен шулай эшләнә соң?

Беренчедән, бу — халык беркайчан да төшенкелеккә артык бирелмәсен, үзен тарих битләреннән төшеп калган халык итеп тоймасын өчен эшләнә. Мәдәниятле халык үзенең иң авыр көннәрендә тарихына күбрәк игътибар итә, шуннан өмет һәм дәрман таба. Икенчедән, халыклар үзләренә атылган ташларны, пычракны бер-

кайчан да тарихи хата дип кабул итмәгәннәр. Никадәр генә авыр булмасын, алар үз тарихларын үзләренеке итеп кабул итә килгәннәр, аны башка берәүгә биреп, котылу юлын эзләмәгәннәр.

Безнең татар тарихы исә башкачарак. Беренчедән, ул әле зур фәнни тикшерену нәтиҗәсе буларак дөньяга туып җитмәгән. Татарның тарихы, аны өйрәну чыганаклары, халыкның үзе кебек үк, бөтен дөньяга чәчелгән, сибелгән. Шуңа күрә аның яхшы күренгән, күңелләренә хуш килгән дәверләрен башка халыклар үзләштереп, үз мирасы иткәннәр. Мәсәлән, Идел буенда туып үскән, соңрак Мисырда солтан булган Бәйбарс бүген казакъ итеп күрсәтелә. Бу җәһәттән милләттәшебез кинорежиссер Булат Мансуров моңа өлеш кертте. Ул «Қазахфильм»да, Бәйбарска багышланган фильм төшереп, шушы тарихи шәхесне дөньяга казакъ итеп танытты. Яки шушы ук киностудиянең чекист Қасыйм Чанышевны гәүдәләндергән тасмасын искә төшерик. Монда да атаман Дутовны теге дөньяга озаткан татарның казакъка әйләнгәнлеген күрәбез. Шулай ук бу кешене уйгыр итеп күрсәтү очракларын да беләбез.

Хәер, инде заманалар үзгәрде. Чекистлар белән горурланыр чаклар үтте. Бәлки, тарихи дөреслек хакына, шушы мәһшүр татарны казакълар хәзер үзебезгә кайтарып бирерләр?

Татардан чыккан тарихи шәхесләрне матур гына итеп башкалар тарафыннан үзләштерү фактларын тагын да китерә алыр идем. Тик мин моны бурыч итеп куймыйм. Артык ваклану кебек күренүе бар. Вакыты җиткәч, болары да эшләнер әле. Бу очракта тарихыбызга кагылган зуррак мәсьәләләр турында сүз алып бармакчы булам.

Күз алдына Алтын Урда килеп баса. Бигрәк тә хуҗасыз тарих инде. Моңарчы аңа бер генә халык та дәгъва кылмый килде. Монголлар аны үз тарихлары итеп санамадылар. Һәм бу дөрес тә. Чөнки Алтын Урда дәү-

ләте чын мәгънәсендәге монгол дәүләте булмаган. Аның ханнары Чыңгыз токымыннан булса да, тәмам татарлашып беткән була. Ә Алтын Урданың халкы исә беркайчан да монгол телендә сөйләшмәгән. Аның түрәләре дә төркиләрдән торган.

Бу тарихны руслар һәрвакыт татар тарихы итеп карадылар. Ә рәсми идеологлары «200 еллык Алтын Урда золымы» дигән уйдырма да уйлап чыгардылар. Табигый ки, татарлар моны үзләренә пычрак ыргыту, яла ягу, дип бәяләделәр. Руслар алдында үзләрен актан — ак, сөттән пакь итеп күрсәтергә тырышкан тугандаш төрки халыклар да бу тарихка шулай ук дәгъва кылмадылар. Татарда исә, урдалыкка каршы буларак, болгарлык дулкыны кузгалды. Имештер, татарларның Алтын Урдага катнашы юк, алар, янәсе, болгарлар, руслар кебек үк монголлар тарафыннан яуланган халык. Мондый болгарчылык дулкыны вакыты-вакыты белән шактый көчле агымга да әверелгәләде. Болгарчылыкның нигезе юк дип уйлау шулай ук хата булыр иде. Белүебезчә, монгол явы Болгар дәүләтен җимерә, аның мөстәкыйль яшәвенә чик куя. Ә бит болгарлар — безнең борынгы шөһрәтле бабаларыбыз. Без бүген мәдәниятле, зәвыклы, мәгърифәтле милләт булуыбыз белән беренче чиратта әнә шул бабаларыбызга бурычлы. Ислам дине, ислам мәдәнияте дә безгә шулар аркылы килгән. Шунлыктан, әгәр дә бүгенге татарлар үзләренең болгар мирасыннан баш тарталар икән, нык ялгышачаклар.

Тик менә бу Алтын Урдага мөнәсәбәтне үзгәртүгә сәбәп була аламы? Юк, булырга тиеш түгел. Урдачылык болгарчылыкка каршы килә алмый. Чөнки боларның икесе дә — безнең тарих, безнең үткән юлыбыз. Алай булгач, ни өчен соң боларны бер-берсенә каршы куя килгәннәр?

Билгеле булганча, тарихи гаделлеккә каршы килеп, Россиядә Алтын Урдага карата аңлы рәвештә тискәре караш традициясе тудырылган. Шуның белән бергә та-

тарга карата да. «200 еллык татар золымы» Россиядәге һәммә җитешмәүчелеккә, аның тарихи артта калуына сәбәп итеп күрсәтелә башлаган. Алай гына да түгел, рәсми пропаганда моны гасырлар буе рус халкының миенә сеңдереп килгәнлектән, шушы караш тора-бара генетик кодка әверелгән.

Кыл яхшылык, көт яманлык, диләр. Монда да шундыйрак хәл күренә. XIII гасырның егерменче елларына инде таркалып беткән рус иленә монголлар килеп, аны яулыйлар. Шулай итеп, Җучи олысыннан татар дәүләте Алтын Урда үсеп чыгып, ул Русьне тәре йөртүче орденнардан саклап килә, таркалган рус кенәзлекләрен Мәскәү тирәсендә мәҗбүри рәвештә оештыра, аларга бер дәүләт булып үсеп чыгарга уңай шартлар тудыра. Соңрак, җитәкче даирәләрнең үзара ызгышып яшәүләре аркасында, Алтын Урда үзеннән-үзе таркалып юкка чыга. Аны берәү дә тар-мар итми. Ә инде соңрак Урда калдыклары булган татар дәүләтләре бер-бер артлы Мәскәү тозагына эләгә. Шуннан соң татарга көн бетә, һәм ул, җәбер-золымнан качу өчен, үзенә болгарлык ныгытмасын әзерли, үзен Алтын Урдага бернинди катнашы булмаган итеп күрсәтүне хуп күрә.

Монда шундый бер закончалыкны күрми калу мөмкин түгел. Ул татарның яңарыш чоры башлангач, Алтын Урдага игътибар артудан гыйбарәт. Әйтик, XX йөз башында татар тарихына багышланган хезмәтләрне, бигрәк тә Шиһабетдин Мәрҗани, Һади Атласи әсәрләрен искә алырга мөмкин. Алар Алтын Урдага карашны йомшартып, аны милләтебезнең тарихи мирасы итеп тануга юл салалар.

Октябрь революциясеннән соң, бигрәк тә Татарстан җөмһүрияте төзелү белән Алтын Урдага караш бөтенләй үзгәрә. Моның төп мисалы итеп «Идегәй» дастанына булган игътибарны күрсәтергә кирәктер. Ә бит «Идегәй» — халык иҗатының чын җәүһәре, шуңа күрә аңа кул сузучылар булмады түгел. Аңа башкортлар да,

казакълар да дәгъва белдереп карадылар. Монда да, Алтын Урданың каһәрләнгән тарихын кабул итмәстән, анысын татарларның үзләренә генә калдырып, бары тик аның энҗе-мәрҗәннәрен генә үз такыяларына кадарга тырышу сизелә. Тик алай була алмый бит ул. Алсаң, бөтенләе белән ал. Алмасаң, бер нәрсәсенә дә тимә!

Әйе, егерменче елларда тарихыбызны тулысы белән кабул итүгә омтылыш ясала. Бу исә татарның әле рухы сынмаганлыкны күрсәтә. Ул үләргә, яки нинди дә булса ясалма ныгытма эченә качып, үз тарихыннан үзе ваз кичәргә җыенмый дигән сүз.

Сугыш алдыннан «Идегәй» дастанының 500 еллык юбилеен үткәрүгә әзерлек эшләре башлана. Минем бу дастанның һиндләрдәге «Рамаяна», карелларның «Калевала»сы, кыргызларның «Манас»ы кебек дан тоткан әсәр икәнлеген искә төшереп үтәсем килә. Ул татарның тарихын турыдан-туры чагылдыра, халыкның бөеклеген, аның мәңге яшәячәген раслый. 1941—1945 елгы сугыш дәверендә татар халкының патриотик һәм милли тойгылары өр-яңадан калкып чыга. Шушы елларда ул үзенең тарихын бөтен тулылыгы белән кабул итәргә әзер икәнлеген тагын бер кат раслый.

Идегәй образына да игътибар арта. Аның исемен йөрткән эпосның 30 варианты табыла, аларны эшкәртүгә Нигъмәт Хәким белән Нәкый Исәнбәт күп көч куялар. Әсәр рус теленә дә тәрҗемә ителә. Бу еллар татарның рухы чын мәгънәсендә ныгыган еллар дип саналырга хаклы. Мондый хәл ул чактагы властьларга да файдалы була. Чыннан да, сугыш елларында татарлар күрсәткән каһарманлыкларны сөйләп бетерерлек түгел бит. Соңрак шуларның шактыен үзләштерергә тырышулар булганлыгын да беләбез. Әйтик, рейхстаг гөмбәзенә Җиңү байрагын беренче булып милләттәшебез Заһитов кадаса да, бу батырлыкны Егоров белән Кантариягә ябыштыралар. Заһитовка исә герой исеме дә бирелми. Ул сугыштан соң бик тә серле шартларда дөньядан китә.

Бәлки, кайберәүләргә әнә шул гаделсезлекнең тере шаһиты яшәмәве кирәк булгандыр? Хәер, моңа ачыклык кертелер әле.

Сугыш тынгач, татарның шундый нык рухлы булуына мохтаҗлык бетә. Аны сындыру, ә үзен кол дәрәҗәсендә калдыру кирәк була. Менә ни өчен ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары туа. Ул «Татарстан партия оешмасында идеологик һәм масса-политик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары» дип атала. Нинди гөнаһсыз исем тапканнар! Ә карар эчендә — халкыбызны чагарга җыенган кара елан бөгәрләнеп ята. Бу документта татар тарихчылары милләтчелектә, Алтын Урда тарихын идеаллаштыруда, аны матур буяуларга буяп күрсәтүдә, ә әдәбиятчылар исә хан-феодал эпосы «Идегәй»не популярлаштыруда гаепләнәләр.

Ярый, Мәскәүнең сәясәте ачык. Ул халыкларны кол хәлендә калдыруны максат итеп куйган. Тик менә партиянең Татарстан өлкә комитеты кыланышлары гына бик «сәер» тоела. Ни өчен соң әле моннан дүрт ай элек кенә Мәскәүдән «Идегәй»нең 500 еллык юбилеен уздыруны үтенгән һәм, шуңа рөхсәт алгач, аны үткәрү эшләрен киң җәелдереп җибәргән Татарстан җитәкчелеге бөтенләй икенче җыр җырлый башлый? Ә бит өлкә комитеты вәкилләре ясаган докладларның берсендә татар халкы күрсәткән батырлыклар танылып кына калмый, галимнәр һәм әдәбиятчылар алдына шул батырлыкларның, фидакярлекнең чыганакларын өйрәнү бурычы да куела, әдәбиятыбызның мең еллык традицияләренә кайту кирәклеге әйтелә.

Әйе, партиянең Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Моратов та, Татарстан Югары Советы Президиумы рәисе Динмөхәммәтов та татар җанлы кешеләр була. Тик Мәскәү сәясәте алар алдында дилемма куя: йә син берсүзсез Мәскәү сәясәтен тормышка ашырасың, йә гаделлекне яклап, «Идегәй»не һәм шуның бе-

лән бергә Алтын Урда тарихын үз тарихың итеп кабул итү, аның абруен саклау юлына басасың.

Минем карашымча, Татарстан җитәкчеләре шушы дилемманы хәл иткәндә — Мәскәү сәясәтен сайлаганда — эчке каршылык кичермәгәннәрдер, дип әйтеп булмый. Тик шунысы хак: алар Мәскәү сәясәтен берсүзсез тормышка ашыралар. Алай гына да түгел, хәтта Мәскәүнең үзеннән дә арттырып җибәрәләр. Куркаклык һәм коллык психологиясе үз эшен эшли.

Менә безнең алда партия өлкә комитеты пленумы материаллары. Пленум 1945 елның 24—27 февралендә уздырыла. Анда Үзәк Комитетның ике карары тикшерелә. Берсе Татарстанда авыл хуҗалыгын күтәрүнең кичектергесез чаралары турында. Монысы буенча докладны З. Моратов ясый. Икенчесе инде «Идегәй»гә багышланган «мәшһүр» 9 август карары. Монысы өлкә комитет секретаре Малов укый. Докладның күләме — машинкада 66 бит. Анда Татарстандагы идеология эше бәйнәбәйнә тикшерелә. Бигрәк тә Үзәк Комитет карарында күрсәтелгән «хаталар»га басым ясала. Аеруча Тел, әдәбият һәм тарих институтына эләгә. Имештер, галимнәр Татарстан тарихын, рус һәм татар халыкларының чит ил илбасарларына каршы көрәшләрен өйрәнәсе урында, Алтын Урда, XII һәм XVI гасыр истәлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Хаталарның берсе, янәсе, тарихи дөреслеккә каршы килеп, Алтын Урда икътисады һәм мәдәнияте югары дәрәҗәдә торган прогрессив дәүләт итеп күрсәтүдән гыйбарәт... Малов докладында Алтын Урданың төп сыйфаты булган агрессивлык, рус халкына карата күрсәткән юлбасарлык сугышлары, аның халыкларны ифрат каты изүче һәм бөлдерүче икәнлегенә басым ясала. «Идегәй» дастаны турында докладта болай диелә: «Берничә ел дәверендә... шушы эпос бөтенләй дөрес булмаган рәвештә татар халкының героик эпосы итеп популярлаштырылды. Шул ук вакытта «Идегәй» эпосының милләтчелек идеяләрен чагылдырган булуы

турында бер сүз дә әйтелмәде». Менә бит ничек, әйтерсең лә, бу эшләрдә партия органнары үзләре катнашмаган. Аңлашыла ки, әгәр дә Үзәк Комитет башкарылган эшне хуплаган булса, мактауны үзләренә генә алырлар иде. Ә инде өстән каһәр яугач, алар моны турыдан-туры галимнәргә, әдбиятчыларга аударалар. Шулай итеп, милли идеянең, милли рухның тамырына балта чабыла.

Пленумда, бәлки, башкачарак сөйләүчеләр дә булгандыр? Моратов үзе ни әйтте икән? Инде аны тыңлыйк: «Әдәбиятчылар, тарихчылар тарафыннан ясалган хаталарны партия Үзәк Комитеты вакытында төзәтмәгән булса, ниләр генә килеп чыкмас иде?!». Чыннан да, ниләр булыр иде икән? Бәлки, дөньяның асты өскә килеп, яңадан татар явы кузгалыр иде? Шулай да Моратовны тагын тыңлыйк әле: «Аларның (ягъни тарихчылар, әдәбиятчылар ясаган хаталарның) руслар белән татарлар арасындагы мөнәсәбәтләрне кискенләштерүгә китерүе мөмкин иде. Ә бу безнең дуслыкка китереп сугу булыр иде».

Партия секретарена ышансаң, татарга яла ягу бернинди дуслыкка да комачауламый, тик аның үзе турында, аның тарихы турында хак сүз сөйләнсә генә дуслык бозылырга мөмкин икән. Кем инде шушы сүзләрне укыганнан соң аларны татар рухын сындыруга юнәлдерелмәгән, дип әйтер. Алай гына да түгел, секретарь әдәбиятчы һәм тарихчыларны фәнгә бернинди катнашы булмаган, череп беткән идеяне, ягъни Алтын Урданың прогрессив дәүләт икәнлеген, Идегәйне исә аның героик вәкиле дигән идеяне сугыш елларында яклап чыгуда гаепли һәм шундый сорау куя: «Ни өчен соң алар шушы иң явыз, заманында инде фаш ителгән, рус халкы тарафыннан тукмалган дошманыбызны нәкъ менә сугыш елларында күтәреп чыктылар?»

Сорауны куюны куя, әмма аңа җавап бирә алмый. Гаҗәп түгел, чөнки Идегәй беркем тарафыннан да тук-

малмый, киресенчә, үз иленең, ягъни Идел-йортының, үз халкының дошманнары белән һәрвакыт уңышлы сугышлар алып бара. Ул ачык сугышта түгел, ә үз милләттәшләре тарафыннан үтерелә, үзара ызгыш корбаны була.

Әгәр инде тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарихи фактларга, эпосның үзенә таянып язалар икән, аларның монда ни гөнаһы бар? «Юк,— ди партия өлкә комитеты секретаре,— алар гөнаһлы, аларның бурычы шул гөнаһларын юуда». Ә гөнаһлы бәндәләр тарихчы Хәйри Гыймади, язучы һәм галим Нәкый Исәнбәт кебекләр булып чыгалар. Моннан соң алар тик халыклар дуслыгы турында язарга, революцион хәрәкәткә татарлар керткән өлешләрне генә өйрәнергә тиешләр икән. «Идегәй» эпосы исә моннан соң телгә алынмаска, Алтын Урда тарихы өйрәнелмәскә, өйрәнелсә дә, тик вәхшиләр дәүләте итеп кенә күрсәтелергә тиеш! Бу шулай эшләнә дә. Тарих китапларында, әдәби әсәрләрдә Алтын Урда тик тискәре яктан гына телгә алына, нәтиҗәдә укучылар уннарча еллар буенча ялган тарихны өйрәнеп килделәр.

Хакыйкатькә тугрылык саклаган хәлдә шунысын әйтергә кирәк: революциягә кадәрге рус тарихчылары, әйтик, Соловьев, Ключевский Алтын Урдага күпкә дөресрәк, гаделрәк бәя биргәннәр. Совет чоры тарих фәне исә чын мәгънәсендә шовинистик, татарларга каршы юнәлеш алды. Алтын Урда һәм татарлар турында дөреслеккә якын фикерне язучылардан тик В. Чивилихин гына әйтте. Галимнәрдән безне Л. Гумилев яклап чыкты.

Татарларның үзләре арасында Урдага карата каршылыклы фикерләр булмады һәм юк дисәк, бу дөреслеккә туры килмәс иде. Тик шунысы бәхәссез, татарлар коточкыч басымга, кимсетүләргә карамастан, үзләренең тарихларыннан ваз кичмәделәр. Бу — чын мәгънәсендә ихтирамга лаек.

Бүген менә дөреслекне әйтү өчен зур мөмкинлекләр ачылды. Соловьевның, Ключевский кебек тарихчыларның әсәрләре басылып чыкты, хәзер аларны теләсә кем

укый ала. Ә аларда Алтын Урда турында да, Идегәй турында да эпостагы мәгълүматларны раслый торган дистәләрчә фактлар тупланган. Л. Гумилев исә татарларны тарихи гаделсезлекләрдән яклауны үз бурычы итеп куйды һәм, кемнәрнеңдер куркыту-янауларына да карамастан, соңгы сулышынача шушы максатына тугрылыклы булып калды. 1989 елда аның «Древняя Русь и Великая степь», «От Руси к России» исемле хезмәтләре басылып чыкты. Аларда ул татар тарихына каршы юнәлдерелгән бик күп уйдырмаларны тар-мар итте. «Идегәй» дастаны да дөнья күрде. Аның Семен Липкин башкарган русча тәрҗемәсе басылып чыкты. Тәрҗемә авторы Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә дә лаек булды. Бөек дастаныбыз халыкка яңадан әйләнеп кайтты.

Шулай итеп, Алтын Урда тарихын да халыкка бөтен тулылыгы белән кайтарып бирү бурычы килеп басты. Шушы бурычтан чыгып, Казанда әлеге дәүләтнең 750 еллыгына багышланган халыкара фәнни конференция булып үтте. Саратовта аңа багышланган татар мәдәнияте көннәре һәм «түгәрәк өстәл» үткәрелде. Волгоград һәм Саратов музейларында шушы дәүләт тарихына багышланган экспозицияләр булдырылган. Анда тупланган бай материал Алтын Урда дәүләтенең, төрле уйдырмаларны фаш итеп, вәхшиләр дәүләте түгел, киресенчә, зур-зур шәһәрләре булган мәдәниятле халык, һөнәрчеләр дәүләте икәнлеген исбатлый. Европада канализациянең нәрсә икәнлеген белмәгән заманнарда Алтын Урда шәһәрендә канализацияле мунчалар һәм башка иҗтимагый корылмалар булуы хакында сөйли.

Мәшһүр Н. Г. Чернышевскийның оныгы татар галимнәренең чыгышларын бәяләп: «Нигәдер безнең казанлылар Алтын Урда турында сөйләгәндә аклану позициясен сайладылар, минемчә, бу тарихтан йөз чөерергә түгел, аның белән горурланырга кирәк», диде. Бүген әнә шундый караш үзенә юл яра. Дөрес, галимнәр хәзер дә

бәхәсләшәләр. Бәхәсләшсеннәр, фәндә бәхәсләрсез булмый. Тик шунысы куанычлы: аларның берсе дә Алтын Урдадан баш тартмый, аны данлы тарихыбызның бер өлеше итеп таный.

Тарихыбызда йөз чөерерлек урын юк. Киресенчә, без бөек тарихыбыз белән тик горурланырга гына хаклыбыз. Ә инде халык үз тарихы белән горурлана икән, аның рухы нык, киләчәге ышанычлы була.

КӨРӘШЧЕЛӘРЕБЕЗНЕ ИСКӘ ТӨШЕРИК!

ПАРИЖДА УКЫГАН САДРИ МАКСУДИ

Октябрьгә чаклы халкыбызның милли һәм сәяси аңын уяту өчен татар милләтенә актив хезмәт итеп тә, большевиклар позициясенә басмый калган, аннан Октябрь идеяләре, Совет власте белән килешмичә чит илләргә күчеп киткән, яисә революцияне кабул итеп туган җирендә яшәсә дә, шәхес культы чорында, милләтчелектә һәм башка шундый гөнаһларда гаепләнеп, исемнәре онытылган сәяси эшлеклеләребез байтак безнең. Аларның исемнәрен халыкка кайтару тарихыбызны баетыр, үткән чынбарлыкны тулырак күз алдына китереп бастырыр иде. Хәер, бу җәһәттән боз кузгалды инде, көрәшчеләребезнең кайберләрен халык инде белә. Бу язма исә Садри Максудига багышлана.

Күп еллар буена аңардан дошман образы тудырып килделәр. Большевик булмаганнарга андый ярлыкны тагу җиңел иде бит. Ә Садри Максуди — сәяси карашлары буенча татар кадеты, хәтта милләт өчен артык янып йөреп «милләтче» исемен дә алган кеше. Кадетлар «халык азатлыгы» партиясе дип йөртелгән «конституцион демократлар партиясе»н тәшкил иткәннәр. Аның составына крестьяннарны үз ягына тарту өчен тырышып йөрүче буржуаз зыялылар кергән. Вакытлы хөкүмәттә алар царизмның тышкы сәясәтен дәвам иттерәләр. Шуңа күрә әлеге партия әгъзаларын, шул исәптән Садри Максудины да, «сөттән ак, судан пакь» итеп күрсәтүне максат

итеп куймыйча, бу юлы бары тик аның сәяси портретын сурәтләү белән генә чикләнәбез.

Садри Низаметдин улы Максуди 1879 елда Казан артындагы Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. Сигез яшенә кадәр Садрига белемне атасы һәм анасы бирә. Тугыз яшендә аны Казандагы бер мәдрәсәгә бирәләр. Җиде ел укыганнан соң ул, 1895 елны, абыйсы Һади белән Бакчасарайга китә. Анда мәдрәсәдә мөгаллим булып эшли, бер үк вакытта абыйсы белән бергә рус һәм төрек телләрен өйрәнә. Күрәсең, нәкъ шул вакытта Кырым татарларының күренекле зыялысы Исмәгыйль бәй Гаспралы белән дә танышкан.

1897 елда Садри яңадан Казанга әйләнеп кайта. Монда ул Учительская школага укырга керә һәм аны уңышлы гына тәмамлый.

Садри Максудига туктаусыз белемгә омтылу хас, аңардан Европа мәдәниятен үзләштерүгә көчле ихтыяҗ туа, һәм ул үзенең белемен арттыру өчен Парижга барырга, анда укырга карар кыла. Юл уңаеннан Садри Л. Н. Толстой янына кереп чыгуны үзенең бурычы итеп саный, Ясная Полянада бөек гуманист-язучы белән бер тәүлек аралаша, киңәшә. Аннан И. Гаспралыдан фатиха алып, Истанбулга юнәлә. Монда үзенең өченче остазы Әхмәт Мидхәт белән киңәш тота. Биредә Парижга барып укырга керү өчен француз телен өйрәнә. Ул аны өйрәнүне Казанда ук башлаган була. Ел ярым буе Истамбулда торып француз һәм латин телләрен өйрәнгәннән соң гына Парижга юл ачыла. 1902 елда Садри дөньякүләм билгеле Сорбонна университетының студенты булу бәхетенә ирешә. Соңрак Мәскәү университетында да рус дипломы алу өчен яңадан имтиханнар тота.

Парижадан кайтып төшүгә үк аңа революция дулкынына чумарга туры килә. Билгеле булганча, ул 1906 елның августында Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында «Густав Струве» пароходында үткәрелгән мөселманнар съездының эшендә актив катнаша. Хәтта анда төзелгән «Мө-

селман иттифагы» («Мөселманнар берлеге») партиясенең үзәк комитеты әгъзасы булып та сайлана.

Минем кулда «Өч думада мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре» исемле 1910 елда басылып чыккан китап. Анда Садри Максудовның II һәм III дәүләт думаларының әгъзасы итеп сайлануы һәм эшләгән эшләре турында шактый күп язылган. Ә инде белем мәсьәләсенә килгәндә, автор кирәгеннән артык чамасыз сүз куерта. Ничек инде ике университет күләмендә имтихан тотып та наданлыкны яшереп калып булыр икән? Думада авторитеты зур булу сәбәпле, Максудины төрле комиссияләргә сайлыйлар. Аның белән Дума рәисе дә киңәшкәли. Ул Дума мөнбәренә менеп нотыклар да сөйли.

Ул 1910 елны Оренбург миллионеры мәшһүр Мөхәммәтшакир Рәмиевнең кызына өйләнә. Бу аның дәрәҗәсен мөлкәтле кешеләр арасында тагын да үстереп җибәрә. Шулай да ул IV Думага депутат булып үтми.

Садри Максудиның депутат чагында мөселманнар арасында алып барган эшчәнлеге игътибарны җәлеп итә. Ул күп йөри, күп чыгышлар ясый. Мәсәлән, ул 1910 елда Төркестанда, аерым алганда Ташкентта һәм Ашгабадта була. Аны мөселманнарның мәгариф эшләре, мәдәният үсеше кызыксындыра. Ул Ашгабадтагы татар колониясенең «Фридуки» исемендәге мәктәбенә ярдәм итә. Шул ук елны Бакуда да була. Монда ул чыгышларын төрек телендә алып бара, популярлык казана. Монда Азәрбайҗан җәмәгать эшлеклесе Галимәрдән Тупчыбашев белән якын дуслыгы да роль уйнамый калмагандыр, күрәсең.

Садри Максуди илдәге сәяси партияләрнең эшчәнлеге белән актив кызыксынып яши. Җандармнар аның 1911 елда Петербург социал-демократлары һәм социалист-революционерлары белән булган элемтәсен игътибарсыз калдырмыйлар. Ләкин Садри әфәндене бу партияләр түгел, ә кадетлар үзенә җәлеп итә. Аның

П. Н. Милюков белән якынлыгы да шуннан килә булса кирәк. Ул әлеге партиянең үзәк комитетына да әгъза булып сайлана.

Кайвакыт Садри әфәнденең эшләрендә кыюсызлык та чагылып киткәндәй була. Чыннан да, әйтик, Рәшит Ибраһимов эшчәнлеге белән чагыштырганда бу шулайрактыр да. Ул Рәшит казый кебек тәвәккәл адымнарга бара торган кеше булмый. Шулай да аның шактый кыю адымнарын да күрми үтү дөрес булмас иде.

Бер генә мисал. 1911 елның 20 маенда Уфага 37 губерна вәкиле җыела. Кич белән үткәрелгән банкетта Садри әфәнде нотык тота. Анда ул, жандарм доносчысы хәбәренә караганда, мөселманнар бердәмлегенә өнди. Һәм шул кадәр кызып китә ки, Уфа губернаторының махсус йомышлар үтәүче чиновнигы аңардан нотыгын туктатуны таләп итә. Садри әфәнде икенче көнне дә, шикле кешеләргә ишарә ясап, 600 кешелек митингта чыгыш ясаганда «Мисыр алачыклары»нда, «Истанбул бульварлары»нда белем алган караңгы шәхесләрнең Россиядә су болгатып йөрүләрен әйтеп китми түзә алмый. Ләкин шул ук шымчылар аның сөйләвен сызгырулар белән туктаталар.

Әйе, бу җиңел еллар булмый, әлбәттә. Бу — Ишми ишаннар эшчәнлеге чәчәк аткан еллар. Бу — донослар, тентүләр, кулга алулар чоры. Берничә дистә мәктәп, китапханәләр дә шушы елларда ябыла. Бөтен илгә шаулаган Иж-Буби эпопеясы үзе ни тора! Монда хөкүмәтнең татарларга карата үткәрелгән сәясәте тормышка ашырыла.

1912 елны Балкан сугышлары йогынтысында хөкүмәтнең татарларга карата шиге тагын да арта төшә. Дөрес, бу очракта репрессияләрнең юан башы С. Максудига төшкән дию һич тә дөрес булмас иде. Шулай да бу эзәрлекләүләрнең чыбык очы аңа да тия. Юкка гына аның исеме жандармнар төзегән исламчылар исемлегендә унбишенче булып тамгаланмагандыр. Каты эзәрлек-

ләүләрдән аны депутат мандаты коткарып килгән, күрәсең.

1914 елның 10—25 июнендә Эчке эшләр министрлыгы рөхсәте нигезендә Диния нәзарәтенә һәм мөселман мәдрәсәләренә реформа ясау нияте белән зур җыелыш булып уза. Анда Садри әфәнде дә катнаша. Шунысы кызыклы, кем булуларына да карамастан, жандармнар һәркем турында яшерен мәгълүматлар җыя. С. Максуди турында да шактый мәгълүматлар туплана. Бу җыелыш хөкүмәтнең үз рөхсәте белән җыела лабаса.

Беренче бөтендөнья сугышы Россия мөселманнарын авыр хәлгә куя, алар ике ут арасында калалар. Дөрес, татарларның беркайчан да Россиягә хыянәт иткәннәре булмый, һәммә сугышта да үзләрен батыр итеп күрсәтәләр. Әмма Германия һәм Австро-Венгрия ягында Төркиянең дә булуы аларны бик нык пошындыра. Алар патша хөкүмәтенең Босфор һәм Дарданеллны кулга төшерергә тырышуына, Ая-Суфия манарасына тәре куярга җыенуына һич кенә дә риза була алмыйлар. Шунлыктан татарлар, сугышта батырлык күрсәтүләренә карамастан, Россиянең Төркиягә карата алып барылган сәясәте белән риза булмыйлар. Җае чыккан саен моңа протест белдерәләр.

Патша бәреп төшерелгәч, март ахырларында Петроградта кадетлар партиясенең VII съезды булып үтә. Анда Садри Максуди да катнаша. Башка мәсьәләләр белән бергә сугышка мөнәсәбәт тә тикшерелә. Бу турыда доклад белән партиянең үзәк комитеты члены А. А. Корнилов чыга. Садри Максуди докладның төп пунктларына каршы килмәстән, Төркияне буу, Истанбулны, Босфор һәм Дарданеллны басып алу планнарына каршы чыга.

Гомумән, 1917 ел Садри Максуди өчен кабат аякка басу чоры була. Ул үзен яңадан тугандай хис итә. Әйтеп үтелгән кадетлар съездында ул Россия мөселманнарының вакытлы Үзәк бюросы әгъзасы буларак катнаша. Шунлыктан ул иллюзиягә бирелә. Аның уенча, мөсел-

маннар аңа бер шиксез тулы ышаныч белдерәләр. Алар аның артыннан барырга әзерләр. Садри — кадет! Димәк, халык та кадетлар артыннан бара. 25 март көнне шул ук кадетлар съездында ул «Россиянең утыз миллионлы мөселман халкы моңарчы да кадетлар белән барды һәм моннан соң алар белән барачак», дип белдерә. Ләкин Садри әфәнде каты ялгышкан булып чыга. Аның бу сүзләре бөтен мөселман дөньясында ризасызлык уята. Хәтта үзе белән бергә вакытлы Үзәк мөселман бюросында әгъза булып торган кешеләр дә протест йөзеннән күмәк мөрәҗәгать кабул итәләр. Анда исә мөселманнарда кадетларга карата, тегеләр империалистик сугыш тарафдарлары булганлыктан, ышаныч кредиты инде күптән бетте, диелә. Шуннан соң С. Максуди үзенең кадетлыгы белән әллә ни шапырынып йөри алмый.

1917 елның 5 апреле көнне Вакытлы хөкүмәт Төркестан комитеты төзи. Аның составына Тургай өлкәсендәге Вакытлы хөкүмәт комиссары казакъ А. Букейханов, генерал А. А. Дәүләтшин, М. Ганышбаев, В. С. Елпатьевский, П. Е. Преображенский белән бергә, С. Максуди да керә. Бу комитет Сәмәрканд, Сыр-Дәрья, Фирганә, Каспий арты, Җидесу өлкәләрендә, шулай ук Хивада һәм Бохарада Вакытлы хөкүмәт исеменнән идарә итәргә тиеш була. Төркестан комитетының башкарган әллә ни файдалы эше булмаса да, С. Максуди үзенең командировкаларын җирле мөселманнар белән танышуга, аларның тормышын өйрәнүгә багышлый.

1917 елның 20 июлендә Казанда өч Бөтенроссия мөселман съезды ачылырга тиеш була. Анда Учредительное собраниегә сайлау техникасы хакындагы доклад белән чыгарга С. Максуди әзерләнә. Ләкин съезд бу көнне ачылмый, чөнки делегатларның саны 150 дән узмый. Рәсми булмаган мәҗлестә С. Максуди сүзне болай дип башлап җибәрә: «Бүген рәсми мәҗлес ачылмый, шуңа танышу мәҗлесе генә ясыйбыз. Мәгълүмегезчә, без мөселманнар Иван Грозный заманыннан бирле кысылып

килдек, урманда адашып калган бала кеби, ни эшләргә белми йөрдек. Бабайларның пайтәхете булган бу Казан шәһәрендә безгә иркенләп торырга ил-көн калмаган иде. Дүрт гасыр буенча изелдек, хокуксызлык илә кая барырга белми... йөрдек. Мондый биналарда аерым җыелырга безнең хакыбыз калмаган, кулымыздан бөтенесе диярлек алынып беткән иде...» Аннан соң ул шушы хокуксызлыкны исбат иткән бер Европа сәяхәтчесенең сүзләрен китерә һәм дәртләнеп дәвам итә: «Ләкин без бетмәдек һәм бетмәячәкбез (көчле алкыш). Ләкин әфәнделәр, яшәү өчен бик зур вазифаларыбыз бар, дөньяда торуымыз өчен бик зур каһарманлыклар кирәк, һәммәбез бер җан, бер тән булып, берничә айларга партия низагларын бер якка куеп тырышсак кына күтәрелә алачакбыз. Армый-талмый иҗтиһад итсәк кенә үзебезне таныта алырмыз».

Шунысы игътибарга лаеклы, бу көннәрдә әле Садри Максуди нинди дә булса милли хөкүмәт төзи алуга ышанмый. Аның фикеренчә, мөселманнар, дөресрәге, Эчке Россия мөселманнары милли-мәдәни мохтарият (автономия) өчен көрәшеп, һәммә милли эшләрне үз кулларына алырга тиеш була. Ул татарларны Россиядән чыгып китәргә өндәми. Киресенчә, ул илнең бердәмлеген яклый. Аның өчен бердәмлек беренче урында. Татарларга да милли-мәдәни мохтарият хокукын алырга кирәк. «Төрек-татар дөньясы тарихында иң якты, иң мәсгуд көннәр шул сәгатьтән башланырга тиеш». Һәм моннан соң «сыйныф низагларыбызны бер якка куеп», «фәкать төрек-татар милләтенең бәхетен вә сәгадәтен күзәтик».

Бу съездда Садри Максуди, һичшиксез, татарның беренче шәхесенә әверелә. 22 июль көнне гомуммөселман съездының, руханилар һәм хәрбиләр съездларының уртак мәҗлесендә Садри әфәнде тарафыннан төзелгән милли-мәдәни мохтарият турындагы карар кабул ителә. Аңа каршы чыгучылар булуга да карамастан, бу карар, чыннан да, милли бердәмлек хисләрен ныгыта. Газета-

лар аны украиннар универсалы белән чагыштыралар, аңа тәңгәл документ итеп күрсәтәләр, Садри Максудига дан җырлыйлар.

Садри Максудиның Федерациягә карашы ничек булган соң? Ул Россия читендәге мөселманнар өчен җирле мохтарият кирәклеген һәрвакыт алга сөреп килә, ләкин Федерация лозунгысын мөстәкыйль таләп итеп күтәреп чыкмый. Аны, Әхмәт бәк Цаликов, Гомәр Терегуловлар белән беррәттән, федерация дошманы дип игълан итүләре юкка гына түгел. Шулай да фәнни әдәбиятыбыздагы милли-мәдәни мохтарияткә (автономия) карата яшәп килгән беръяклылыкны әйтеп китү урынлы булыр дип саныйм.

1917 елда күпләр, шул исәптән татар эсерлары да, әгәр дә Россия Федератив дәүләткә әйләнсә, татарларның төрле җиргә таралып яшәүләре аркасында алар өчен территориаль яки җирле мохтарият булдыру мөмкин түгел дип саныйлар. Мәсәлән, эсер Фуат Туктаров, Россияне Федератив нигездә корган очракта да, татарлар өчен тик милли-мәдәни мохтарият кына хас дип саный.

Ләкин башкача уйлаучылар да була. Мәсәлән, Петербургтагы «Татар учагы» җәмгыяте, Галимҗан Ибраһимов тирәсенә тупланган татар-башкорт сул эсерлары татарлар һәм башкортлар өчен аерым җирле мохтарият булдырырга кирәклеген алга сөрәләр. Ләкин 1917 елның июлендә алар азчылыкны тәшкил итә. Мөселман социалистлар комитеты, Мулланур Вахитов үзе, Уфадагы татар-башкорт большевиклары оешмасы һәм бик күпләр милли-мәдәни мохтариятне хуплыйлар. Аны игълан иткән 22 июль көнен милли бәйрәм итеп таныйлар. Менә ни өчен Садри Максудиның абруе бик нык үсә. Аны игълан ителгән мохтариятне тормышка ашыру хәйәтенең *

---

* *Хәйат* — **комиссия.**

рәисе итеп сайлыйлар. Һәм бу өлкәдә ул шактый эшләр дә башкарырга өлгерә.

Әлбәттә, баштан ук татарлар өчен җирле мохтарият төзүне күздә тотмау Садри Максудиның абруена бераз күләгә төшерә. Чөнки ни дисәң дә, милли-мәдәни мохтарият, әгәр дә ул теге яки бу җирле властька бәйләнмәгән булса, һавадагы торна булып кына кала. Һәм ул шулай булып чыга да. Соңыннан аңа, теләсә-теләмәсә дә: җирле мохтариятне дә, федерацияне дә танырга туры килә. Чөнки ул властьсыз милли-мәдәни мохтариятнең нәрсә икәнлеген берничә ай эчендә бик яхшы аңлый. Шуңа күрә 20 ноябрьдә Уфада ачылган Милләт мәҗлесендә мондый мохтариятнең үзе генә гамәлгә ашмаячагы күрсәтелә.

Бу мәҗлеснең беренче җыелышын Садри әфәнде ачып җибәрә һәм рухланып сөйли. Нотыгының беренче өлешендә шундый сүзләр бар: «Милләт рухын онытып, гадәтләребез онытылып беткәннән соң, яңадан башыбызны күтәреп, үз эшебезне үз кулыбызга ала алачагыбызны кем уйлаган?.. Без черек нигезгә корылган дәүләтләр урынына егерменче гасырда чын мәгънәсе белән мәдәнияткә бина кылынган... дәүләтләр корырбыз».

1918 ел башында эшләгән бу мәҗлес турында махсус язарга кирәк. Анда сөйләнгән сүзләр берничә томлык материалны тәшкил итәр иде. Без бу очракта тик Садри әфәндегә кагылган кайбер материалларны гына китерергә мәҗбүр булабыз. Мәҗлестә Исмәгыйль Рәмиевнең: «Без милләтнең даими ялчысы да, сакчысы да. Милләт мәҗлесе Урал буе мөселманнарына федерация алып бирсен!» дигән сүзләренә Садри әфәнде болай җавап бирә: «Без барысына да тырышачакбыз. Мөмкин булса, үзебезгә аерым дәүләт тәшкил итү дәрәҗәсенә кадәр тырышачакбыз». Ул гаскәрләргә милли полклар оештыруда ярдәм итәргә вәгъдә бирә.

Укучы: кайда соң монда милли-мәдәни мохтарият, дип сорарга мөмкин. Чыннан да, бик урынлы сорау.

Садри Максуди элеккечә милли-мәдәни мохтарияткә — мәдәни автономиягә турылыклы булып кала. Мәҗлестә шуны тормышка ашыру өчен күп төрле карарлар кабул ителә. Монда без җирле мохтарият һәм милли-мәдәни мохтариятнең кулга-кул тотышып эшләгәнен күрәбез. Мәҗлестә ике фракция барлыкка килә: 1) туфракчылар; 2) төркичеләр. Ике фрацияне дә берләштергән идея — федерация идеясе була. Ике фракция дә шуның нигезендә Идел-Урал җирле мохтариятен алга сөрә. Әмма туфракчыларның таләпләре конкретрак була. Алар федерация генә дип калмыйлар, ә Россия — кушма җөмһүриятләрдән торырга тиеш, диләр. Алар җирле мохтарият кенә дип калмыйлар, җәнүби Идел-Урал штаты, диләр. Алар бу мәсьәләләрнең кирәклеген тануны гына түгел, ә штатның чикләрен билгеләүне үз вазифаларына керә дип карыйлар. Алар шулай ук штатны булдыру өчен аның Учредительный собраниесен җыюны үзләренең бурычы итеп куялар.

Фракцияләр аерым-аерым да эшлиләр. 25 ноябрь көнне мәҗлеснең утырышы сәгать 12дә ачыла. Садри әфәнде берничә хәйәт-комиссия төзергә кирәклеген әйтә. Аның сүзен Шәйхулла Алкин куәтли. Зыялы әфәнделәр комиссияләрнең исемнәрен гарәпчә төзеп тә китә башлыйлар. Тик ни эшлисең бит, залдагыларның барысы да алар кебек үк гарәпчә белми. Залдан берәү: «Аларның исемнәре татарча ничек соң?» — дип сорарга мәҗбүр була. Шундый өстәмәләрдән соң Садри әфәндегә күктән җиргә төшеп эшләргә туры килә. Чыннан да, Фатих Сәйфи җирле мохтариятне тормышка ашыру комиссиясен төзергә кирәк дигән тәкъдим кертә. Ибраһим Биккулов, моны хуплап, автономиягә Идел-Урал штаты исемен бирергә кирәклеген әйтә.

20 декабрь көнне иртәнге утырышта һич көтмәгәндә: «Кемнәр соң без, төрекме яки татармы» дигән дискуссия кабынып китә. Бу, әлбәттә, теоретик бәхәс кенә булмый. Монда татарларның башкорт һәм казакъ автономиясенә

ничек карарга тиешлекләре тикшерелә. «Төрекчеләр» төрек-татар бердәмлеген алга сөрә, ә «туфракчылар»ны конкрет татар проблемалары күбрәк кызыксындыра. Бәхәсләр тулы компромисс белән бетә. 9 январь көнне «Тормыш» газетасында басылып чыккан Идел-Урал штаты турындагы карарны шул бәхәсләрнең нәтиҗәсе дип карарга кирәктер.

1918 елның 11 январе көнне сәгать 10 да Уфа ресторанын «Россия»дә төрекчеләр банкеты була. Монда Садри Максудига Россия җирлегендә соңгы тапкыр дан җырлана.

Октябрь революциясеннән соң Садри Максуди Төркиягә күчеп китә һәм калган гомерен шунда үткәрә. Белмим, бәлки, ул үз иленә кайтырга омтылгалап та карагандыр. Бу чорда андыйларга кайту юллары ябык була инде.

Ул Төркиядә утыз ел гомерен үткәрә. Рухы белән Садри Максуди зур биеклекләргә омтылучан кеше була. Шунлыктан чит илдә дә тик ятмый. Аны яңа Төркия юлбашчысы Кәмал Ататөрекнең дусты булган диләр. Ул ике мәртәбә республика мәҗлесенә (парламент) депутат итеп сайлана. Күрәсең, аны эшлекле кеше итеп таныганнардыр. Ул Төркиядә Арсал исеме астында билгеле була. Шушы исеме белән Милләтләр лигасы составына җибәрелгән Төркия делегациясенә дә кертелә.

Төркиядә Садри әфәнде политик эшлекле генә булмый. Ул анда башы-аягы белән фән эшенә дә чума. 1945 елдан башлап ул Истанбул университетында профессор булып эшли. Лингвистика һәм хокук белеме буенча шактый күләмле хезмәтләр яза. 1955 елда чыккан соңгы хезмәте «Милли аңның социологик нигезләре» дип атала.

Садри Максуди 1957 елның 20 февралендә Истанбул шәһәрендә дөнья куя.

Әйе, зур талант иясе булуына карамастан, аның мирасының бик аз өлеше генә үз халкына хезмәт итә. Аның хезмәтләрен үз халкына кайтарып бирү татар зыялыларының мөһим бурычы булып кала.

БИГИЕВЛӘРНЕҢ ИКЕНЧЕСЕ

Заманында Муса Бигиевнең исеме татар дөньясында иң данлыклы исемнәрнең берсе була. Берәүләр өчен ул гыйльми дәрәҗәгә ия кеше. Мөселманнар аны ислам динен иң яхшы белүче дип таныганнар, дин әһелләре аңардан көн тәртибенә килеп баскан мәсьәләләргә исламның ничек җавап бирергә тиешлеген сораганнар. Ул үзе исә, Аллага ихлас ышанган кеше буларак, бу диннең мөселманнарга яшәү көче бирү мөмкинлекләре бик зур дип исәпләгән.

Муса Ярулла улы Бигиев 1875 елны Пенза губернасының Чембар шәһәрендә туган. Аның абыйсын — күренекле язучы Заһир Бигиевне — кем генә белми икән. Күрәсең, бу гаилә бер урында гына яшәмәгәндер. Абыйсы Ростов-Донда туган, ә энесе Чембарда. Гаиләдә рус телен дә, татар телен дә бик яхшы белгәннәр. Муса да ике мәдәният йогынтысында тәрбияләнгән. Ул Л. Н. Толстойга аеруча ихтирамлы булган. Аны бик күп акыл ияләренең фикерләрен сеңдергән бөек философ дип атаган. Аңа абыйсының да йогынтысы зур була.

Үзләрендә бераз белем алганнан соң, Муса Казанга, Апанаев мәдрәсәсенә килә. Бу мәдрәсә заманы өчен шактый алдынгы белем учагы булып хисапланган. Аның укытучылары да, шәкертләре дә ислахчылык, җәдитчелек рухы белән сугарылган була. Мусаның монда күпме укыганлыгы билгесез, ләкин шунысы хак, аны Казан да канәгатьләндерми, ул киңрәк дөньяга чыгарга омтыла. Аның 1901 елда Петербургта яшәгәнлеге мәгълүм. Шул елны 31 августта башкаланың Васильев утравы, 55 нче линия, 2 нче йортында полиция тарафыннан тентү үткә-

релә, һәм шунда яшәүче Муса Бигиев кулга алына. Ул эшче оешмасы эше буенча җавапка тартыла. Димәк, булачак атаклы дин галиме иҗтимагый эшен эшчеләр хәрәкәте белән бәйләнештә башлап җибәрә. Мусаның анда нәрсә эшләгәнлеге турында бернинди дә мәгълүмат юк. Әмма шунысы ачык, аны бу хәрәкәттә катнашканы өчен Уфага сөрәләр, анда ул полиция күзәтүе астында яши.

Сөрген срогы тулуга, ул Төркиягә китә. Аннан Гарәбстанга сәяхәт кыла. Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә була. Гомумән, гарәпләрнең тормыш рәвеше белән таныша. Алай гына да түгел, анда ул күп дин галимнәренең лекцияләрен тыңлый.

Муса әфәндене фанатик итеп күз алдына китерү һич кенә дә дөрес булмас иде. Ул үткәннәр белән түгел, үз заманы ихтыяҗлары белән яши. Дини фанатиклар, исламның бер хәрефен дә үзгәртмичә, аны тик шул килеш кенә файдаланырга кирәк дигән фикерне халыкка сеңдерсәләр, гарәп илләрендә, шулай ук Төркиядә дә, исламга реформа кирәклеген аңлаган кешеләр шактый була. Муса алар белән таныша. Жандармерия белешмәләрендә аның ирекле фикер йөртүче яшьләр арасында «бөтерелгәнлеге» күрсәтелә. Бу чыннан да шулай була. Дини фанатиклар, Россиядә булсын, Төркиядә булсын, аны догмалардан баш тартырга өндәгәне өчен яратмыйлар. Ул мөселман дөньясында беренчеләрдән булып хатынкыз иреклеген яклап чыга, хатын-кызны санга сукмауны хата дип саный.

Россиягә ул 1905 елны әйләнеп кайта. Ил революция утына чолгана башлаган бу чорда Муса да вакыйгалардан читтә кала алмый. Ул Россиядә үзенең төп яши торган урыны итеп Петербургны сайлый. Бу аңлашыла да. Ул шушыннан сөрелгән иде, инде хәзер дә илдә башланып киткән революциянең үзәгендә буласы килә. Икенчедән, ул Петербург университетын тәмамлау турында хыяллана һәм анда ирекле тыңлаучы рәвешендә укый да башлый.

Петербургта урнашуның тагын бер сәбәбе — монда Рәшит казый Ибраһимов яши. Ул исә жандармнарның 1911 елда төзегән панисламистлар исемлегендә беренче кеше булып теркәлгән була. Кызганычка каршы, әдәбиятта Рәшит Ибраһимовка тик тискәре бәя генә бирелеп килде. Һичшиксез, бу тарихи гаделсезлек, ә гаделлек исә аны милләтебезнең асыл затларына кертүдә булыр иде. Муса әфәнденең аңа ихтирамы искиткеч зур була. Монысы да юкка түгелдер. Алар Төркиядә танышканнар булса кирәк. Гомер буе алар бер-берсен аңлап яшиләр.

Рәшит Казый Ибраһимов йогынтысы белән Муса Бигиев тә бөтен көчен Россия мөселманнарының съездын оештыруга бирә. Мәгълүм ки, мөселманнарның беренче съезды 1905 елның 15 августында Ока елгасында «Густав Струве» пароходында уза. Монда сайланган үзәк комитетка Петербургта Рәшит Ибраһимов мөхәррирлегендә чыга торган «Өлфәт» һәм «Әт-Тилмиз» газеталарының хезмәткәрләре, Петербург университетының ирекле тыңлаучысы Муса Бигиев тә керә.

Муса Бигиев моннан соң булган барлык мөселман съездларында катнаша. Ул һәрвакыт съездларның документларын хәзерләүдә булыша, секретарьлык вазифаларын башкара. «Мөселман иттифагы»ның уставын да Муса Бигиев төзегән. 23 пункттан торган бу устав буенча Россиянең мөселманнар яшәгән губерналары 15 районга бүленә һәм районнарның хокуклары билгеләнә. Уставта ел саен 15 август көнне съезд уздырылырга тиешлеге күрсәтелә. Шунысы да игътибарга лаек, «Иттифак»ка әгъза булып кергән һәрбер кеше оешманың һәрбер карарына һәм таләбенә буйсынырга тиеш була.

Беренче съезд хакында Муса Бигиев үзенең хатирәләрен язып калдыра. Менә шуннан бер өзек:

«Съезд тәмамлангач, төнге сәгать унбергә якынлашканда пароходыбыз Мәкәрҗә пристанена җитеп килә иде: кинәт һәммә кешедә бер курку уянды. «Әгәр безне

полиция көтеп торса, нихәл итәрбез? Шул язулы кәгазьләрне (карандаш белән язылган протокол кисәкләре), карарларны, актларны кайда сакларбыз? Пароход пристаньга якынлашкач, безне гаскәр чолгап алса, ни эшләрбез?» Бу вәсвәсә һәммәнең йөрәген каплады. Исмәгыйль бәк Гаспринский: «Шул кәгазьләрне суга ташлагыз, мин алмыйм»,— диде. Кәгазьләрне бер-берсенә бирделәр. Ләкин һичкем кабул кылмады. Ахырда Рәшит әфәнде алды. Ни булса булыр, һәрхәлдә бу кәгазьләрне сакләрмын, диде (Муса Бигиев. Исляхат әсаслары. Петроград, 1916, 171—172 б.).

Кача-поса гына барлыгы биш съезд уздырыла. Һәм нигездә «Иттифак» дигән «бала» тумас борын үлә. Сәбәбе бар: бу чорда мөселманнар берлеге инде хыял гына була, чөнки Россиянең төрки халыклары күптән мөстәкыйль юлга баскан булалар. Күпме генә тырышсаң да, аларны бер милләт итеп булмый. Күрәсең, шушы проблема Муса әфәндене федерация мәсьәләсе белән кызыксынырга мәҗбүр итә. Ул Россиядә туып килүче федератив хәрәкәт белән якыннан танышмакчы була. Шушы ният белән ул хәтта федералистлар съездында да катнаша, хокук белгечләре белән элемтә урнаштыра. Бу вакыйга беренче рус революциясе елларына туры килә.

Федерация ысулында төзелгән дәүләттә мөселманнар берлеге булырга мөмкинме? Төрки берлек реальме?

Бу сорауга җавап бирү җиңел түгел. Муса Бигиев төрки халыкларны бер милләт итеп укмаштырып булмавын аңлый булса кирәк. Шулай ук бөтендөнья мөселманнарын бер кыршау белән тарттырып кую мөмкин түгеллегенә дә инана. Тик шулай да мөселманнар өчен әхлакый берлек, бер-береңә ярдәмләшү, мәдәни-икътисади элемтәләр урнаштыру, шәригать кануннарына буйсыну, аларны ничектер оешкан төскә кертүне ул мөмкин дип саный.

Монда шунысын ачык итеп әйтергә кирәк. Муса әфәндә мөселманлыкның практигы түгел, ә теоретигы була.

Гаделлек хакына тагын бер нәрсәне әйтеп үтәргә кирәк. Муса Бигиев, Рәшит Ибраһимов белән берлектә, ислам социализмы концепциясен эшли. Беренчелекне кемгә бирергә икәнлекне тикшерү кирәк түгелдер. Шулай да аларның бу бердәм идеяләрен Рәшит Ибраһимов 1906 елны мөселманнар съездына күтәреп чыга. Нотыгында ул «социализм исламга каршы түгел, ул исламга нигезләнгән»,— ди. Дөрес, аның дәлилләре бик беркатлы, примитив була. Имеш, пәйгамбәребез Мәккәдән Мәдинәгә күчкәч, хатыннарын һәм булган бөтен милкен үзенең тарафдарларына бүлеп биргән. Соңрак Муса Бигиев тә шуны кабатлый. Ләкин эш анда түгел. Муса Бигиев тә, Рәшит Ибраһимов та исламның гаделлеген күрергә тырышалар, аны социализмга тәңгәл күрәләр.

Форсаттан файдаланып, кайбер тарихчыларга һәм философларга тәнкыйть сүзе әйтәсем килә. Алар ислам социализмы концепциясен бүгенге көннең яңалыгы дип, әллә кайсы Азия һәм Африка илләреннән эзлиләр. Баксаң, бу идея безнең өчен һич тә яңалык түгел икән. Ул бездә гасыр башында ук туган.

Муса Бигиевне дулкынландырган тагын бер проблема — ул да булса, шәригать кануннарының хәзерге дөньяда тоткан урыны. Аны нәтиҗәле кулланып буламы, әллә инде аңардан бөтенләй баш тартыргамы? Бу темага ул бәхәсләр алып бара һәм Коръәнне һәм шәригать законнарын бүгенге көндә нәтиҗәле файдаланып була дигән фикергә килә. 1909 елны ул Оренбургка күчеп килә. Анда аны дүрт баскыч мәктәпне берләштергән атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе үзенә җәлеп итә: 1) «Ибтидаия» — өч еллык курслар башлангыч мәктәпкә тигезләнә; 2) «Рөшдия» — уку срогы өч еллык һәм ике класслы шәһәр училищеларына тәңгәл килә; 3) «Игъдадия» — дүрт еллык укудан тора һәм гимназия яки реаль училищелар дәрәҗәсендә санала; 4) «Галия»—анда өч ел укытыла һәм белем бирү университетка тигезләнә. «Хөсәения» юкка гына татарларның горурлыгы дип аталма-

гандыр. Муса Бигиевнең аны күрәсе һәм анда эшлисе килгәндер, күрәсең.

Ләкин аның үзен анда күрергә теләделәр микән? Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов кебек атаклы реформаторлар гына җитмәдеме икән Оренбургка? Билгеле, М. Бигиев Истанбул университетындагы укыту ысулларын, Петербург университетындагы тәртипләрне дә бик яхшы белгән. Ихтимал, «Хөсәения»не шул рәвешчә үзгәртергә дә уйлагандыр. Аның мәдрәсә эшенә тыкшынуы житәкчеләргә ошап бетми. Белмим, нинди җирлектәдер, мәдрәсә директоры Дәүләтшин, мөдир-инспектор Файрушин белән Бигиев арасында низаг чыга. 1910 ел башында Муса Бигиев мәдрәсәдән сөрелә. Ләкин шушы кыска гына вакытта да уку йорты тормышында тирән эз калдырып китә.

1911 елның гыйнварында төзелгән жандармнар берләшмәсендә: «Оренбург губернасында панисламизм пропагандисты буларак, С. Петербург университетының элеккеге ирекле тыңлаучысы Муса Бигиев игътибарны җәлеп итә», диелгән. Анда ул 1909 елдан башлап Оренбург мәдрәсәсендә укыта башлады һәм, педагог буларак, үзен сул панисламчы итеп танытты, шунлыктан уку вазифаларыннан азат ителде, диелгән.

Шулай да Муса әфәнде төшенкелеккә бирелми. Ул «Шура» журналы битләрендә бәхәсле темалар күтәреп чыга, рефератлар яза, лекцияләр укый. Ул «Вакыт» газетасына да күп яза. Мәкаләләрендә төрек шәйхел-исламнарының җинаятьләрен дәлилле тәнкыйтьли. Аның мәкаләсеннән өзек ике томлы бер җыентыкка да кертелгән. Бер үк вакытта ул сионизмны да утка тота, шигыйлыкны да читтә калдырмый. Соңрак ул шигыйлыкка хәтта аерым китап та багышлый. Шул рәвешчә губерна халкы алдында зур популярлык казана. Бу хәтта Тукай иҗатында да чагылыш таба. Халык шагыйре юк-юк дигәндә дә Муса әфәндене чеметкәләп куя. Мәсәлән, аның түбәндәге юллары игътибарны җәлеп итә: «Арыслан бе-

лән юлбарыс яратылган бер каннан: Безнең Муса һич тик тормас — ялгыш тапкан Коръәннән».

Бу юллар 1909 елда язылган, ягъни М. Бигиевнең Оренбургка күчеп килгән елына туры килә. Тукай аның «Рәхмәте илаһия гомуми» (1910) китабын да игътибарсыз калдырмый. Шул китап уңаеннан ул «Зур бәшарәт» исемле шигырь яза.

Билгеле булганча, Самара, Уфа аша 1912 елның язында Габдулла Тукай кымыз белән дәвалану нияте белән Троицкийга таба сәфәр тота. Ләкин сәфәре уңышсыз булу аркасында, күрәсең, Муса Бигиев чакыруы буенча, ул Петербургка килә һәм вокзалдан турыдан-туры аның фатирына килеп төшә.

Тукай килү вакытын алдан хәбәр итмәгәнлектән, Бигиев кунакханәдән урын хәстәрләмәгән була. Шунлыктан Тукай берничә көн аның дүрт-биш бүлмәле фатирында яши.

Муса Бигиевнең эш рәвешен Тукай болай тасвирлый: «Мин Муса әфәнденең эш бүлмәсендә (рабочий кабинетында). Бүлмә әнваг (төрле) гарәби китаплар белән тулы. Язу өстәле бер көн, өченче көн, кичә, аннан элек, әлегенә язып ташлаган материалларга күмелгән. Муса әфәнденең иртәнге чәе дә, көндезге ашы да, кичкесе дә язу өстәлендә эш арасында, между прочим гына, ашалып, эчелә».

Тукай Петербургка инде шактый авыру хәлдә килә. Ул үзенең М. Бигиев кабинетында «Муса әфәнденең үзе ята торган кроватенда авырып, йөткереп, гадәт буенча папирос тартып» ятканлыгын сөйли. Шушы эш бүлмәсендә Тукаебыз биш көн яши. Тукайның язуыннан аның Бигиевне ничек хөрмәт иткәнен сизәсең. Күрәсең, Бигиев үзе дә бөек халык шагыйрен чын күңеленнән яраткан, аның ачы һәм авыр язмышын кулыннан килгәнчә җиңеләйтергә тырышкандыр.

Әле бүгенгечә Тукай белән Бигиевнең мөнәсәбәтләре тиешенчә ачыкланмаган. Бу ике зур әһел, әлбәттә, бер-

берен юкка гына шулкадәр якын итмәгәннәрдер. Аларның бер-берсенә булган йогынтысы киләчәктә тиешле яктыртылу табар дип уйларга кирәк.

Үз илендә Муса Бигиевкә каршы чыгучылар булса да, башка илләр аны таный. Уфа жандарм идарәсе белешмәсеннән күренгәнчә, Муса Бигиев һәм Фарвазетдин Ямалетдинов Төркиянең бер югары уку йортында профессор исеменә лаек булалар. Аның зур галим икәнен танып, 1911 елда янына Америкада яшәүче әфганлы галим Имандар Халхал килә.

«Каспий» газетасы үзенең 1913 ел 21 август санында Россиягә Төркиянең вакыфлар министры Мөхәммәт Асад әфәнде килүен хәбәр итә. Ул Казанда да була. Аңа исламда эволюция булырга мөмкинме, дигән сорау бирәләр. Моңа каршы ул: исламда «Ля иләһә иллә Аллаһе» гына үзгәрешсез кала, ди. Аның калган өлешләре заман таләпләренә карата үзгәрергә тиеш, дип җавап бирә. Шушы уңайдан ул Муса Бигиевнең әсәрләренә дә югары бәя бирә. Әгәр дә Петербургта булсам, һичшиксез, аның белән күрешәчәкмен, ди. Шушы уңайдан Муса Бигиевнең русның күренекле шәрекъ белгечләре Бартольд, Крачковский һәм Самойловичлар белән дусларча бәйләнештә торганлыгын да әйтеп үтәргә кирәк.

Бу инде Муса Бигиевнең дөнья күләмендә танылган галимгә әйләнүе турында сөйли. Галимнең галимголямаларны җәлеп итә торган әсәрләре бер-бер артлы чыгып тора. Юк, ул дин турында гына язмый. Аны дөньяви проблемалар да нык кызыксындыра. Мәдәният, сәнагать (промышленность) үсеше мәсьәләләреннән дә читтә торып кала алмый ул. Аны фәнни-техник прогресс та кызыксындыра. Ул җәмгыятьтәге процессларны аңлап эш итә. Мәсәлән, 1915 елда Казандагы «Мәгариф» нәшрияты Муса Бигиевнең «Банк процентлары хакында» исемле хезмәтен бастырып чыгара.

Күпләрне борчыган кебек, аны да милли мәгариф эшләре нык борчый. Ул Россия шартларында халыкка

белемнең тик мәчетләр, мәдрәсәләр, Диния нәзарәте аша гына таралганын яхшы белә, шунлыктан Диния нәзарәте эшләренә реформа кирәклеген сизә. Аны ул нәүбәттәге мөселман съезды чакыру юлы белән хәл итеп булыр дип ышана.

1914 елның 10—25 июнендә Эчке эшләр министрлыгы рөхсәте белән Петербургта Диния нәзарәтен һәм дини мәктәпләрне реформалаштыруга багышланган җыелыш үткәрелергә тиеш була. Бу җыелышта Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясенең катнашырга тиешле 6 депутаты һәм 33 дин әһеле арасында Муса Бигиев тә була. Ул үзенең чыгышында: «Без күбрәк рухи мәсьәләләргә игътибар бирергә тиешбез... без аларны тәртипкә салсак, башка эшләребез дә төзекләнер», ди.

Күренгәнчә, Муса әфәнде үзен руханилар арасында түгел, ә практикларга якынрак хис итә. Асылда исә ул дин эшлеклесе, дин галиме булып кала. Киң җәмәгатьчелек тә аны шулай кабул итә. 1917 елның маендагы Мөселманнар съездында аның кандидатурасы да мөфтилеккә сайлау бюллетененә кертелә. Бу вакыт мөфтилеккә ул да, Садри Максуди да үтмиләр. Тавышларның күпчелеге Галимҗан Галиев (Баруди) файдасына бирелә. Соңрак Муса Бигиев Петербург имамы вазифаларын үти.

Муса Бигиевне Октябрь революциясен кул күтәреп дога кылып каршы алган дию чеп-чи ялган һәм арттыру булыр иде. Ул революцияне кабул итә алмый, чөнки аның җиңүендә ислам диненә, гомумән мөселманлыкка зур куркыныч янаганны күрә. Шунлыктан ул, бик күп дин әһелләре кебек үк, мөселманнарны революциядән читтә калырга өнди. Ул үзе өчен һәм барлык Россия мөселманнарына шундый сорау куя: «Фараз кылыйк, моннан соң Россия хөкүмәте Төркия дәүләтенә сугыш ачты, ди. Шул вакыт Төркия хөкүмәте Россия мөселманнарыннан ярдәм сораса, безнең хәлебез ничек булачак?» Аның уенча, мөселманнар Төркиягә каршы сугышырга тиеш түгелләр.

Шулай итеп, ул яңадан ислам берлеге идеясенә әйләнеп кайта. 1920 елда ул «Исламият әлифбасы» исемле китап яза. Аны Гаяз Исхакый редакцияләгән һәм 1923 елда Берлинда бастырып та чыгарган. Менә шул китабында ул яңадан мөселманнарның теле, әдәбияты, дине күзәткән максатларның табигате бердәм дигән фикерне алга сөрә. Муса Бигиев революция җиңгәннән соң иленнән китми. Ул үзен халыкка кирәк саный. Безгә В. И. Ленинның М. Бигиевне кабул иткәнлеге мәгълүм. Сөйләшүләр ни турында баргандыр, анысы караңгы. Ләкин бу факт үзе генә дә зур игътибарга лаек.

Баштарак чыннан да Бигиев белән хисаплашалар, киңәшәләр. Мәсәлән, Төркестан суды реформа үткәргән елларда Төрки комиссия рәисе Элиава имзасы белән җибәрелгән телеграммада аны, шәригать кануннарын яхшы белүче буларак, Ташкентка суд реформасы эшләрендә эксперт итеп җибәрелүе сорала.

Ләкин бу хәл озакка бармый. Муса Бигиев көннән-көн үзенең кирәксезлеген тоя. Аның фәнни эшләрен бастыру елдан-ел кыенлаша бара. Аны эзәрлеклиләр. Кызганыч, әмма факт, аңа каршы чыгучылар арасында заманында Бубилар белән дуслык элемтәсендә торган, прогрессив фикерле мулла Абдулла Сөләймани да була. Ул 1930 елда Мәскәүдә җомга намазы вакытында Муса әфәндене хурлап сүз сөйли. Муллага башкалар да иярә. Бервакыт Ленинградта аңа хәтта трамвайда да начар сүзләр әйтеп бәйләнәләр. Бу хәлләр аны үзе өчен авыр карар кабул итәргә мәҗбүр итәләр: 1930 елда ул гаиләсен калдырып чит илгә китә.

Чит илләрдә ул фәнни эшен дәвам итә. Аны бигрәк тә Коръән иңгән гарәп илләре кызыксындыра. Ул күп яза һәм үзенең фәнни абруен ныгыта. 1931 елда ул шәхси чакыру нигезендә Иерусалимда Мөселман конгрессында катнаша. Ләкин читтә яшәсә дә, ул илен, халкын, гаиләсен бервакытта да онытмый. Гомеренең соңгы елларында, хатынына мәгълүм булганча, ул илгә

кайту юлларын эзләгән, моның тиешле хәстәрләрен күргән. Тик кайтырга гына өлгерә алмаган. Бу дөнья-күләм зур галимнең тормышы 1949 елда Каһирәдә өзелә. Муса Бигиевнең басылган күпсанлы хезмәтләре бар. Шулай ук күп кенә басылмаган хезмәтләре дә кала. Алар арасында Коръәннең татарча тәрҗемәсен әйтеп китәргә кирәк. Ләкин ул тәрҗемәнең язмышы безгә әлегә мәгълүм түгел. Аны Казанда дигән сүзләр дә йөри.

Хәзерге чорда халкыбызның дини-мәдәни мирасына игътибар бирелә башлады. Мәшһүр галим Муса Бигиев хезмәтләре дә акрынлап дөнья күрер дип ышанырга кирәк.

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ ТАТАР ТАРИХЫ

Бу мәсьәлә әлегәчә фәндә бик начар тикшерелгән. Шунлыктан мин бу мәкаләмдә, аны тулысы белән ачуны максат итеп куймастан, кайбер аспектларын гына билгеләүне кирәк таптым.

Мәсьәлә ким дигәндә өч төрле аспектта тикшерелергә мөмкин. Беренчесе — әдипнең тарихи карашлары, икенчесе — аның гамәлдәге тарихка керткән шәхси өлеше, өченчесе — Гаяз Исхакый әсәрләрендә татар тарихының чагылышы.

Өченче аспектка карата мөнәсәбәтләр инде күпмедер дәрәҗәдә белдерелгән булганлыктан, анысын күбрәк әдәбиятчыларга калдырып, бары тик бер фикер генә әйтеп китүне кирәк саныйм. Гаяз Исхакыйның әдәби әсәрләрендәге тарихи материал тулысы белән гаделлек һәм дөреслек таләпләренә җавап бирә. Мин бу очракта җәмәгатьчелектә каршылыклы фикерләр уяткан «Зөләйха» пьесасының Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендәге премьерасын истә тотам. Шунлыктан аның турында матбугатта бөтен кешегә аңлашырлык объектив рецензия булырга тиеш.

Анда Г. Исхакый пьесасының тарихи объективлык һәм дөреслек принципларына туры килгәнлеген, сурәтләнгән фаҗигале вакыйгаларда татар халкының гомуми фаҗигасе чагылганын күрсәтеп үтү зарурдыр.

Инде әдипнең тарихи карашларына әйләнеп кайтыйк. Аларны без аның публицистикасыннан, бигрәк тә «Таң», «Таң йолдызы», «Ил», «Яңа милли юл», «Милли байрак» газеталарындагы материалларыннан төсмерли алабыз. Өстәвенә без бүген киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм «Идел-Урал», «Олуг Мөхәммәт», «Казан тарихы» әсәрләрендә Исхакыйның татар тарихына караган концепциясе бар икәнлеген әйтергә тиешбез.

Бу тарихи әсәрләрне ул күп төрле татар, рус, төрек, инглиз, гарәп телләрендә басылып чыккан тарихи әсәрләргә һәм чыганакларга таянып язган. Алар белән танышканда без авторның тарихи гаделлек һәм объективлык принцибына һәрвакыт турылыклы булганлыгын икърар итәргә тиешбез.

Г. Исхакыйның тарихи карашларын тикшергәндә аның бигрәк тә өч проблеманы алга сөргәнлеге күзгә ташлана. Аларның беренчесе — татарның этник чыгышы һәм төрки дөньядагы урыны, икенчесе — татар бәйсезлеге һәм социализм, өченчесе — татарның киләчәге.

Әлбәттә, һәр төрле бүлеп карарга тырышу шартлы гына була ала. Тормышта исә алар уралып баралар. Бу Исхакыйның татар тарихына булган карашларының өч аспектына да кагыла. Алар берсеннән-берсе аерым яши алмый. Тик шулай да, әгәр дә мин Исхакыйның тарихи карашлары киләчәккә юнәлдерелгән дисәм, һич тә ялгышмам дип уйлыйм. Тарихка мөрәҗәгать итү аның өчен бер сорауга җавап алырга тырышудан килеп чыга. Татарның киләчәге бармы, аның дәүләте яңадан аякка басармы, татар яңадан шөһрәтле милләт була алырмы? Г. Исхакыйның төшенкелеккә бирелгән вакытлары да була. Гомумән, ул хис кешесе була. Ләкин нигездә ул һәрвакыт оптимист булып калган. Аның

1912 елгы бер хатында болай диелгән: «Авыр еллар үтәр, безнең урамга да бәйрәм килер...»

Шунлыктан Г. Исхакыйның тарихи әсәрләре әлеге оптимизм рухы белән сугарылган. Ул татарны төрки дөньяда яралган, шунда яши һәм киләчәге дә шул дөньяга бәйле булырга тиешлеген беренче урынга куя. Шул сәбәпле аның өчен болгарлык белән татарлык арасында каршылыклар юк. Ул Болгар чорын һәм борынгы төрки дәүләтләр яшәгән дәверне татар тарихының шөһрәтле бер дәвере итеп кабул итә. Алтын Урда чорын да ул үз тарихыбыз дип таный. Болгарларның монголлар тарафыннан яулануында бернинди дә фаҗигә күрми. Болгар ханлыгының Алтын Урдага кушылуында ул зур сәяси әһәмият күрә, икътисади яктан да бернинди югалту булмаганын күрсәтә, болгарларның һәм яу белән килүчеләрнең кушылуы нәтиҗәсендә тарих сәхнәсенә «Казан татарлары» дигән халыкның күтәрелүен исбатлый. (Гаяз Исхакый. Идел-Урал, Яр Чаллы, 1992, 9 бит.)

Казан ханлыгының, гомумән, барлык төрки дәүләтләрнең дә тарих сәхнәсеннән төшүенең бер сәбәбе итеп Г. Исхакый алар арасында бердәмлек булмауны күрә. Ул Казан халкының ярдәм сорап Төркиягә, Кырым ханына, Нугай урдасына мөрәҗәгать иткәнлегенә басым ясый. Ләкин төрек солтанының, Кырым ханының шушы мөрәҗәгатькә тиешле әһәмият бирмәүләрен, ә нугайларның ярдәм урынына үзебенең халыкны талап йөргәнлекләрен ачынып яза (Шунда ук, 15 бит).

Бәйсезлегебезне югалтуның бер сәбәбе тиешле төрки бердәмлекнең булмавы кебек, бәйсезлекнең яңадан кире кайтуының шарты да төрки бердәмлек булдыру икәнлеген Исхакый кат-кат яза. Бу очракта без аны пантөрекче дип тә атый алыр идек. Әлбәттә, бүгенге көндә бу төшенчәдә нинди дә булса тискәре төсмер булуы мөмкин түгел. Тугандаш халыкларның бердәм булырга тырышуына тик изге тойгыларның чагылышы

итеп кенә карарга кирәк. Аны халыклар арасына чөй кагарга тырышу дип карау тамырдан дөрес түгел. Чөнки тугандаш халыкларның үзара дустанә яшәүләре бөтендөнья өчен тынычлык һәм стабильлек факторы икәнлеген бүгенге тарих үзе исбат итә. Әнә Югославиядә шундый дуслыкның, бердәмлекнең булмавы нинди фаҗигаләргә китерде.

Шулай да төрки халыкларның бердәмлеген булдыру мәсьәләсендә Гаяз Исхакый кайвакыт Төркиянең ролен кирәгеннән артык күпертеп күрсәтә сыман. Чыннан да Казан ханлыгының, гомумән, татар ханлыкларының бәйсезлекләрен югалтуның төп сәбәбе Төркиянең ярдәмгә килә алмавында түгел, ә татарларның үзара бердәмлеге булмауда бит. Мәскәү патшасы Казанга һөҗүмне сиздермәстән ясамый. Моңа ул ачыктан-ачык һәм бик озак әзерләнә. Казанлыларның күз алдында, татарның үз җирендә Свияжск корылмасын сала. Казанның җитәкче даирәләре моны күрмәгәнмени? Мәскәүнең 150 меңлек гаскәренә каршы торырлык көче булмаганмыни? Нигә Казанны нибары эчке ягында 30 мең, тышкы ягында 30 мең кеше генә яклаган һәм саклаган?

Бүген дә бәйсезлек юлына баскан татар милләте, беренче чиратта, үзенә ышанып, үз көченә таянып эш итәргә тиеш. Без үзебезне төрки дөньяның бер өлеше итеп хис итик, бердәмлегебезне ныгытыйк. Ләкин иң беренче сызыкка үзебезнең оешканлыгыбызны һәм бердәмлегебезне куйыйк.

Г. Исхакый да бәйсезлек өчен көрәштә бердәмлек факторын алга сөрә. Мин исә бу очракта сүзне кайбер приоритетлар турында гына алып бармакчы булам.

Г. Исхакый СССР дигән дәүләтнең мәңгелек булмаячагына ышана. Ул аның җимереләчәген алдан күрә. Соңгы вакытта профессор Хатип Миңнегулов бастырып чыгарган «Бүгенге вазгыятебез вә безнең вазыйфамыз» исемле 1935 елда «Яңа милли юл» журна-

лында урнаштырылган мәкаләсендә Гаяз Исхакыйның бу ышанычы бик ачык күренә. Алай гына да түгел, аны чын мәгънәсендә алдан күрә белү дип атап булыр иде. (Х. Миңнегулов. Гаяз Исхакый фаразлары. «Татарстан», 1992, № 9—10, 49—52 б.)

СССР дәүләте сүздә социализм нигезенә корылган булганлыктан, Исхакыйның социализмга булган мөнәсәбәтен ачыклап китәргә кирәк. Г. Исхакый тарихи мәйданга чыккан дәвердә дөнья социализмны бер модага әйләндергән була. Соңрак социализмның дошманы булып әверелгән шәхесләр дә аның белән мавыгып алалар. Хәтта кадетлар да тарихның кайсыдыр бер ерактагы пунктында социализм принципларының тантана итү мөмкинлекләрен күрәләр.

Г. Исхакый исә социализмны гаделлек принцибына тиңли. Социаль һәм милли гаделлек тантана итәргә тиешлегенә ышана. Шунлыктан ул аңлы тормышының башында ук социализм лозунгысын милли азатлыкны тормышка ашыру инструменты итеп таный. Әлбәттә, монда сүз Исхакыйның үзе турында гына түгел, башка яшь ихлас йөрәкләр турында да бара. Хөсәен һәм Хәдичә Ямашевлар, Гомәр Терегулов, Фуат Туктаров, Галимҗан Ибраһимов, Ибраһим Әхтәмов, Шакир Мөхәммәдьяров һәм башкалар шулай ук социализмга инаналар.

Юкка гына түгел, жандарм идарәсендә җыелган мәгълүматларда Г. Исхакыйның 1904—1905 елларда европача белем алган татар яшьләреннән торган түгәрәк төзегәнлеге һәм «Таң» газетасын чыгарганлыгы күрсәтелгән. Шунысы кызыклы, бу түгәрәкнең 1905 ел башында — 1905 ел ахырында икегә бүленеп, берсе — эсерларга, икенчесе — социал-демократларга кушылганлыгы күрсәтелә. Шунда ук Г. Исхакыйның исламчы яшьләрне җитәкләгәнлеге дә әйтелә. (Кара: ГАОО, ф. ДПОО, 74 бүлек, 92-Б, 2 б.)

1911 елның 31 августында жандармерия идарәсе

төзегән белешмәдә Петербург югары уку йортларында исламчылык пропагандасы алып барылганлыгы һәм аны алып баручылар арасында Шакир Мөхәммәдьяров, Мәхмүт Терегулов, Алима Терегулова, Садри Максуди, Минсәет Җәмилов, Лотфулла Исхаков һәм Муса Бигиевләр күрсәтелә. Анда, алар бер-берсен яхшы беләләр һәм сөргеннән качкан күренекле революционер һәм әдәбиятчы Гаяз Исхаковны яшерәләр, диелгән (Шунда ук, 74 бүлек, 57, 1 б.).

Күренә ки, милләтебезнең күренекле шәхесләре дә социализм идеяләре белән мавыкканнар. Тик аларның барысы да диярлек моны татарның азатлыгына ирешү юлы итеп кенә караганнар. Гаяз Исхакый да социализмны төп максат итеп куймый. Дөрес, вакыты-вакыты белән ул да, үзенең бик күп көрәштәшләре кебек үк, бәлки, аңа кирәгеннән артык игътибар биргәндер. Мәгълүм ки, Рәшит казый Ибраһимов якын көрәштәше Муса Бигиев белән ислам социализмы концепциясен дә булдырырга тырышалар. Бу аларның чын социализмны гаделлеккә юл дип карауларыннан килә. Алай гына да түгел, шушы ике зат башлаган эш ислам социализмы исеме астында дөньяга тарала. Социализм юлына басканнар арасында берәүләр аннан бик тиз тайпылалар, икенчеләре күпмедер вакыт шул юлдан баралар. Ләкин вакыты җиткәч, социализм һәм милли принциплар арасында приоритетлар билгелиләр.

Билгеле булганча, Беренче бөтендөнья сугышы башлануга Көнбатыш илләрнең күпчелек социалистлары, гомумән, II Интернационал милли патриотизм юлына күчәләр, дөньякүләм социализм принцибына үз илләрен саклау принцибын каршы куялар. Тик большевиклар гына, милли ватанга инанмастан, пролетар интернационализм принцибын алга сөрделәр. Моңарчы коллыкта яшәгән халыкларның социалистлары исә бигрәк тә авыр хәлдә калалар. Сугыш аларны да тиешле позиция сайларга мәҗбүр итә.

Бу очракта Гаяз Исхакыйның көрәштәше, поляк социалистларының атасы саналган Юзеф Пилсудскийның позициясе гыйбрәтле. Ул да социализмга инанып, аны милли бәйсезлеккә тәңгәлләштереп килгән шәхес. Ләкин вакыты җиткәч, ул приоритет итеп милли бәйсезлекне сайлаган, үзе әйтмешли социализм поездыннан милли бәйсезлек тукталышында төшеп калган.

Гаяз Исхакый хакында да шулай дип әйтеп булыр иде. Ул да социализм поездыннан вакытында сикереп төшеп кала алган. Ләкин аерма шунда ки, Пилсудский, яки Грузия социалистларының башлыгы Жордания поездан ялгыз гына төшмичә, бик күп курку белмәс тарафдарлары, үз илләренең ватанпәрвәрләре белән бергә төшеп калган булсалар, Исхакыйлар ялгыз булалар. Татарларның күпчелек социалистлары социализм поездына ахыргача утырып бардылар. Поездны алып баручы юлбашчылар аларның кайберләрен поезд көпчәкләре астына сала килде, ә күпләренең язмышын максатка барып җиткәч хәл иттеләр. Шуның белән милләтне дә төрле фиркаләргә бүлгәләп төп башына утырттылар.

Гаяз Исхакыйның исә вакытында кемнең кем икәнлеген аңлый алуы, бер яктан, аның зирәклеген күрсәтсә, икенче яктан, аның шәхси фаҗигасенең бер сәбәбе була. Ләкин ул һәрвакыт халкына турылыклы булып кала. Үзенең шәхси язмышын фаҗига итеп кабул итми. Чөнки ул тарихның барышын дөрес чамалый. Үз күз алдында чәлпәрәмә килә башлаган империяләрнең язмышын үткән заман империяләре белән чагыштыра. Һәммә империянең дә, нинди генә киемгә киенгән булуына карамастан, юкка чыгасына ышана. Ул тарихның барышы барлык халыкларга да азатлык китерәчәгенә шикләнми. Шул турыда һәрвакыт язып та килә. Татарның киләчәгенә дә ышана. Менә шушы тарихи карашлар Г. Исхакыйның көрәш юлын да билгели. Шушы юлда ул милләтенең, халкының азатлыгына туры-

лыклы һәртөрле көч, һәрбер шәхес белән берләшергә әзер тора.

Төрки бердәмлек тарафдарларына аның мөнәсәбәте бигрәк тә җылы була. Шунлыктан ул гомере буе Исмәгыйль бәк Гаспралыга, Йосыф Акчурага ихтирамлы булып кала. Инде безнең әдәбиятта И. Гаспралыга карата мөнәсәбәт үзгәреп, әлеге зур шәхескә аның тарихтагы үз роле кайтарылып бирелде дияргә була. Ләкин әле Йосыф Акчура турында моны әйтеп булмый. Соңгы вакытта күренгән С. Даишев белән Н. Субаевның мәкаләсеннән башка берни дә юк дисәк, һич тә хата булмас. Тик менә Й. Акчураның төрки гомумлекне булдыруга күрсәткән хезмәтен без әле чамалы рәвештә генә дә күзаллый алмыйбыз. Ә бит аның 1908 елда ук дөнья күргән «Сәясәтнең өч системасы» дигән әсәре төркичеләр өчен дәреслек булган. Аны «Коммунистик манифест» белән тиңләгәннәр. Ә авторның үзен туранчылар (яки төркичеләр.— *И. Т.*) Марксы дип атаганнар. (М. Э. Расул-задә. О пантуранизме. Оксфорд, Англия, 1985, 47 б.)

Гаяз Исхакый боларның барысын да белеп эш иткән. Шунлыктан ул үзенең социализм белән мавыгып йөргән вакытларында да миллилек, төркилек, мөселманлык принципларыннан йөз чөермәгән. Ул үзенең тарафдарлары белән Нижний Новгородтагы мөселман съездларында катнашкан. Казан социалистлары белән бәйләнештә торган. Аның «Таң», «Таң йолдызы» газеталары тирәсендә оешкан тарафдарлары социалистлар белән генә эш йөртмәгәннәр. Алар дин әһелләрен, мәдрәсәдәге шәкертләрне дә үзләре белән бергә эшләргә өнди килгәннәр. 1907 елда сөргенгә Исхакый гына түгел, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җитәкчесе, соңрак мөфти булган Галимҗан хәзрәт Баруди да сөрелә — бу юкка түгелдер. Сәбәбе — аларның һәм сөрелгән башка милләттәшләребезнең татар азатлыгына турылыклы булуында.

Кайвакыт Г. Исхакый русларны, гомумән, төрки булмаган башка халыкларны сөймәгән дигән сүзләр ялгышрак. Бу дөреслеккә туры килми. Ул тик русның түрәләрен, миссионерларын, татар бәйсезлегенә каршы булганнарын гына яратмаган. Ләкин Лермонтов, Тургенев, Толстой, Горькийга һәм русның башка бөек шәхесләренә, гади халыкка ул бик ихтирамлы булган. Яһүдләргә дә кыек күз белән карамаган. Ул 1906 елны сөргеннән бозлы су кичеп ике яһүд белән качкан.

Ә менә кайбер милләттәшләре аның өстеннән шымчылык кыла килгәннәр. Шуларның берсе 1912 елда Санкт-Петербургта аның эзенә төшә, артыннан калмый йөри. Гаяз Исхакый исә монда башка исем астында качып яши. Артыннан барган шымчы бервакыт аңа үз исеме белән «Гаяз!» дип эндәшә. Адәм баласы ни эшләсен соң, үз исеме белән дәшкәч, борылып карый. Ә теге мөртәт татарга шул җитә кала. Шакир Мөхәммәдьяровның әйтүенә караганда, ул шушы көнне генә «Зөләйха» пьесасын тәмамлаган була.

Гаяз Исхакый татар бердәмлеген булдыруны беренче урынга куя. Баштарак әлеге бердәмлекне ул социализм байрагы астында булдырмакчы була. 1914 елдан башлап, ул Галимҗан Ибраһимов белән берлектә мөселман азатлык партиясен төзү эшен башлап җибәрә. Шул елны Галимҗан Ибраһимов, «Аң» журналы секретаре вазифаларын ташлап, Украина-Кырым аша Кавказга юнәлә. Аның шушы чордагы эшчәнлеге турында жандармнарда тулы мәгълүмат булган. Һәрбер адымы тикшерелеп-теркәлеп барган. Аның максаты «Дашнакцютюн» яки «Мусават» рәвешендәге партия төзү була. Шунысы кызыклы, Казаннан чыгып киткәндә, жандарм белешмәсенә караганда, ул үзенең иң якын кешесе булган Гаяз Исхакыйга кереп чыга.

Без әле Гаяз Исхакый һәм Галимҗан Ибраһимовларның үзара мөнәсәбәтләре турында тиешле мәгълүматка ия түгел. Чөнки алар һәрвакытта да дус булып

тормаганнар. Бу ике бөек шәхеснең үзара чын мәгънәсендә ихтирамлы чорлары да булган. Ә бер дәвердә фикер каршылыклары өскә бәреп чыккан ике дусны ике якка аерган. Юк, мин бу очракта Галимҗан Ибраһимовның «Кара маякларын» истә тотмыйм. Мәсьәлә, һичшиксез, тирәнрәк.

Инде әйтеп үткәнемчә, вакыты җиткәч, Гаяз Исхакый социализм поездыннан сикереп төшеп калган. Ә Галимҗан Ибраһимов исә үлгәнчегә кадәр социализмга ышанган. Алай гына да түгел, большевизмны кабул итеп, аны социализмның иң дөрес юлы дип таныган.

Әйе, моның ничек эшләнгәнлеге инде хәзер ачык. Ләкин тарихи дөреслек шунда ки, ике бөек шәхесне социализм киртәсе аерган: берсе киртәнең теге ягында калган булса, икенчесе бу ягына сикереп чыккан.

Милли бердәмлекне булдыру эшен Г. Исхакый эмиграциягә киткәч тә дәвам итә. 1919 елдан башлап ул күп илләрне гизә. Ерак Көнчыгыштан башлап, Парижга кадәр килә. Варшавада үзенең көрәштәше Ю. Пилсудский белән киңәш тота. Аңардан милли эшләрне башкару өчен ярдәм дә ала.

Инде тагын бер мәсьәләгә тукталып үтү кирәк. Еш кына Г. Исхакый Икенче бөтендөнья сугышы вакытында фашистлар белән хезмәттәшлек иткән, татар солдатларыннан Кызыл Армиягә каршы көрәшү өчен милли легионнар төзегән, хыянәтче булган икән дигән сүзләр ишетелгәли. Хыянәтче дигән сүз генерал Власовка карата дөрестер. Чөнки ул Совет властена турылыклы булырга ант иткән кеше. Антын бозгач, ул, һичшиксез, хыянәтче. Ә Гаяз Исхакый беркайчан да Совет хөкүмәтенә турылыклы булырга ант итмәгән. Ул, гомумән, Октябрь инкыйлабын кабул итмичә, большевикларга каршы көрәшергә сүз биргән кеше. Шуңа күрә аның эшчәнлеге, беренчедән, фактик яктан тулысынча тикшерелергә тиеш. Матбугатта булган кайбер ашыгыч бәяләр һич кенә дә хакыйкатькә туры килми. Икенче-

дән, әнә шул эшчәнлек объектив бәя алырга тиеш. Инде әйтеп үткәнемчә, Г. Исхакый Советлар властеның гаделлек принципларына дошман булганлыгыннан чыгып, аның тарихи яктан үлемгә дучар ителәчәгенә ышанып эш иткән. Ул читтән торып та Совет властеның барлык явызлыкларын илдә яшәгәннәргә караганда күбрәк белгән. Г. Исхакыйның тарихи эшчәнлеген бәяләгәндә боларның берсен дә онытырга ярамый.

Тагын шуны әйтергә кирәк, чит ил архивларында, мәсәлән, Варшавада Г. Исхакый турында материаллар күп булырга тиеш. Бу турыда инде кайбер мәгълүматлар да бар. Боларны без тикшерергә тиешбез.

Гаяз Исхакый моңарчы тарихыбызда таплы шәхес булып йөрде. Аның эшчәнлегенә, шул исәптән иҗат эшчәнлегенә дә, тискәре бәя генә бирелде. Инде заманалар үзгәрде, ул тарихта үзенең лаеклы урынын алды.

Бүгенге бәйсезлек өчен алып барган көрәшебездә без милләтнең барлык ватанпәрвәрләренең мирасын эшкә җигәргә тиешбез.

МӨФТИ ХӘЗРӘТ ГАЛИМҖАН ГАЛИЕВ (БАРУДИ)

Заманында Русия күләмендә исеме шаулаган Галимҗан хәзрәтне күбрәк Баруди фамилиясе аша беләннәр. Бу фамилия аһәңле булуына да карамастан, аны йөрткән шәхеснең борынгы данлыклы нәселдән түгел, ә дары-төтен арасыннан чыкканлыгын гына күрсәтә. Чөнки «баруд» сүзе гарәпчәдән татарчага «дары» дип тәрҗемә ителә.

Әйе, Галимҗан хәзрәт 1857 елда Қазанның Дары бистәсендә гади солдат гаиләсендә дөньяга килә. Аның атасы, күпме тырышуына да карамастан, вак сәүдәгәрлектән уза алмаган.

Бистә баласы яшьтән революцион идеяләрне тоеп яши. Эшче халык арасындагы хәрәкәт аның тормышына шактый йогынты да ясый.

1862 елдан 1874 елгача ул Казанда мәдрәсәдә укый. Шуннан соң Бохарага китеп 7 ел буе Мир Араб мәдрәсәсендә белем ала. Әлбәттә, Бохара инде Дары бистәсе түгел. Ул шулай ук эшчеләр шәһәре дә түгел. Монда эшчеләр түгел, ә мөселманнар, һөнәрчеләр, шәкертләр, руханилар яши. Монда азан завод-фабрика гудогына кушылып яңгырамый, ә йөрәкләргә үтеп керердәй бердәнбер тавышы белән бөтен тирә-юньне каплап ала.

Ләкин туган ил барыбер туган ил инде ул. Галимҗан 1881 елны, ниһаять, хәзрәт сыйфатында Казанның 4 нче мәхәлләсенә икенче имам булып кайта. Алган белеме шактый камил булганлыктан, ул бер үк вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта башлый һәм тиз арада аның җитәкчесенә әверелеп китә. Бу мәдрәсә ысулы җәдиткә күчә. Анда дөньяви фәннәр укыта башлыйлар. Галимҗан хәзрәт үзенең фикер йөртүе буенча, яшәү рәвеше белән чын-чыннан реформатор була. Ул дөньяның моннан соң болай Бохарача гына бара алмаячагына яхшы төшенә. Әгәр Русия мөселманнарының прогресс юлына басасылары килә икән, ул вакытта алар кичекмәстән заман таләпләренә җавап бирердәй мәктәп һәм мәдрәсәләр булдырырга тиеш. Алдынгы рус иҗтимагый хәрәкәте, революцион идеяләр мөселманнар тормышына да кагыла. Ул боларның һәммәсен аңлап эш итә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе юкка гына шул алдынгылык үзәгенә әверелмәгәндер. Анда татарлар гына түгел, Кавказ, Төркестан, Казагыстан яшьләре дә укый.

Галимҗан хәзрәтнең тырышлыклары белән мәдрәсә 1901 елда Тихвинский урамындагы яңа зур бинага күчә. Анда инде 300—400 шәкерт укый башлый.

Барудиның энергиясе һәм таланты шул кадәр көчле була ки, ул укыту, оештыру эшләренең иксез-чиксез булуына да карамасатн, бер үк вакытта гыйльми эш белән шөгыльләнүне дә ташламый. Ул яңа ысул

белән язган арифметика һәм татар теле дәреслекләре бик күп мәдрәсәләрдә кулланыла башлый.

Моңарчы Галимҗан хәзрәт турында тискәре фикерләр генә әйтелеп, безнең әдәбиятыбызда аның мәдрәсәсеннән бик күп күренекле кешеләр чыкканлыгын бөтенләй диярлек язылмый иде. Ә бит «Мөхәммәдия»дә Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Борхан Шәрәф һәм башка бик күп шәхесләр укыган.

Әгәр дә җәдитчелек хәрәкәтен дөрес һәм объектив рәвештә өйрәник дисәк, безгә бүгенге көндә Исмәгыйль бәк Гаспралыга, Галимҗан Галиевка (Барудига) булган карашларны үзгәртергә кирәк. Галимҗан хәзрәт чын мәгънәсендә новатор һәм реформатор була. Аның кадимилеккә каршы көрәше принципиаль нигездә алып барыла. Аңа каршы көрәшүчеләрнең төп көрәш ысуллары донос һәм анонимкалардан гыйбарәт.

Беренче рус революциясе еллары аның өчен менә дигән көрәш мәктәбе була. Ул гомумреволюцион хәрәкәттә дә, мөселманнар хәрәкәтендә дә актив катнаша. Алай гына да түгел, бу эшкә мәдрәсә шәкертләрен дә тарта.

1905 елның 17 октябрендә чыккан патша Манифесты җәмәгать эшләренең шактый куеруына китерә. Митингларда һәм башка төрле җыелышларда татарларны аерым автоном бердәмлек итү идеяләре тарала башлый. Шул идеяләрнең хәрәкәткә килүен һәм актив политик көчкә әверелүен теләүчеләр «Ислах» җәмгыяте төзиләр. Моның активистлары шәкертләр һәм иң активлары «Мөхәммәдия» шәкертләре була. Тиздән «Ислах» нигезендә «Берек» оешмасы барлыкка килә. Ул үзенең бурычы итеп самодержавиегә каршы көрәш һәм Учредительное собрание җыюны куя. Галимҗан хәзрәт өндәве нәтиҗәсендә шушы мәсьәләләрне тикшерү өчен 1907 елның маенда Казанда шәкертләр һәм мөгаллимнәр съезды ачыла. Шуннан соң Баруди начальство рөхсәтеннән башка «Берек» программасын яхшылап үзләштерү мак-

сатыннан шәкертләр һәм укытучылар өчен мәдрәсә каршында курслар ачып җибәрә. Ләкин властьлар аны ябалар. Шуннан соң шәһәр читендә мөселманнар җыелышы оештырырга булалар. Ләкин анда җыелган кешеләрне полиция куып тарата. Боларны оештыручы Габдулла Апанаев, Галимҗан Галиев, М. Казаков һәм башкалар җавапка тартылалар.

Безнең кулда Галимҗан хәзрәтнең үзе кебек реформаторлар булган Исмәгыйль бәк Гаспарлы, Йосыф Акчура, Рәшит Ибраһимовларга карата аның мөнәсәбәтен тулы ачыклаган мәгълүматлар юк. Ләкин бу әһелләрнең, бер-берен яхшы белеп, бер-берсенә таянып эшләгәнлекләре шик уятмый. Алай гына да түгел, инде мәгълүм чыганаклар аларның тыгыз дуслык мөнәсәбәтендә торганлыгын раслый. Русиядә вакытта Й. Акчура һәрвакыт диярлек Галимҗан хәзрәткә якын була. Шул ук вакытта Галимҗан хәзрәт Исмәгыйль Гаспралы белән дә дус була. Алар хат алышып торалар. Рәшит казый да бу кешеләрнең һәрберсе белән аралаша, хат аша да хәбәрләшеп тора. Гомумән, соңгысы, тынгысыз зат буларак, берәүгә дә тик ятарга ирек бирми. Билгеле булганча, «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручы да ул була. Р. Ибраһимов бу эшендә нәкъ шушы кешеләргә таяна. 1904 елның 26, 28 ноябрь көннәрендә җибәргән хатлар арасында Сөләйман Аитов, Галиәсгар Камал һәм Галимҗан Барудига багышланган аерым мәктүпләр бар. Бу хатларда нәкъ менә әлеге партияне гамәлгә ашыру өчен Минзәлә ярминкәсе вакытында киңәшмә үткәрү тәкъдиме әйтелә. Дөрес, ул вакытта киңәшмә булмый кала. Ләкин шунысы ачык, Галимҗан хәзрәт бу партиянең актив оештыручысы санала. Аның беренче һәм икенче съездларында катнаша. Оештыручыларның берсе буларак, президиумда утыра, 15 кешедән төзелгән Үзәк комитетның әгъзасы итеп сайлана. Ул анда кергән Абдулла Апанаев, Сәегтәрәй Алкин, Йосыф Акчура белән берлектә партиянең Казан бюро-

сын тәшкил итә. Бу партияне оештыруда Галимҗан хәзрәт шул кадәр активлык күрсәтә ки, аны хәтта, үзе сөргендә булуына карамастан, 1907 елның августында үткән IV съездда Йосыф Акчура һәм азәрбайҗан зыялысы Галимәрдән Тупчыбашев белән бергә бюро әгъзасы итеп тә сайлыйлар.

Биредә Галимҗан хәзрәт актив катнашкан бер әһәмиятле вакыйгага тукталып үтү урынлы булыр дип уйлыйм. 1906 елның 16—21 августында булып үткән II нче мөселман съезды Диния нәзарәтен үзгәртеп кору комиссиясе төзи. Аның председателе итеп Галимҗан Баруди билгеләнә. Комиссия 19 август көнне съездга 13 пункттан торган докладын тәкъдим итә. Анда үзгәртеп кору эше диния җыелышлардан һәм идарәләрдән башланырга тиеш диелә. Мөфтиләр моннан соң шәйхел-ислам дип аталырга тиеш булалар. Аларны 5 елга сайлау күздә тотыла. Мөфтиләр каршындагы Диния нәзарәте моннан соң Мәхкәмә вә Исламия дип аталырга һәм алар карамагына һәммә дини-укыту, җәмгыяте хәйрия эшләре күчәргә тиеш була. Алар шулай ук мәчетләр төзергә һәм ачарга рөхсәт бирергә хаклы. Шул ук вакытта мәктәп-мәдрәсәләр ачу аларны тоту өчен акча табу да алар бурычы. Мәхкәмә вә Исламия шулай ук вакыф милек өчен дә җаваплы. Имамнарга дәрәҗә билгеләү, бәхәсле мәсьәләләр, никах эшләре дә аларның тулы карамагында тиеш була. Шунысы кызыклы, һәрбер Мәхкәмә вә Исламиядә югары белемле юрист булырга тиешлеге дә карала.

Әлбәттә, бу документны идеал нигездә төзелгән дип әйтеп булмый. Шулай да аның ике моменты игътибарны җәлеп итә. Беренчесе, дин һәм мәгариф эшләрендә билгеле бер мөстәкыйльлек булдыру: мөфтине, Диния нәзарәтен яки Мәхкәмә вә Исламияне сайлап кую. Моңарчы мөфти хөкүмәт тарафыннан билгеләнеп килсә, моннан соң ул дәүләт чиновнигы булмыйча, фәкать дин хезмәтчесе санала. Икенчесе, дини эшләргә җитәкче-

лек итүдә демократик рух кертү, аның халык арасында абруен күтәрергә тырышу документта урын ала.

Комиссиянең эше уңышлы тәмамланса да, кабул иткән карарлар тормышка ашмый. Чөнки мөселманнарның теләге хөкүмәтне кызыксындырмый. Диния нәзарәте эшен элеккечә дәвам итә бирә. Хөкүмәт мәктәп эшләренә дә бернинди файдалы үзгәреш кертми. Шунлыктан беренче рус революциясенең соңгы елларында мәгариф эшләрен үзгәртеп кору реформаторларның үз эше булып кала бирә. Хөкүмәт исә аларны туктаусыз эзәрлекли. 1910 елда бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның мөселман дөньясында мәшһүр Иж-Буби мәдрәсәсе тар-мар ителә. Дистәләрчә алдынгы мөгаллим һәм муллалар кулга алына. Мәдрәсәләрдә, китапханәләрдә бертуктаусыз тентүләр үткәрелеп тора.

Билгеле булганча, 1907 елның 3 июнендә хөкүмәт II Думаны куып тарата һәм бөтен ил буенча революциягә катнашкан кешеләрне эзәрлекләү башлана. Шуннан соңгы дәвер тарихка реакция еллары дип керә. Татар зыялылары бу дәвернең авырлыгын үз җилкәләрендә татыйлар.

Бу ел Галимҗан хәзрәткә дә бик күп авырлыклар алып килә. Аның өстеннән җыелган материаллар хәрәкәткә китерелә. Нәтиҗәдә аны шәкертләре һәм көрәштәшләре белән җавапка тарталар. Документларның берсендә аның энесе Салихҗан, мулла Абдулла Апанаев һәм крестьян Мөхәммәт Исхаков белән берлектә хөкүмәткә каршы революцион пропаганда алып барганлыгы күрсәтелгән. Бу эшкә шәкертләрнең дә тартылуына аерым басым ясалган. Галимҗан Галиев 2 елга Вологда губернасына сөрелә. Анда ул 1907 елның 17 мартында озатыла. Әйтүемчә, аның белән бергә реформатор мулла Абдулла Апанаев та сөрелә. Форсаттан файдаланып бу шәхес турында да бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк. Ул да, Галимҗан хәзрәт кебек үк, татар халкын агарту эшенә, аңа ирек яулау хәрәкәтенә күп өлеш

кертә. Аның йортында күп еллар дәвамында төрле-төрле җыелышлар уздырыла, милли оешмалар урнашып килә. Ә гомере исә фаҗигале рәвештә тәгәлләнә. 1919 елның июнендә Казандагы татар батальонында фетнә кузгалган чакта, Камил Якубов үтерелгәннән соң, властьлар заложниклар алалар. Аларның барысы да атыла. Шулар арасында Абдулла Апанаев та була.

Инде кабат Галимҗан хәзрәткә әйләнеп кайтыйк. Ул сөрелгәннән соң да аның өстеннән донослар күп языла. Үз өстеннән генә түгел, шәкертләренә дә шактыйны татырга туры килә. Бер генә мисал. Әстерхан губернасының Таловка авылында «Мөхәммәдия»не бетергән Галләм Фәсхетдинов мөгаллимлек кыла. Аны Буада яшәүче берәү «Казан мулласы революционер Галимҗан Галиевнең эшен дәвам итүче» дип күрсәтә. Хәтта хәзрәтнең үз мәдрәсәсеннән, аның ипиен ашап ятучы Таһир Әхмәтҗанов та шуны раслап яза.

Галимҗан хәзрәтнең сөрген чоры документларында чагылмаган. Шулай да анда оҗмах булмагандыр, дип уйларга кирәк. Тик никадәр авырлыклар кичермәсен, ул бирешми, көрәш һәм мәгърифәт юлыннан һич тайпылмый. Ул бертуктаусыз эштә була, ә домшаннары һич тә тынмый.

1908 елның 20 июлендә Эчке эшләр министры Столыпинга мөселман муллалары исеменнән прошение килеп төшә. Бу документны кадимчеләр манифесты дип атарга мөмкиндер. Аның авторлары мәдрәсәләрдәге бик күп мөгаллимнәрне революционерлыкта гаепләүгә йөз тотканнар. Имеш, алар барлык авылларга тамыр җәйгән, халыкны бушлай укыталар, дингә хезмәт итәбез дисәләр дә, чынлыкта халыкны хөкүмәткә каршы алып баралар, аны коралландыралар. Шундый мөгаллимнәр тәрбияли торган урын итеп алар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен күрсәтәләр. Алар бу мәдрәсәне революция учагы дип атыйлар. Аннан чыккан мөгаллимнәр асылда революционерлар, алар, аллага һәм ислам диненә хезмәт

итүне сылтау итеп, мәдрәсәләргә халыкны юлдан яздыру өчен җибәрәләр».

1917 ел мөселманнар өчен кискен борылыш елы була. Февраль революциясе җиңеп, патшаның бәреп төшерелүе аларның милли тойгыларын уята, өметләренә реаль җирлек бирә. Шул елның май аенда Мәскәүдә булып үткән I Бөтенмөселман съезды башка зур мәсьәләләр белән бергә дин һәм мәгариф мәсьәләләрен дә карый. 1906 елны үткәрергә тырышып та тормышка ашыра алмаган карарлар яңадан калкып чыгалар. Әйтеп үтелгәнчә, ул вакытта Диния нәзарәтен үзгәртеп корып булмый, мәгариф эшләренә дә үзгәреш кертә алмый. Хәзер исә моның өчен яңа мөмкинлекләр туа. Съезд һичкемнән дә сорамастан дин мәсьәләсе буенча резолюция кабул итә. Анда Диния нәзарәтенең үзгәртеп корылырга тиешлеге күрсәтелә. Моннан соң мөфти тик сайланып кына куелырга тиеш була. Бу урынга альтернатив рәвештә Садри Максуди, Муса Бигиев, Габдулла Буби, Хәсән Габәши һәм Галимҗан Галиев (Баруди)ларның исемнәре тәкъдим ителә. Күпчелек 292 тавыш белән Диния нәзарәтенең рәисе һәм мөфти итеп Галимҗан Баруди сайлана. Бу беренче мәртәбә кулланылган демократик алым була. Чөнки моңа кадәр бу урынга кеше билгеләү тик хөкүмәт тарафыннан гына үткәрелә.

1917 елның июль аенда Казанда II гомуммөселман һәм хәрбиләр съезды белән бергә руханилар съезды да булып үтә. 22 июль көнне шәһәр театрында ул съездларның уртак мәҗлесе үткәрелә. Аны Коръәннән аять укып Галимҗан хәзрәт Баруди ача. Шуның өстәвенә ул, замандашларының әйтүенчә, кыска һәм гадәттән тыш үтемле котлау сүзе сөйли. Бу мәҗлестә Эчке Русия мөселманнары өчен милли мәдәни мохтарият игълан ителә.

Эчке Русия мөселманнарының милли-мәдәни мохтариятен игълан итү Диния нәзарәтенең эшчәнлегенә

башка төс бирә. Ул инде съездда сайланган эчке Русия мөселманнарны Милли идарәсенең Вөҗдани тәшкиләте[1] дип атала. Аның башында мөфти Галимҗан Галиев (Баруди) була. Шушы хакта хөкүмәткә махсус рәвештә хәбәр ителә. Бүгенгечә шул вакытта чыгарылган карарларның тиешле рәвештә тикшерелгәне юк. Ә бит шунсыз күп нәрсәне, шул исәптән 1917 елның демократик рухын, альтернативаларын тулысынча аңлап булмаячак.

1921 елны илгә зур ачлык килә. Бу афәт бигрәк тә Татарстан, гомумән татар халкына бигрәк тә авыр була. Татарстан җитәкчеләре республика төзелү хөрмәтенә Үзәктән бирелгән продразверстканы ул елны зур күтәренкелек белән кабул итәләр. Кайберәүләр хәтта өстәмә йөкләмәләр алу тәкъдимен дә кертәләр. Әлбәттә, бу язмада мин ачлыкның сәбәпләренә тукталып тормыйм. Хәзер исә ачлык афәтеннән котылуга Галимҗан Барудиның керткән өлеше турында бер-ике сүз әйтеп китмәкче булам. Чыннан да, ул шушы эшкә җаны-тәне белән бирелә. Татарстан хөкүмәте белән бердәм хәрәкәт итә. Помгол (помощь голодающим) эшендә актив катнаша. Ул ачларга ярдәм итүгә мөселман илләренең өлешен кертүне реаль эш дип саный, үзенең Төркия һәм башка илләрдәге элемтәләрен эшкә җигәргә әзерлеген белдерә. Тик шушы файдалы каналны эшкә җигүгә Көнбатыш илләре, аерым алганда Англия хөкүмәте комачаулык тудыра.

Галимҗан Баруди, авыру булуына да карамастан, изге максатларын тормышка ашыру нияте белән Помгол эшләре белән 1921 елны Мәскәүгә килә. Ләкин авыруы кискенләшеп китү сәбәпле ул Боткин шифаханәсенә эләгә һәм шунда вафат була.

Татарстан хөкүмәте мәшһүр хәзрәтнең эшчәнлеген тану йөзеннән аның мәетен алып кайту чараларын күрә.

[1] *Тәшкиләт* — министрлык.

Аны Казанда матәм тантанасы үткәрү рәвешендә каршы алу күздә тотылган була. Ләкин партия өлкә комитетындагы җитәкчеләр бу эшне тыялар. Галимҗан хәзрәт бик гади рәвештә генә күмелә. Үзе үлгәч тә дошманнары аның өстенә яла ягудан туктамыйлар. Имеш, ул гражданнар сугышы елларында Колчакка хезмәт иткән, Совет властена каршы булган. Болар барысы да уйдырма гына. Архивларда моны раслардай бер генә факт та юк.

Без бүген Галимҗан хәзрәт Барудины Мирсәет Солтангалиев яки Мулланур Вахитов кебек революционерлар белән янәшә куярга омтылмыйбыз. Моның һич тә кирәге юк. Ул моңа мохтаҗ да түгел. Тарихта һәркемнең үз урыны бар. Без бары тик тарихи гаделлекне торгызып, изге күңелле затны тарихтагы үз урынына куюны гына күз алдында тотабыз.

АЗАТЛЫК КАҺАРМАНЫ

Дөньякүләм шөһрәткә ия Мирсәет Солтангалиев хәзерге Башкортстанның Эстәрлетамак районы, Елембет авылында 1892 елның 13 июлендә туа. Аның атасы, гади авыл укытучысы булуына карамастан, киң карашлы, тирәннән фикер йөртә белүче кеше була. Шушы эшчән һәм мәгърифәтле гаиләдә унике бала туып, шуларның сигезе исән-сау кала.

Мирсәет бик тә үзенчәлекле булып үсә. Бер карасаң, ул бөтен дөньясын онытып татарлар һәм башкорт малайлары белән уйнап йөри. Икенче карасаң, тирән уйга чумып утыра. Ул укырга бик ярата, әйләнә-тирәдәге авылларның мәктәп китапханәләрендәге барлык китапларны диярлек укып чыга. Бигрәк тә Европа классиклары, рус демократ язучыларның әсәрләрен ярата. Үзе дә хикәяләр, шигырьләр яза башлый. Русчадан тәрҗемә дә иткәли.

Ничек итеп шушы авылда туып-үскән кеше бүгенге көндә дә таң калырлык тәгълимат барлыкка китерә алган? Ничек соң шушы тәгълимат азатлык өчен көрәшкән Азия һәм Африка халыкларына ярдәмче көч була алган?

Бәлки, моның сәбәбе Мирсәетнең изелгән халыктан чыккан булуындадыр.

Мирсәет яшьтән үк үтә сәләтле һәм зиһенле бала була. Табигый акылга ата-ана тәрбиясен дә өстәргә кирәктер. Атасы тәрбияләгән сыйфтлар арасында Мирсәетнең алдына куйган максатка тайпылышсыз бара белүен күрсәтергә кирәк. Аны дөнья никадәр кыйнаса да, ул беркайчан да үз халкының бәйсезлеге өчен көрәш юлыннан тайпылмаган.

Казанга Учительская школага килгән вакытта атасы Хәйдәргали ага улына юллык кына акча туплый ала. Ә инде калганын Мирсәет үзе кайгыртырга тиеш була. Гомумән, ул Казанга татарның яңарыш кичергән вакытында эләгә. Бу вакытта татарның дистәләрчә газета-журналлары чыга, милли театры гөрләп эшли, берсеннән-берсе сәләтле язучылары, журналистлары үсеп чыга. Аларның күпләре белән Мирсәет шәхсән таныш була.

Казанда укуын ул 1911 елны тәмамлап, бирегә тик 1917 елны гына әйләнеп кайта. Анда да ул Казанда бер елдан артык яшәми. Соңрак исә монда килеп-китеп кенә йөри. Ә 1937 елда кулга алынып Черек күл төрмәсенә китерелә.

1917 елга Мирсәет зур әзерлекле кеше булып кера. Шушы елның маенда Мәскәүдә булып үткән I Бөтенроссия мөселман съездында катнашып, мөселман дөньясының кеме бар һәм кеме юклыгын барлый, татар зыялыларының мөселман дөньясында лидер булганлыгына инана. Казанда ул Мулланур Вахитов белән дуслаша, ул төзегән Мөселман Социалистик комитетның актив эшлеклесенә әйләнә.

Ул большевикларның эшчәнлеген бик җентекләп өйрәнә. Гомумән, аларның изелгән милләтләргә азатлык бирү вәгъдәсенә ышана. Большевиклар аның сәләтенә, энергиясенә мохтаҗ булалар. Шуңа күрә аны тиз вакыт эчендә Мәскәүгә эшкә алалар. Ә инде Мулланур Вахитов үлгәч, ул Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариатының Мөселман Комиссариатын җитәкли. Мөселмән Хәрби коллегиясенең рәисе була. Гражданнар сугышы елларында 2 нче армиянең реввоенсоветы әгъзасы буларак, үзенең хәрби-оештыру эшләрендә сәләтле кешe икәнлеген күрсәтә. Аның кул астыннан чыккан һәм хәзерге көндә киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм документлар шуны раслый.

Әмма адәм баласы хата җибәрми тормый. М. Солтангалиев җибәргән хаталарның берсе — Идел-Урал штаты проектына, Казанда шушы проектны тормышка ашырырга тиешле II Бөтенмөселман хәрби съездына дөрес бәя бирә алмау була. Ул вакытта М. Солтангалиев Идел-Урал штаты проектына каршы чыга, аны Татар-Башкорт республикасы проектына алыштыруга юл куя.

Ләкин шунысын әйтергә кирәк, М. Солтангалиев мондый республиканы булдыру өчен көчен кызганмый. Ул шушы юлдагы һәммә киртәләрне алып ташларга әзер икәнлеген күрсәтә. Ләкин бу барыбер файдасыз була, чөнки билгеле даирәләр татар белән башкорт арасына чөй кага. Аннан соң татар белән татарны капма-каршы куя.

Ә инде Татарстан төзелү мәсьәләсе тугач, ул, Милләтләр Комиссариатының кече коллегиясе әгъзасы буларак, шушы республиканы булдыру өчен барысын да эшли. Алар Сәхибгәрәй Сәетгалиев белән, артык дус булмауларына да карамастан, бергә җигелеп эшлиләр. Шушы чорда икесе турында да төрле имеш-мимешләр таратыла.

Әгәр дә без СССР төзелгән чорда М. Солтангалиевнең Татарстанның һәм башка төрки республикаларның анда тигез хокуклы оештыручы булып керергә тиешлеген батырларча яклавын искә алмасак, бу дөрес булмас иде. Әйе, ул үзенең шушы позициясен яклап, Сталин белән каршылыкка керә. Ә тегесе усал хәтерле кеше була.

РКП(б)ның XII съезды вакытында М. Солтангалиев, милли республикаларның җитәкчеләре Нариманов, Мдивани, Махарадзе, Рыскулов, Рәхимбаев, Гамбәров, Коркмасов катнашында киңәшмә үткәреп, анда СССР составына турыдан-туры кермәгән республикаларның хокуклары турында җитди сүз алып бара.

Инде М. Солтангалиевнең башка төрки республикаларга мөнәсәбәте турында берничә сүз. Әлбәттә, ул аларның мөмкин кадәр бердәм булуын тели. Шуның өчен дә Татар-Башкорт республикасы проектын тормышка ашыру өчен көрәшә. Соңрак Башкортстан һәм Казагыстанны берләштерү проекты да барлыкка килә. Гомумән, М. Солтангалиев шушы республикаларның, Төркестан республикасы, яки үз эченә Үзбәкстан, Төркмәнстан, Таҗикстан җирләрен керткән территориянең бер Федерация тәшкил итүен тели. Моны берәүләр пантуранчылык дип атый. М. Солтангалиев исә туган халыкларның якын һәм дус яшәвен күздә тота. Моның белән ул әлеге халыкларны башкаларга каршы да куймый, алар өчен хокук өстенлеге дә дәгъваламый. Гомумән, М. Солтангалиев чын мәгънәсендә интернационалист кеше була.

Аның кыю эшләре, мөстәкыйльлеге, оригиналь фикер йөртүе Сталинга ошамый. Ул 1923 елның маенда аны кулга алырга боера. Аннан соң РКП(б) Үзәк Комитеты милли республикаларның җитәкче хезмәткәрләре белән киңәшмә үткәрә. Ул тарихка 4 нче киңәшмә дип кереп калды. Анда барлык Политбюро членнары катнашып, һәммәсе дә М. Солтангалиевне партиягә, ил-

гә хыянәт итүче дип фаш итмәкче була. Урыннардан килүчеләр дә, туып килә торган традицияләр рухында шушы хорга кушылып, М. Солтангалиевне дөньяда булмаган гөнаһларда гаеплиләр.

Нәтиҗәдә ул партиядән чыгарыла һәм эшеннән куыла. Бу елларда ул Охотсоюз системасында эшли. Илнең төрле районнарында була. Татарстанны беркайчан да онытмый. Аның анда һәрвакыт теләктәшләре, дуслары, туганнары яши. Ул яшьләр белән эшләүгә зур игътибар бирә.

Бу елларда аның үткән тарих, анда үзенең тоткан урыны турында уйларга вакыты була. Һәм ул, чыннан да, үткән тормышын җентекләп анализлый.

Шунысы игътибарга лаек, Мирсәет Солтангалиев бервакытта да сыйнфый принциптан чыгып эш итмәгән. Дөрес, ул, большевиклар кебек үк, дөнья революциясенә ышанган. Ләкин аның революциясе — пролетар революциясе түгел, ә колониаль системаны, Шәрекъ илләрендә Көнбатышның хаким итүен бетерүгә юнәлдерелгән революция. Аның идеалы — пролетариат диктатурасы түгел, ә революцион демократик хакимият.

Ә бит, чыннан да, большевиклар фараз кылган дөнья пролетар революциясе булмый калды, ә М. Солтангалиев күрсәткән антиколониаль революция җиңеп чыкты. Колониаль система чәлпәрәмә килде. М. Солтангалиевнең тагын бер алдан күрә белүенә тукталып үтү кирәктер. Ул Россиядә пролетар революциясенең җиңелү мөмкинлеген күрә, большевикларны моңа әзерләнергә чакыра. Ләкин мондый сүзләр ул вакытта саташу, ә еш кына дошман агитациясе һәм пропагандасы дип карала.

М. Солтангалиев нидән чыгып революциянең җиңелү мөмкинлеген әйткән соң? Моңа тулы җавап юк. Ләкин ул гадел нигезгә көйләнмәгән дәүләтнең иртәме соңмы җимерелергә тиешлегенә ышанган булса кирәк.

ә Совет дәүләтенең шундый гаделсезлеккә таба тайпылышсыз юл тотуын ул яхшы күргән.

Шул ук вакытта ул гаделлекнең колониаль система юкка чыгарылганнан соң гына урнаша алачагына нык ышана. Ышанып кына калмый, Россиядәге революцияләрне, андагы милли азатлык хәрәкәтенең үзенчәлекләрен тикшереп, кайбер сабакларны колониаль революцияләрнең җиңүенә гарантия дип саный.

Беренче сабак. Милли азатлык өчен көрәш дәверендә милләтләр үзара таркалу, сыйнфый көрәш юлына басарга тиеш түгелләр. Россиядәге, аерым алганда, татарлар арасындагы милли азатлык хәрәкәтенең уңышсыз тәмамлануына әнә шул үзара сугыш, сыйнфыйлык сәбәп була. Шуның аркасында дошман көчләр үзләренең «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» принцибын тормышка ашыра алдылар.

Икенче сабак. Милли азатлык өчен көрәш алып барган илләрдә тик бер генә милли партия булырга тиеш. Монда бернинди сыйнфый фиркаларга урын булырга тиеш түгел. Чөнки алар изелгән зәгыйфь милләтнең болай да аз көчен таркаталар, үзара алып барылган көрәшләр милләтне көчсезләндерә.

Өченче сабак. Азатлык өчен көрәшүче халыклар, бердәм хәрәкәт итеп, мөмкин кадәр ныграк укмашырга һәм нинди дә булса уртак координацион үзәк булдырырга тиешләр.

Кызганычка каршы, М. Солтангалиевнең үз эшчәнлеге дәверендә боларның берсен дә эшләп булмады. Шунлыктан Россиядә империя Совет төсенә кереп сакланып калды.

Шул ук вакытта Россия революциясе колониаль системаның җимерелә башлавына этәргеч булды, аны башлап җибәрде. М. Солтангалиев исә аның нәтиҗәләрен ясады. Шул нәтиҗәләрдән Азия-Африка илләренең милли азатлык лидерлары бик яхшы файдаландылар. Мирсәет Солтангалиев сабакларын үзләренең

идеологиясе итеп кабул иттеләр. Татар халкының мәшһүр улының колониаль илләрнең яки өченче дөньяның идеологы итеп танылуы юкка гына түгел. Алжир революциясе җитәкчесе Әхмәт Бен-Белланың кабинетында аның рәсеме эленеп торган.

Ерак Африка һәм Азия илләрендә М. Солтангалиев турында кайдан беләләр соң? Көнбатыш илләрендә Россия революциясен һәм андагы милли азатлык хәрәкәтен махсус өйрәнеп килгәннәр. Шулай булгач, М. Солтангалиевнең эшчәнлеген дә читләтеп үтә алмаганнар. Шундый тикшеренүчеләрнең берсе — Александр Беннигсен мөселман дөньясына, мөселман хәрәкәтенә аерым игътибар бирә. Үз хезмәтләрендә ул М. Солтангалиевнең чын мәгънәсендә бөек шәхес икәнлеген күрсәтә. Соңрак ул «Солтангалиев — өченче дөньяның идеологы» исемле китап бастырып чыгара.

Башка авторлар да М. Солтангалиев турында күп яза. Аннан соң, шул А. Беннигсен башлаган эшне дәвам итеп, Солтангалиевнең үз кулы астыннан чыккан материаллар, документлар, мәкаләләр дөнья күрә. Шушы материаллар Азия һәм Африка илләрендәге азатлык өчен көрәшне җитәкләгән лидерларга барып җитә. Бу эш бигрәк тә 50 елларда киң колач ала. Шунысы кызганыч, бу елларда М. Солтангалиев безнең илдә явыз халык дошманы, халыклар дуслыгы дошманы, әллә кайсы илләрнең шпионы итеп күрсәтелә иде.

Икенче мәртәбә Мирсәет Солтангалиев 1929 елның ноябрендә Глазов шәһәрендә чагында кулга алына. Ул милләтчеләрнең «Мәскәү үзәге»н төзүдә гаепләнә. Ул вакытта аның белән бергә ОГПУ тарафыннан 76 кеше җавапка тартыла. Шуларның 21-е үлем җәзасына хөкем ителә, шул исәптән Мирсәет Солтангалиев үзе дә. Ярты ел атылырга тиешлеләр камерасында ятканнан соң, үлем җәзасы 10 еллык сөрген белән алыштырыла. Ул аны Соловкида үткәрергә тиеш була. Ләкин аны

1934 елда аннан кайтаралар һәм Саратовта яшәргә рөхсәт итәләр.

Өченче мәртәбә Мирсәет Солтангалиев 1937 елның мартында кулга алына. СССР Югары судының хәрби коллегиясе аны атарга хөкем итә. 1940 елның 28 гыйнварында бу хөкем җиренә җиткерелә. Шулай итеп, татар халкының бөек улы дөньядан китә. Ләкин аңа чын шөһрәт һәм дан соңрак килә. Аның бөеклеген иң элек чит илләрдә таныйлар. Аның идеяләре башка җирләрдә тормышка аша. Безнең илдә ул тик 1990 елда гына реабилитацияләнде. Ләкин бу вакыт ул инде кемнең дә булса аклавына мохтаҗ түгел иде. Аның тарихи хаклыгын тормыш агышы, чынбарлык үзе раслады.

Кая соң аның палачы төзегән канлы империя? Ул инде үлем түшәгендә ята. Кая соң дошманнары фараз кылган дөнья революциясе? Алар барысы да миф булып чыкты. Хәзер шушы империя, аларның идеологиясе дөнья җәмәгатьчелеге суды алдында. Бу идеология, хурлыклы көннәрен кичереп, соңгы сәгатьләрен саный. Ә М. Солтангалиев идеяләре триумф кичерде. Алар чит илләрдә тормышка ашты. Бәлки, инде безнең үзебезгә дә шушы бөек татарга мәдхия җырлау белән генә чикләнмәскәдер? Үзебезгә дә аның идеяләрен яхшылап өйрәнеп, аларны халкыбыз файдасына эшкә җигәргә кирәктер? Тагын соңга калмабызмы?

БӘЙСЕЗЛЕККӘ НИЧЕК ИРЕШЕРГӘ?

АЗАТЛЫҠ БЕЗГӘ БАРЫБЕР КИЛӘЧӘК!

Бу китапны туплау дәверендә мин аның нигездә Россия һәм Татарстан мөнәсәбәтләрен яктыртуга багышланган икәнлеген аңладым. Чөнки Татарстанның тарихы Россия язмышына бик нык бәйләнгән. Аның азатлыгы һәм бәйсезлеге дә күп очракта ике яклы мөнәсәбәтләргә кайтып кала. Менә шуның өчен дә мин укучыларга гомеремнең бер якты мизгеле булган Россия һәм Татарстан арасында 1991—1992 елларда алып барылган сөйләшүләрдә катнашуым турында истәлекләр тәкъдим итәм.

Бу истәлекләр вакыйгаларның эзе тарих тузаны белән капланмас борын ук языла. Аларның дөреслеге шул сөйләшүләрдә катнашкан башка кешеләр тарафыннан раслана ала. Минемчә, сөйләшүләр вакытында нинди дә булса стенограмма яки беркетмә алып барылмады. Шулай булгач, әлеге тарихи вакыйгалар хакында язып калдыруны үземнең бурычым дип саныйм. Шунысын да әйтеп үтәсем килә: мин үземне шушы сөйләшүләрнең кайбер нәтиҗәләренә шактый өлеш керттем дип саныйм. Бу масаю түгел, бары тик тарих өчен кадерле булган дөреслек һәм гаделлек принцибыннан чыгып эш итү генә.

Әлеге сөйләшүләргә нигезне, һичшиксез, 1990 елның 30 августында Югары Совет тарафыннан кабул ителгән

Татарстанның суверенлык Декларациясе салды. Әлбәттә, декларацияне кабул итүнең үз тарихы бар. Бу очракта аңа артык туктап торуның кирәге юк. Тик, аны төзүдә һәм кабул итүдә катнашкан кеше буларак, шуны гына әйтеп үтәсем килә: әгәр дә шушы документка Татарстан — Россия Федерациясенең субъекты, дип язылган булса, безнең Россия белән сөйләшүләр алып баруыбызның бернинди хаҗәте калмаячак иде. Әлеге документка бәйсезлек нигезен салып калдыруыбыз бик зур тарихи әһәмияткә ия.

Нәкъ шушы документ Татарстанның махсус позициясен тудырды да инде. Инде бүген Татарстанда республиканың статусы буенча Референдум да үтте, бәйсез дәүләт Конституциясе дә кабул ителде. Ләкин Декларация тарихка онытылмас документ булып кереп калачак.

Мәгълүм булганча, М. С. Горбачев үзенең реформаларын СССРны һәм бердәнбер партия булган КПССны үзгәртеп кору максаты белән башлады. Шулай итеп, аның инициативасы белән яңа Союз килешүен төзү эше башланды.

Суверенлык декларациясен кабул иткән Татарстан шушы эшкә карата үзенең махсус позициясен билгеләде. Аның асылы булачак договорга Россия делегациясе составында түгел, ә мөстәкыйль рәвештә кул куюга кайтып кала иде. Бу исә, республикабызга союздаш республика статусы бирелеп, аны башка суверен республикалар белән бер рәткә куярга тиеш иде. Бу, һичшиксез, Россия Федерациясеннән чыгу булачак иде.

Менә ни өчен Россия җитәкчелеге, Татарстанның шушы махсус позициясе белән танышып, аны үз эчендәге башка автономияле республикалар белән бер дәрәҗәдә калдыру максатын куйды. Моның өчен ике яклы сөйләшүләр үткәрү кирәк иде. Шунлыктан ике президент, ягъни Б. Н. Ельцин һәм М. Ш. Шәймиев үз әмерләре белән делегация төзеделәр.

Әйтеп үткәнемчә, Россия җитәкчелеге бу сөйләшүләргә искиткеч зур әһәмият бирде. Шунлыктан делегация составына үзенең иң шөһрәтле кешеләрен кертте.

Исән кешеләргә нинди дә булса бәя бирү җиңел эш түгел, әлбәттә. Шулай да мин моңардан бөтенләй үк баш тарта алмыйм. Чөнки һәрбер эшкә теге яки бу тарихи шәхесләр үз тамгаларын салып калдырдылар. Тик шуны искәртеп китүне кирәк саныйм: биргән бәяләрем минем үз фикеремне генә чагылдыра. Аларны мин тулысы белән дөрестер дип тә санамыйм. Укучыларым моны шулай кабул да итсеннәр иде.

Россия делегациясенең җитәкчесе итеп Б. Н. Ельцинның иң якын кешеләреннән булган Г. Бурбулис билгеләнгән иде. Бу кешене без Россия сәясәтен билгеләүче зур шәхес итеп таныдык. Бу чыннан да шулай. Ул вакытта Г. Бурбулис РСФСРның дәүләт секретаре булып тора иде. Аның ни дәрәҗәдә йогынтылы кеше икәнлеген без Мәскәүдә чакта янына берничә мәртәбә Россия хөкүмәте башлыгы И. Силаевның кереп чыгуы да күрсәтә. Күпләр аны нәкъ йогынтылы булганы өчен сөймәде, урыныннан алырга тырышты. Р. Хасбулатов аңардан «фәнни коммунизм укытучысы» дип тә, ул җитәкләгән хөкүмәтне «кече фәнни хезмәткәрләр хөкүмәте» дип тә көлгәләде. Тик гаделлек шунда ки, бу кеше заман үзгәрешенә, аның кайсы юнәлеш белән китүенә бик сизгер. Шуның өчен аның белән сөйләшүләр алып бару бигүк җиңел булмаса да, һәрвакыт нинди дер нәтиҗәгә китерә иде.

Инде бер-ике сүз делегациянең башка әгъзалары турында. Икенче кеше булып монда С. Шахрай тора иде. Ул Мәскәү университетында лабораториядә эшләгән, юридик фәннәр кандидаты. Бу да акыллы кеше. Ләкин аңарда ниндидер катып калганлык сизелә. Ул заман сулышын Г. Бурбулис кебек үк ныклап тоя алмый. Шулай да, акыллы кеше буларак, интеллигентлык манераларын нык саклавы аркасында ул сөйләшүләрне

шактый оста алып барды. Аның белән дә сөйләшү ниндидер бер ләззәт бирә иде.

С. Станкевич — тарихчы, АКШ буенча белгеч. Хатыны татар. Бу кеше Г. Бурбулистай сыгылмалы түгел, аңарда еш кына ниндидер катып калганлык сизелә. Мәсәлән, ул Россиянең федерация булуыннан түгел, ә мең еллык тарихыннан чыгып эш итмәкче. Фикер йөртүе катгыйлык һәм катылык белән аерылып тора. Аның белән аңлашу авыр, ә кайвакыт гомумән мөмкин түгел.

Делегация составында РСФСР Министрлар Советының председателе урынбасары, бүгенге экономика министры О. Лобов та бар иде. Ләкин ул сөйләшүләрдә ике генә көн катнашты. Аннан соң, Россия җитәкчелегенә фетнә кузгалу (ГКЧП) ихтималы алдан ук билгеле булганлыктан, шуңа әзерлек күрү йөзеннән, ул ашыгычлык белән Свердловскига җибәрелде.

Россия делегациясенең тагын ике әгъзасына кыскача характеристика бирәсем килә. Аларның берсе Ф. Шелов-Коведяев. Бу «бердәм һәм бүленмәс Россия» тарафдары. Кирәгеннән артык тәкәббер. Өстәл артында утырганда да бертуктаусыз ни дә булса эчеп һәм тәмәке тартып утыра. Минемчә, ул үз-үзенә артык зур бәя бирә. Шулай да үзен бик тыйнак кеше итеп күрсәтергә ярата. Аның белән сөйләшүе авыр, әйткәнне аңлый торганнардан түгел. Аның үз туксаны гына туксан. Соңгы сөйләшүләрдә аның урынына Россия Югары Советында милли эшләр буенча комиссия җитәкчесе булып сайланган В. Подопригора катнашты. Монысы да, нәкъ Шелов-Коведяев кебек, зур амбицияле кеше. Үзен бик белдекле саный торган адәм.

Россия делегациясенең беренче составында юстиция министры Н. Федоров та бар иде. Бу намуслы һәм зур белемле чуваш. Заманында Казан университетының юридик факультетын бетергән. Баштарак ул үзен киң җәмәгатьчелеккә «бердәм һәм бүленмәс Россия» та-

рафдары итеп таныткан булса да, соңрак Татарстанның омтылышын гадел дип тапты.

Хәер, бу состав гел алышына килде. Г. Бурбулис үзе генә делегация җитәкчесе булып кала килде. Соңрак монда В. Тишков та кертелде. Ул профессор, Россия Фәннәр Академиясенең Миклухо-Маклай исемендәге Этнология институты директоры буларак, Россия хөкүмәтенең Милли Эшләр буенча Совет председателе итеп тә билгеләнгән иде. Күрәсең, монда аны «бердәм һәм бүленмәс Россия» тарафдары булып, үз принципларын фәнгә таянып яклар дип уйлаганнардыр. Тик бу ышанычны ул аклый алмады шикелле. Әлбәттә, ул интеллигент, күп белә. Тик аңарда да «бүленмәслек» принцибын яклардай аргументлар табылмады.

Инде Татарстан делегациясенә тукталыйк. Президент аның җитәкчесе итеп вице-президент В. Лихачевны билгеләде. Ул фәннәр докторы, халыкара хокук буенча белгеч. Ифрат оста сөйли. Дипломат буларак, кайвакыт бик күп сөйләп тә бер сүз дә әйтмәскә мөмкин. Сөйләшүләрне тиешле югарылыкта алып барды дисәм һич ялгышмам.

Делегация составына шулай ук вице-премьер, дәүләт милке комитеты рәисе Ф. Газизуллин да кертелде. Бу белемле һәм максатчан шәхес. Аның да сөйләшүләргә керткән өлеше гаять зур булды.

Президент киңәшчесе Р. Хәкимов та үзен бик компетентлы кеше итеп күрсәтте. Ул әллә ни күп сөйләми. Ләкин әйткән сүзе төпле һәм аргументларга нигезләнгән була иде. Документларыбызны компьютерга салып, аларны сипләп алып барды.

Делегациядә Татарстан Югары Советының даими комиссия рәисе Р. Хафизов, профессор Б. Железнов та бар иделәр. Эшебезгә алардан да зарар килмәде, киресенчә, кирәкле документлар төзегән вакытта файдалары нык сизелә иде. Халык депутаты Ф. Сафиуллин барыбызга да билгеле шәхес. Сөйләшүләр барышында

аның йогынтылы ролен билгеләп үтмәү һич тә дөрес булмас иде.

Без 1991 елның 12 августы көнне Россиянең Ак йортында сөйләшүләр өстәле артына утырдык. Бу дәһшәтле 1552 елдан соң безнең Россия белән тигез хокуклы килеш беренче мәртәбә өстәл артына утыруыбыз иде.

Иң элек котлау сүзе белән һәм Россия җитәкчелегенең Татарстанга ихтирамын белдереп Г. Бурбулис чыгыш ясады. Аннан соң җавап сүзе белән В. Лихачев чыкты. Ике чыгыш та эчтәлекле һәм эшлекле иделәр.

Аннан соң Татарстанның нәрсә дәгъвалаганын һәм нәрсәгә таянып эш иткәнлеген аңлату өчен мин сүз алдым. Мин татар халкының мең елдан ким булмаган дәүләтчелек тарихы булуын, аның тарихи хәтерендә моның яхшы сакланганын, халкыбызның һәрвакыт азатлык өчен көрәш алып барганлыгын әйттем, Татарстанның беркайчан да ирекле рәвештә Россия составына кермәгәнлегенә аеруча басым ясадым. Аннан соң большевиклар кабул иткән 1917—1918 еллар документларына тукталдым. Иң элек «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»ндә [1] Россиядәге халыкларның суверенлыгы һәм тигез хокуклы булуы танылган икәнлеген документның үзеннән цитата китереп исбат итәргә туры килде. Шушы документ кабул ителгәннән соң татар халкының мөстәкыйль рәвештә үз язмышын үзе хәл итәргә хаклы булуына аеруча басым ясадым. Моңа каршы чыгучы булмады. Мин III Бөтенроссия съезды кабул иткән шушы документның безнең позицияне ныгыта торган өлешләренә аңлатма бирдем. Бу декларация Россияне ирекле республикалар тарафыннан төзелгән ирекле халыклар союзы дип таный. Димәк, татар халкы да шушы хокукка ия. Мин документның соңгы пунктыннан цитата ки-

---

[1] Образование и развитие СССР как союзного государства. М. 1972, 9—10 б.

тереп, халыклар яки республикалар федерациядә катнашырга телиме, юкмы, теләсә ни рәвештә икәнлеге әйтелгән урынга тукталдым. Сүземне йомгаклап, Татарстан позициясенең төрле яктан нигезләнгәнлеген күрсәттем.

Әгәр дә әйткәннәрем берсүзсез һәм бәхәссез кабул ителде дисәм, бу дөреслеккә туры килмәс иде. Сораулар, каршы аргументлар шактый яңгырады. Шунысын да әйтергә кирәк, С. Шахрай, ниһаять, шушы онытылган 1917—1918 ел документларына игътибар итәлә башлавына канәгатьләнүен белдерде. Бернинди сәбәпсез калкып чыгып, Шелов-Коведяев миңа берничә мәртәбә һөҗүм итәргә тырышкалап караган иде. Ләкин аның бу өлкәдә бик сай йөзгәнлеге күренде.

Минем чыгыштан соң бәхәсләр башланды. Әйтергә кирәк, бу бәхәсләр бер-береңне аңларга тырышу һәм ихтирамлы мөнәсәбәткә нигезләнгән иде. Соңрак шушы сөйләшүләрне һәр ике як та бер фәнни семинар кебегрәк кабул итте. Бу чын мәгънәсендә шулай булды да.

Г. Бурбулис сөйләшүләрнең икенче көнендә Татарстанның позициясен хаклы позиция дип таныды («правомерность позиции Татарстана»). Шулай булуга да карамастан, Г. Бурбулис һәм С. Шахрай Татарстан Россиянең бердәмлеген бозарга тиеш түгел, ул союз договорына бары тик Россия делегациясе составында гына кул куярга тиеш дип исбат итмәкче булдылар. Без исә китерелгән аргументларга таянып, аларны киңәйтү йөзеннән гаделлеген тану һәм Татарстанга мөстәкыйль рәвештә союз договорына катнашырга юл ачуын күрсәттек. Без Россиянең ана-үзәк буларак башкарган функцияләренә таяндык. Аның үз составыннан бер-бер артлы союздаш республикаларны тудырып торганлыгын күрсәттек. Инде Татарстан да шундый республика булып өлгерде. Инде Россиянең аңа да союздаш республика статусына юл ачарга бурычлы икәнен әйттек.

Моңа каршы бездән берничә мәртәбә: «Алай булгач, әйтегез, Татарстан Россиядән чыгамы, юкмы?»— дип сорадылар. Бу, әлбәттә, җиңел сорау түгел иде. Чөнки без Татарстанның суверенлык декларациясенә таянып, бу мөстәкыйльлек — халык теләге дисәк, безгә җавап итеп: «Алай булгач, сез нигә шушы хакта референдум үткәрмисез?»— дип әйтә торганнар иде.

Миңа бу очракта шундый ысул кулланырга туры килде. Татарстан, дидем мин, 1552 елны яулап алынган. Ул беркайчан да ирекле рәвештә Россиягә кергәнлеген танымады. Безнең күршеләребез үзләренең ирекле рәвештә кергәнлекләрен, моның алай булмавына да карамастан, таныдылар. Шул датаның 400 еллыгын бәйрәм итеп орденнар да алдылар. Татарстанда бу хәл булмады. 438 ел дәверендә бер генә татар да Россиягә ирекле керү документына кул куймады. Шунлыктан безнең декларациябездә дә «Татарстан — Россиянең өлеше» дип язылмаган. Бүгенге көнне бер генә татар да андый документка кул куймаячак.

Бу сүзләр безнең Россия коллегаларын уйландырырга мәҗбүр итте. Ниһаять, С. Шахрай өстәл артыннан торды, безнең исемнән сөйләгәндәй итеп, йөри-йөри болай диде: «Значит, мы из России не выходим, но в нее и не входим».

Мин аңа: «Сергей Михайлович, вы очень тонко поняли нашу позицию»,— дип әйттем. Ул урынына утырды. Һәм инде бу сорау әлеге очрашуда кабат яңгырамады. Сөйләшүләр вакытында уртак икътисади киңлектә эш итү, мәдәни мәсьәләләрне бергәләп хәл итү кирәк дип табылды. Шулай ук ике яклы мөнәсәбәтләрнең тик договор нигезендә генә алып барылырга тиешлеге бәян ителде. Моның шулай булырга тиешлеген, ягъни безнең арада ике яклы килешү булырга тиешлеген бигрәк тә С. Шахрай таныды.

Сөйләшүләр никадәр уңайлы булмасын, без Татарстанның ни рәвештә союз килешүенә кул куярга тиеш-

леге хакында уртак фикергә килә алмадык. Гомумән, менә шундыйрак каршылык калкып чыкты. Каршы як Татарстанның дәгъвасын нигездә кабул итеп булыр иде, диде. Ләкин моның башка республикалар өчен прецедент (үрнәк) булуы мөмкин. Без исә моңа җавап йөзеннән, башка республикалар кабул иткән декларацияләрендә үзләренең Россия составында икәнлекләрен таныдылар, шулай булгач, Татарстан алар өчен үрнәк түгел, дип тә карадык. Тик Россия делегациясен үзебезнең фикергә күндерә алмадык.

Тирән эчтәлекле кыска гына беркетмә кабул итеп, сөйләшүләрнең шушы өлешен тәмамладык. Бу 15 август иде. 16 август көнне без Казанга әйләнеп кайттык.

Сөйләшүләрнең нәтиҗәсе президентыбыз тарафыннан хупланды. Без әлеге очрашуның үзебез өметләнгәннән артыграк та нәтиҗә биргәнлеген нык сиздек. Россия җитәкчелеге исә безнең делегациянең сөйләшүләргә аларның үзләренә караганда яхшырак әзерләнгән булуын таныды.

Мәгълүм ки, 19—21 август вакыйгалары (ГКЧП) Союз килешүен булдырмый калды. Күп тә үтмәде Союз таркалды. Безнең Союз килешүенә ни рәвештә кул куярга тиешлегебез актуальлеген югалтты. Ләкин Россия белән Татарстан мөнәсәбәтләрен ачыклау мәсьәләсе хәл ителмичә калды. Шунлыктан сөйләшүләрне дәвам иттерү ихтыяҗы кала бирә.

Тик менә Татарстанның статусы буенча сөйләшүләр тиз генә дәвам иттерелмәде. Күрәсең, Россия җитәкчеләре үзләренең позициясен ныгыту өчен аргументлар туплагандыр. Ә менә көндәлек мөнәсәбәтләр буенча, бигрәк тә икътисади өлкәдә, сөйләшүләрне хөкүмәт делегацияләре дәрәҗәсендә дәвам итәргә кирәклеге зарури дип табылды. Бу сөйләшүләр декабрьдә булып үтте. Россия делегациясенең җитәкчесе итеп премьер-министр вазифаларын башкаручы Е. Гайдар билгеләнде, Татарстан делегациясен Татарстан премьер-министры

М. Сабиров җитәкләде. Ике делегациянең дә составында беренче сөйләшүдә катнашкан кешеләр юк иде дисәм, хата җибәрермен. Безнең делегациягә Ф. Газизуллин һәм мин кертелгән идек. Россия ягында элеккеләрдән берәү дә юк иде. Премьер-министр җитәкчелегендәге бер төркем кеше алданрак китте. Икенче көнне, минем Мәскәүгә кичекмәстән килеп җитүемне сорап, М. Сабировтан хәбәр килеп төште. Шул ук көнне поездга утырып Мәскәүгә киттем. Анда мине каршы алып, тиз генә Старая площадька, хөкүмәт бинасына алып килделәр. Ләкин инде сәгать 11 дә ике делегациянең пленар утырышы тәмам булган. Мин Е. Гайдар белән М. Сабировның коридорда сөйләшеп торуларын күреп килеп исәнләшкәндә инде эш беткән, делегацияләрне төрле төркемнәргә бүләләр иде. Шулай итеп, икътисади төркем, милек, нефть, финанс, банк, юллар төркемнәре төзелде. Алар иртәгәдән эшкә керешергә булдылар.

Кичен миңа пленар утырышның беркетмәсен күрсәттеләр. Ул тик Е. Гайдар һәм М. Сабиров чыгышларыннан гына тора иде. Миңа ике чыгышның да эчтәлеге ошамады. Е. Гайдарның чыгышында Россия милек һәм башка хокуклар хуҗасы, ә Татарстан сораучы, теләнүче дәрәҗәсенә куелган иде. Аның позициясе «бердәм һәм бүленмәс Россия» принцибына нигезләнгән һәм ул катгый иде. Без, ди ул, Татарстан өчен генә ниндидер ташламалар ясарга җыенмыйбыз. Һәммә республика һәм регион бер хокукта булырга тиеш. Е. Гайдарның позициясе аңлашыла, чөнки ул Россия җитәкчелегенең позициясе. Ә менә М. Сабировның позициясе миндә зур ризасызлык тудырды. Ул чыгышының бер урынында «мы однозначно в России» дип ычкындырган. «Сез нигә мондый белдерү ясадыгыз», дип сорадым. Ул миңа: «Азрак төгәлсезлек киткән», дип аңлатты. Шуннан соң М. Сабировтан делегациябезне тулы составында җыюын сорадым. Үземнең беренче көнге сөйләшү нәтиҗәлә-

рен анализларга теләвемне белдердем. Ул моңа ризалык бирде. Икенче көнне сәгать унда башланган делегациябез киңәшмәсендә чыгыш ясадым. Алдан сөйләшкәнчә, М. Сабировның позициясен ачыклауны кирәк санадым.

Чыгышымда делегацияләрнең кичәге утырышында ике позиция бер-берсе белән бәрелешкән, дидем. Аның берсе Е. Гайдар позициясе. Ул Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы, икенчесе М. Сабиров позициясе, ул исә Татарстанның мөстәкыйльлеген яклый, дидем. Әгәр дә М. Сабиров «мы однозначно в России», дип әйткән икән, ул мәдәни, рухи һәм икътисади бердәмлек турында сүз алып бара дип, Сабировның позициясенә уңайрак төс бирдем. Өстәвенә делегация әгъзаларының кабул ителгән декларациябез һәм августта булып үткән сөйләшүләр беркетмәсенә таянып эш итүләрен сорадым. «Без, дидем мин, монда сорарга һәм теләнергә килмәдек. Без үз хокукларыбыз белән килдек. Без аларны тануга корылган икътисади килешүне төзәргә тиешбез», дидем.

Мин сөйләгәннән соң М. Сабиров, ике делегациянең пленар утырышы стенограммасын ишәйтеп, барлык делегациябез әгъзаларына бирергә әмер бирде. Ләкин позициябезне ачыклау әнә шул пленар утырышта эшләнгән булырга тиеш иде. Инде Россия делегациясе әгъзалары үз җитәкчелегеннән тиешле күрсәтмәләр алган һәм шул юнәлештә эш итә дә башлаган иде. Кыскасы, без сорыйбыз, теләнәбез, алар йә бирәләр, йә бирмиләр. Бирсәләр, күпме бирәләр,— монысы аларның мәрхәмәтлелегенә бәйләнгән.

Безнең эш мөшкел иде. Ике-өч көн буе төрле төркемнәрдә эшләгән делегация әгъзалары әйләнеп кайткан саен бернинди нәтиҗә юк икәнлеген бәян итә тордылар.

Беркөнне минем яныма дәүләт милеге комитеты рәисе урынбасары Д. Бикбов килде һәм милек төркеменә

ярдәм итүемне сорады. Мин, әлбәттә, бардым. Тик өченче дәрәҗәдәге Россия чиновнигының безнең белән сөйләшерлек бернинди хокукы юк икәнлеген күрдем. Ул инструкция алган һәм шуның нигезендә эш итә. Ул безгә федераль органнар һәм регионнарның үзара милек белән идарә итү буенча вәкаләтләре булу турындагы документның ничәнчедер экземплярын күрсәтте. Янәсе, менә шуны карагыз да ризалык бирегез. Мин аңа: «Сез безгә нинди ксерокопия күрсәтәсез, без мондый документ түгел, ә тигез хокуклылык нигезендә төзелгән документ булдыруны телибез»,— дидем. Ул исә үзенә андый вәкаләтләр бирелмәгәнлеген әйтте. Шунлыктан бу көн нәтиҗәсез үтте.

Икенче көнне сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителергә тиешле документның проектын төзү эше башланды. Россия ягыннан бу эшне экономика министры урынбасары алып бара иде. Миндә кичәге ачу әле бетмәгәнлектән, аңа:

— Сезнең белән җитди сөйләшүләр алып барып буламы?— дидем.

Ул миңа:

— Сез безне кимсетәсез, без җитди кешеләр һәм безнең белән җитди сөйләшүләр алып барып була,— диде.

— Яхшы,— дидем мин.— Алай булгач, сез инде сөйләшүләрдә варислык (преемственность) принцибын таныйсыздыр.

— Әлбәттә,— дип җавап бирде ул.

— Менә сезнең алдыгызда августта булып үткән сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителгән беркетмә ята. Аңа ничек карыйсыз?

— Мин аны яхшы документ дип саныйм.

— Алай булгач, әйдәгез әле, аның эчтәлеген карап карыйк.

— Яхшы!

— Анда ике як та үзләре кабул иткән дәүләт суверенлыгы декларацияләреннән чыгып эш итәләр, диелгән.

— Әйе, бу шулай булырга тиеш тә.

— Алай булгач, Татарстан декларациясендә җир һәм андагы милек Татарстан һәм аның гражданнарыныкы, дип язылган. Шуны танныйсызмы?

Бу кадәргә киткәч, бу кешегә инде «таныйм» дип әйтергә туры килде. Мин исә аңа: «Кабул итә торган документта ике якның да үз милке бар дигән принцип билгеләнергә тиеш. Сезнеке ул — сезнеке, ә Татарстандагы барлык милек — «безнеке». Әйдәгез, шулай дип язып та куйыйк»,— дидем.

Ул риза булды. Шушы принцип документка теркәлде. Мин сүземне дәвам иттем. Тыңлаучылар арасында безнең дәүләт экономика комитеты председателе, вице-премьер Ф. Хамидуллин, финанс министры Д. Нагуманов, инде телгә алынган Д. Бикбов. Сүз уңаеннан соңгысы хакында бер-ике сүз әйтәсем килә. Беренчедән, ул искиткеч тыйнак. Икенчедән, зур компетенцияле белгеч. Икътисадны, милек мәсьәләсен энәсеннән җебенә кадәр белә. Ул, сөйләшүләрдә актив катнашып, йомгак документ хәзерләүгә өлешен кертте.

— Милекнең безнеке икәнлекне тануның никадәр әһәмиятле булуына да карамастан, бу әле эшнең бер ягы гына,— дидем мин.— Сөйләшүләрдә без шундый логикага таянабыз: әгәр дә кемнең дә булса милке бар икән, ул аннан үз файдасына налог җыя. Кешегә салым җыярга булгач, ул милекнең нигә кирәге бар? Шунлыктан без,— дип дәвам иттем мин,— бер каналлы мөстәкыйль республика налогын булдыруны алга сөрәбез. Налог исә ул акча чыганагы. Димәк, безнең мөстәкыйль финанс системабыз, ягъни үзебезнең бюджетыбыз булырга тиеш. Ә инде акчаң булгач, аны салырга кесә кирәк. Без Татарстанның милли банкын булдыруны да күздә тотабыз.

Дөресен әйтергә кирәк, ул хакыйкатьне таный торган акыллы кеше булып чыкты. Логикага таянган, аргументланган фикерләрне тулысы белән аңлап эш итә. Кем ничектер, мин аңа рәхмәтле. Мин әйткәннәрне тулысы белән кабул итте. Әгәр дә шушы принцип Гайдарлар аша үтсә, без максатыбызга ирешә алачак идек. Бу көн шуның белән тәмамланды.

Кичке аш вакытында финанс министры Д. Нагуманов: «Индус Ризакович, сез бит тарихчы, ничек итеп шушы җиңүне булдыра алдыгыз»,— дип хуплавын белдерде. Икенче көнне кичен кайткач ул: «Россия мөстәкыйль бюджет һәм банкка ризалаша»,— дип хәбәр итте. Банк управляющие М. Галимов та безгә банк бирәләр, дип кайтып әйтте.

Нефть мәсьәләсе буенча сөйләшүләр аеруча авыр бара иде. Инде безнең вәкилебез М. Гиниятуллин кайтып нефтьнең дә безнеке икәнлеген таныйлар, диде. Ә тагын бер көннән Татарстан нефтенең яртысы Татарстан карамагына күчүе турында документ проекты төзелде. Мин бу документның тулы эчтәлегенә тукталып тормыйм. Аның тик әнә шул, финанс, налог, банк мәсьәләләре кебек үк, милек мәсьәләсенә принципиальлек кертелгәннән соң гына кузгалып китеп, безгә уңай нәтиҗә биргәнлеген әйтеп үтәсем килә.

Сөйләшүләр нәтиҗәсендә төзелгән беркетмәнең проекты Р. Хасбулатовка җиткәч, ул зур ризасызлык белдереп, банк һәм бюджет мәсьәләсе тик Россия Югары Советы вәкаләте генә булып тора, дип безнең документны бераз үзгәртте. Гомумән, бу ике мәсьәлә буенча ике якның да Югары Советлары делегацияләре үзара сөйләшүләр алып барырга тиеш булып чыкты. Андый сөйләшүләр дә булып, анда да кайбер уңышларга ирешелде. Каршы якның безнең аргументларга каршы куярлык дәлилләре булмаганлыгы ачыкланды.

Икътисади мәсьәләләр буенча сөйләшүләр Татарстанның статусын билгеләү мәсьәләсен алып төшереп

калдырмады. Билгеле булганча, республикада бу хакта Референдум үткәрелеп, анда катнашканнарның 61 проценты бәйсезлекне яклап «әйе» дип җавап бирде. Бу 1992 елның 21 марты иде.

31 мартта Россиянең федератив килешүенә кул кую булырга тиеш иде. Татарстан үзенең кабул ителгән дәүләт суверенитеты декларациясе һәм аның бөтен халык референдумы нигезендә расланган махсус позициясенә таянып аңа кул куймаячагын белдерде. Бу, әлбәттә, Россия җитәкчелеген бик нык борчыды. Чөнки, Татарстанга ияреп, Саха һәм Башкортстан да килешүгә кул куймау ихтималын белдерделәр. Россия җитәкчелеге аларны Татарстаннан аерып алуны үзенә максат итеп куйды. Күрәсең, шул максатка ирешү йөзеннәндер, алар Татарстан белән сөйләшүне дәвам иттерү көнен нәкъ менә шушы 31 мартка билгеләделәр. Минемчә, аларга моның исеме генә кирәк иде. Җисеме түгел. Алар шушы килешүгә кул куярга тиешле республикаларга Татарстанның ультиматив позициядә булмавын, хәтта ничек тә булса, кайчан да булса аңа кушылачагын исбат итү өчен һәм, Татарстанга ияреп, башкалар да бу документка кул куюдан баш тартмасыннар, дип курыкканга сөйләшүне шушы көнгә билгеләделәр.

Бу көнне Старая площадьтагы йорт яны бигрәк тә җанлы иде. Бер-бер артлы яль-яшь министрлар утырган лимузиннар килеп туктый. Республикалар вәкилләрен утырткан машиналар да күренгәли. Без дә килдек.

Менә сәгать 10. Г. Бурбулис әле үз кабинетында утыра. Ишек төбендә Башкортстан җитәкчеләре. Мин аларны танымыйм. Безнең вице-президент В. Лихачев миңа аларның кайсы кем икәнлеген аңлата.

Ниһаять, без өстәл артында. Г. Бурбулис безнең белән исәнләшә. Уч төбе салкын тирдә. Бу нервларының тыныч түгел икәнлеген күрсәтә. Шулай булырлык та. Инде мәгълүм булганча, ул моңа кадәр Башкортстан делегациясе белән авыр сөйләшү үткәргән, ике хөкүмәт

арасында килешү төзелеп, ул федератив килешүгә өстәмә документ итеп танылган. Ә бит бу барып чыкмаска да мөмкин иде.

Г. Бурбулис сүзен болайрак башлады:

— Татарстан башка республикалар өчен әхлакый ориентир билгеле. Аны мисал, өлге итеп карыйлар. Бүген федератив килешүгә кул кую булачак. Без, әлбәттә, сезнең дә аңа кул куюыгызны теләр идек. Ләкин беләбез, сез моңа бара алмыйсыз. Шуның өчен сезнең безне яклап, хуплап чыгуыгызны телибез.

Аннан эшлекле сөйләшүләр башланды. Статус мәсьәләсендә. Г. Бурбулис артыннан В. Лихачев сөйләп, конкрет сүзгә күчтек. Шуннан соң мин сүзне дәвам итеп болай дидем:

— Геннадий Эдуардович, сез үткән сөйләшүләр вакытында, суверенлык декларациясе урынына референдум үткәреп, шуның нәтиҗәләрен алып килгән булсагыз, яхшырак булыр иде, дигән идегез. Без менә шулай эшләдек тә. Референдум үтте, менә аның нәтиҗәләре.

Бу сүзләргә ул көенмәде дә, сөенмәде дә. «Инде бит, сезгә мәгълүм булганча, конституция суды булып, ул Татарстан референдумы хакында үз карарын чыгарды. Безнең кулыбыз шуңа бәйле»,— диде.

Тарткалашулар шактый дәвам итте. Төштән соң Г. Бурбулис килмәде. Аның вазифаларын В. Тишков алып барды. Икенче көнне «Независимая газета» Россия һәм Башкортстан хөкүмәте арасында килешүгә кул куелуын, Башкортстанга экономик мөстәкыйльлек, тышкы сәүдә эшләрен алып бару хокукы бирелгәнлеген хәбәр итте. Өстәвенә тагын хокукый органнарның да Башкортстанның үз юрисдикциясенә күчерелүе каралган. В. Тишков бу турыда хәбәрдар булып чыкмады. Россия делегациясенең башка әгъзалары да берни белми иде. Газетада язылганның серенә төшкәнчә, тәнәфес җитте. Аннан без шушы хәбәрнең дөрес икәнлеген, хәтта әлеге документның копиясен дә үзебездә булдырдык.

Россия делегациясенең алдына китереп салдык. Моңарчы «не может быть» дип утырганнар, ышанмый булдыра алмадылар. В. Тишков, гомумән, тапкыр кеше, ул:

— Сез дә федератив договорга кул куегыз, сезгә дә шуны бирербез. Сез дә бит нигездә шушындый хокуклар турында сүз алып барасыз,— диде.

— Юк, без ул хокукларны сездән сорап алырга теләмибез. Бездә алар болай да бар. Референдумыбыз нәтиҗәсендә без суверен дәүләт. Без тик шуны сезнең тануыгызны гына дәгъвалыйбыз.

Шунда утырган С. Станкевич:

— Сез Россиядән чыгарга ниятлисезмени? Сезнең моңа хакыгыз юк!— диде.

Без аңа: «Сез 1918 елда Россияне федерация дип игълан иткән документларны танийсызмы?» — дидек. (Сөйләшүнең «тәмен» саклау өчен калганын русча гына китерәм.)

Ул: «Это большевистские штучки. Давайте, будем исходить из тысячелетней истории российской государственности».

Без: «Вы имеете в виду Киевскую Русь? Так, давайте в таком случае поедем в Киев и продолжим наши переговоры там!»

Бу аңа ошамады, ул һаман үзенекен сөйләде. Әлеге сөйләшүләрдә безнең делегациягә Татарстанның халык депутаты А. Колесник та кертелгән иде. Ул бик актив кеше. Сөйләшүләр вакытында кискенләштерүдән дә курыкмый. Бервакыт мин башлап җибәргән бәхәскә ул да килеп кушылып, болар икесе дә шул кадәр кызып киттеләр ки, С. Станкевич хәтта: «Менә кем сезнең республикадагы обстановканы кискенләштерүче»,—дип куйды.

Бу очрашу безнең өчен нәтиҗәсез узды. Кечкенә генә бер протокол кабул ителде. Анда да безне алдый яздылар. Безгә тәкъдим ителгән документта Татарстанның халыкара эшләргә катнашу хокукы һәм суверен дәүләт икәнлеге күрсәтелгән, тик менә «в составе Рос-

сийской федерации» дип язылган иде. Мин алдымдагы блокнотыма «в» или «с» дип язып В. Лихачевка төрттем. Ул аны алды да: «сув. гос-во, субъект мжн. отн» дип язып куйды. Күрәсең, шулай булгач «в составе России» булса да ярыйдыр. Шулай да мин В. Тишковка әлеге «в» ны, «с» хәрефенә алыштыруын сорадым.

Ул: «Алай булгач, «суверенное государство, субъект международных отношений» дигән сүзләрне алып атабыз»,— диде.

Мин: «Алып атыгыз, тик шушы хәрефләрне генә алыштырыгыз»,— дидем.

Алыштырдылар. Эш беткәч В. Лихачев миңа: «Из-за вас Индус Ризакович, потеряли суверенное государство и субъект международных отношений»,— диде. Шул вакыт минем янга Ф. Газизуллин килеп җитте: «Индус Ризакович, зур рәхмәт сезгә, бик дөрес эшләдегез»,— дип кулымны кысты.

Бу эпизодка комментарий бирәсем килми. Сөйләшүләр вакытында төрле хәлләр була. Анда һәркемнән уяулык таләп ителә. Шуның өчен дә делегация бит инде ул — сөйләшеп эшләү өчен.

Без бер генә карарны да тикшермичә кабул итмәдек. В. Лихачев та бернинди ялгыш җибәрмәде. Күп вакыт аның халыкара хокук өлкәсендәге зур мәгълүматлылыгы, логик фикер йөртә белүе безгә нык ярдәм итә иде.

Шуны әйтеп үтәсем килә: Россия җитәкчелеге үз делегациясе составына һәрвакыт үзгәрешләр кертеп торды. Шунлыктан безгә очрашкан саен күп нәрсәне өр-яңадан аңлата башларга туры килә иде.

Шул елның маенда яңартылган составтагы Россия делегациясе Казанга килеп төште. Аңа бүгенге беренче вице-премьер, ул вакытта Р. Хасбулатовның урынбасары булып эшләгән Ю. Яров җитәкчелек итә иде. Бу кешенең позициясе каты һәм катгый. Ул куркыту-янауларны еш куллана. Принцибын ул миңа «лом на лом»

дип аңлатты. Бу кешегә бигрәк тә А. Колесник кулай булмады. Алар гел чәкәләшеп, бәйләнешеп тордылар. Бу юлы делегация составында Россия Югары Советының экспертлар төркеме җитәкчесе, юридик фәннәр докторы Л. Болтенкова да бар иде. Аның турында бер-ике сүз әйтәсем килә. Бу кеше чын мәгънәсендә югары квалификацияле белгеч. Сөйләшү өчен уңай. Кеше башыннан ахырына кадәр тыңлап, аның белән чын мәгънәсендәге эшлекле сүз алып бара. Өстәвенә сабыр холыклы һәм итагатьле дә ханым булып чыкты. Бу сөйләшүләрдә без инде конкрет рәвештә ике яклы килешүнең эчтәлеген эшли башладык. Максатыбыз бер булса да, без ике төрле позициядә идек. Ю. Яров шушы килешүне Татарстанның федератив килешүгә бара торган юлы, дип аңлый. Без исә моны мөстәкыйль документ һәм бернинди башка документ белән нинди дә булса бәйләнештә тормый дип карыйбыз. Алар безнең килешүнең текстын федератив килешүгә якынлаштырырга тырыштылар. Без исә Татарстанның суверенлыгын тәэмин итә торган маддәләрнең аның үз вәкаләтендә булуын алга сөрәбез.

Мәскәүлеләр июльдә тагын килделәр. Тагын шул эш дәвам итте. Бу юлы без делегациябезгә хәрби эксперт та керткән идек. Бу эш тә азмы-күпме алга китте.

1 август көнне без Мәскәүгә киттек. Вокзалда безне чәчәкләр белән каршы алдылар. В. Тишков безгә «сез Россия хөкүмәтенең кунаклары», диде. Милиция озатуында дүрт кара «Волга»га утырып киттек. Безне Кунцевога, Сталинның Ближняя дачасына урнаштырдылар. Шул көнне делегацияләр төркемнәргә бүленеп эшли башлады. Россия делегациясе составында ике генерал да бар иде. Аларның берсе эчке эшләр министры урынбасары, икенчесе оборона министры урынбасары, хәрби фәннәр докторы.

Безнең яктан В. Лихачев һәм мин, каршы яктан В. Тишков һәм Россия Югары Советының милләтләр

палатасы рәисе урынбасары В. Сыроватко төп мәсьәләне — статус мәсьәләсен хәл итү өстендә эшләргә тиеш булдык. Инде кайбер фикерләрне туплаганнан соң, 3 август көнне сәгать дүрттә без Кремльгә Г. Бурбулис кабинетына киттек. Ул М. Горбачевның элеккеге кабинетында утыра. Ишектән чыгып каршы алды. Эшнең ни рәвештә башланып киткәнен В. Тишков сөйләде. Аннары В. Лихачев сөйләде. Шуннан соң Г. Бурбулис миннән: «А вы, Индус Ризакович, как оцениваете обстановку?» — дип сорады.

Мин дә, В. Лихачев кебек үк, эшләү өчен тудырылган уңай шартлар өчен рәхмәт әйттем. Һәм болай дип дәвам иттем: «Геннадий Эдуардович, вы первый из российских руководителей, понявший нашу ситуацию и признавший позицию Татарстана правомерной. Мы вам за это очень благодарны».

Үзем сөйлим, ә үзем күзәтәм, ничегрәк кабул итәр икән ул бу сүзләрне. Чөнки бер ел элек, беренче мәртәбә очрашкан вакытта, ул безнең позициянең «правомерный» икәнлеген танығач, мин аның сүзләрен протоколга кертергә маташкан идем. Ләкин аның ул вакытта җен ачулары чыкты. Гадәттә, үзен кулда тота белә торган зур ихтыяр көченә ия кеше ул чакта шартлаган иде. Бу юлы ул, берни дә булмаган кебек, мине тыныч кына тыңлый бирде.

Мин дәвам иттем (сүзләрне әйтелгәнчә русча китерәм):

— Мы особенно благодарны вам, Геннадий Эдуардович, за то, что вы признаете решения III Всероссийского съезда Советов, где Россия провозглашается добровольной федерацией свободных народов в лице их республик. Для нас особенно важен последний пункт этого документа, где говорится, что III Всероссийский съезд устанавливает лишь коренные начала федерации, а вопрос о том, хотят ли участвовать в федеральном правительстве, и если да, то в каком качестве, респуб-

лики должны решить самостоятельно на своих собственных съездах...

Шушы җиргә җитүгә мине В. Тишков бүлдерде:

— Вот видите, Индус Ризакович, какую-то вертикаль вы все равно признаете... Скажите, вы выходите из России или нет?

— Валерий Александрович, вертикаль есть и она неизбежна в процессе превращения народного суверенитета в государственный. В этом случае, поскольку источником прав является народ, права движутся снизу вверх. Но как только народный суверенитет превращается в государственный, движение прекращается. Оно свойственно как суверенитету России, так и Татарстана. После этого все суверенитеты равны. Не бывает старших и младших суверенитетов. Это юридическая аксиома.

Г. Бурбулис ачуланып В. Тишковка карады. Ә мин исә В. Тишковка: «Вам важна форма или содержание. Как будем работать: по форме или по содержанию?» — дидем. Г. Бурбулис В. Тишковка борылып: «Давайте больше таких вопросов задавать не будем, а будем работать по содержанию»,— диде.

Шуннан соң ул мондый сүзләрне әйтте:

— За прошедший год мы очень сильно изменились. Мы сейчас допускаем, что Российская федерация может быть асимметричной с элементами конфедерации...

Аның сүзе шактый озын булды. Мин ул сөйләгәннең үзем иң әһәмиятле дип санаган урыннарын гына искә төшереп киттем.

Кремльдән чыктык. Безнең сөйләшү 1 сәгать тә 15 минут дәвам иткән. В. Лихачев миңа: «Бу көнне без истә калдырырга тиешбез. Бу тарихи көн»,— диде. В. Тишковлар белән бергә Ближняя дачага әйләнеп кайттык. Кичке ашны бергә ашадык. Ике делегация алдында ул: «Индус Ризакович как кремень»,— диде.

Бу һичшиксез мактау сүзе иде. Күрәсең, мин аңа чакма ташы кебек нык булып тоелганмындыр.

Бәлки, шуның өчендер дә ул мине берничә мәртәбә делегация составыннан чыгарып ташламакчы булды. Без Мәскәүгә киткәнче үк, бер газетага сөйләшүләрнең барышы турында интервью биреп, анда: «Вот только непонятно, почему в делегации Татарстана принимают участие представители национальных организаций», дигән. Мин кем бакчасына таш ыргытылганын аңладым. Үземә сүз бирелгәч, шуны искә төшереп, кайберәүләр, интервьюлар биреп, мине Татарстан делегациясеннән чыгарып атарга тырыштылар. Ләкин булырлык эш түгел. Беркем дә, берничек тә моны эшли алмас, дидем.

Инде В. Тишковның тапкырлыгы турында әйтелгән иде. Бу юлы да ул аптырап калмады:

— А может быть, Индус Ризакович, это была подсказка вашему руководству, чтобы оно привлекло вас для работы в государственных учреждениях?

— Вы бы в таком случае сказали об этом самому нашему президенту,— дидем дә сүзне бетердем.

Мәгълүм ки, бу кешене Госкомнац председателе вазифаларыннан азат иттеләр. Бәлки, ул үзе теләп киткәндер. Сәбәпләре аңлашыла. Мондый вазифаны таркалып барган империя шартларында башкару, әлбәттә, җиңел түгел. Безнең арада төрле бәхәсләр, бәрелешләр булса да, бу кеше турында минем җылы истәлекләр саклап каласым килә. Ул кешелекле, аңлы, зур ихтирамга лаек шәхес. Миңа карата әйтелгәннәре дә, безнең белән бүленмәс Россияне яклаган бәхәсләре дә, аның үзенә йөкләнгән вазифаларыннан чыга. (Алда әле бу хакта сүз булыр.)

Бездән соң президентларыбыз ике мәртәбә очраштылар. Аларга эшләр өчен булачак килешүнең проекты әзерләнде. Ике президент иң мөһим булган берничә мәсьәләне хәл итәргә тиешләр иде. Аларның берсе —

Татарстанның статусы һәм Россия белән мөнәсәбәтләре.

Тик, билгеле булганча, сөйләшүләр бернинди дә нәтиҗә бирмәде. Монда, минемчә, ике сәбәп бар: беренчесе — сәясәттән Г. Бурбулисның китүе. Бу кеше, инде язып үткәнемчә, Россиянең конфедератив элементларны эченә алган асимметрияле федерация булырга тиешлеген таныган иде. Ләкин Россия сәясәтенең иң кырый чигендә торган көчләр аны Татарстан белән сөйләшүдә чигенүләргә барган дип гаепләп чыктылар һәм бу эштән читләштерүне таләп иттеләр. Газеталар, шул исәптән «Аргументы и факты» да, әгәр дә Россия президенты Татарстан белән шул рәвештә төзелгән килешүгә кул куя икән, аңа импичмент[1] игълан ителергә тиеш дип янадылар.

Икенче сәбәп беренчесенә бик нык бәйләнгән: бүгенге Россия җәмәгатьчелегенең күпчелек өлеше һаман әле бөек мәмләкәтчелек сөременнән арына алмый. Шунлыктан Россиядә милли мәсьәләләрне гадел хәл итәрдәй демократик көчләр җитенкерәми. Шулай булгач, Татарстан белән Россия арасындагы тигез хокуклылык нигезендә төзелгән килешүгә берәү дә кул куя алмаячак. Әгәр дә ул моны эшләсә, иртәгәдән үк аның үзенең хәле мөшкелгә әйләнәчәк.

Дөрес, Г. Бурбулистай сәясәтчеләр булса, бу эш икенчерәк төс алган булыр иде. Тик бүген Президентка киңәшләрне башка кешеләр бирә.

Инде эшнең асылына килгәндә, шуны әйтәсе килә. Татарстан тәкъдим иткән асимметрияле, ирекле хокук һәм тигезлек нигезендә төзелгән федерация Россиянең үзе өчен бердәнбер котылу юлы. Империяләр заманы инде үтте. Россия империясенең дә сәгате сукты. Моны бүген кайбер Г. Бурбулис кебек акыл ияләре аң-

---

[1] *Импичмент* — АКШ, Англия кебек илләрдә дәүләт җитәкчеләрен парламент судына тарту.

лый. Җәмәгатьчелек фикере моның өчен кайчан өлгерер? Кайчан президент тирәсендә моны аңлаган сәясәтчеләр тупланыр. Шушы сорауларга җавапны күпме көтәргә туры килер?

Сорау туа: шушы киләчәкне Татарстан көтеп торырга тиешме, әллә үз юлы белән сабыр гына алга таба барырмы?

Китабымның шушы бүлегендә моңа кайбер җаваплар бар кебек. Сүземне тәмамлап шуны әйтәсем килә: без бәйсезлек өчен көрәшнең иң алгы сызыгына чыгып киләбез. Шунлыктан монда хәлиткеч адымнарны Татарстан үзе ясарга тиеш. Кемгәдер ышанып тору, кемнеңдер мәрхәмәтен көтеп яту бәйсезлек өчен барган көрәштә уңай шартлар тудырмас.

Көрәшнең шактый өлешен Россия белән алып барылган ике яклы сөйләшүләр тәшкил итәр дип уйларга мөмкин. Әле монда соңгы сүз әйтелмәгән. Киләчәк очрашуларның нинди нәтиҗә бирүенә карамастан, азатлык безгә барыбер киләчәк! Шикләнмим, бәйсез дәүләтебезнең туу көннәре инде ерак түгел.

Сентябрь, 1993 ел.

КУРЧАК АВТОНОМИЯДӘН — БӘЙСЕЗЛЕККӘ

Без олы юлга кузгалдык. Максатыбыз — иреклегражданнар, тигез хокуклы милләтләр яшәгән ил — бәйсез Татарстан җөмһүрияте төзү. Бу юлда киртәкаршылыклар адым саен очрап тора. Мондый чакта адымыйча атлау өчен тарихка борылып карарга, бүгенге көнебезгә дөрес бәя бирергә кирәк.

1. Үткән юлыбыз нидән гыйбарәт?

1552 елда татар иле яулап алына. Халкыбыз бәйсезлеген югалта. Ләкин ирек өчен көрәш беркайчан да тукталмаган. Россия империясендә күтәрелгән төрле

восстаниеләргә, чуалышларга татарлар азатлыкларын кайтару өмете белән килеп кушылганнар. Октябрь революциясендә һәм гражданнар сугышында да алар большевикларның милли бәйсезлек бирү вәгъдәләренә ышанып катнашканнар. Ләкин вакыт ул вәгъдәләрнең чеп-чи ялган булуын күрсәтте. Баштарак Идел-Урал штаты идеясе чәлпәрәмә килә, аннары Татар-Башкорт җөмһүрияте проекты юкка чыгарыла. Ниһаять, 1920 елда Мәскәү татар халкының нибары чирек өлеше генә яшәгән җирләрдә автономияле республика төзи. Соңрак аның бу хокуклары да, елдан-ел кысылып, курчак автономия гади өлкә дәрәҗәсендә кала. Бу халыкның үзбилгеләнүе түгел, ә өстән билгеләү була.

Шулай да автономияле республика чын дәүләтчелекне аякка бастыру юлында җитди адым иде. 1922 елдан аны союздаш республикага әверелдерү өчен көрәш башлана. Ниһаять, 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителде. Бу, һичшиксез, халыкның үзбилгеләнү акты иде.

Шуннан соң узган бер ел вакыт эчендә халыкның үзаңы бермә-бер үсте. Без Россиянең бер өлеше түгел, ә мөстәкыйль дәүләт, РСФСР белән тигез республика, дип фикер йөртү татарда гына түгел, руслар һәм башка халыклар арасында да киң таралды. Бу президент сайлаганда да шактый ачык чагылды. Республика халкының хәлиткеч күпчелеге РСФСР Президентын сайлаудан баш тартты. Ә Татарстан Президентына сайлаучыларның 75 проценты тавыш бирде. Татарлар республикада 48,7 процент тәшкил итәләр. Димәк, халыкның күпчелеге мөстәкыйльлек идеясе ягында. Бу — безнең соңгы вакытта ирешкән икенче казанышыбыз. Бу инде милләтара аңлашуга, татулыкка ныклы нигез бар дигән сүз.

Милли азатлык хәрәкәтенең яңа биеклеккә күтәрелүен өченче казаныш дип санарга кирәктер. Әле кай-

чан гына Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) бердәнбер милли оешма иде. Хәзер ул Бөтенсоюз статусы алды. Аның бүлекчәләре илнең төрле почмакларында эшли. Хәтта Бөтендөнья татарлары оешмасы барлыкка килде. Бөтен җир шары күләмендә төрле мәсьәләләргә багышланган конференцияләр, конгресслар булып тора. «Иттифак» партиясе дә үзен сизелерлек көч итеп таныты. Республикада шулай ук милли бәйсезлек юлында эш алып баручы «Суверенлык» комитеты оешты. Татар яшьләренең «Азатлык» дигән оешмасы тернәкләнеп килә. Ш. Мәрҗани җәмгыяте, «Иман» кебек төрле милли җәмгыятьләребез бар. Аларның саны уннан артып бара.

Яңару чорының тагын бер куандыргыч күренеше — милли матбугатның яңаруы. Элек яшәп килгән газета-журналлар халыкчанлык юлына басты. Шуның өстенә Казанда, Чаллыда, Әлмәттә һәм башка шәһәрләрдә яңа газета-журналлар чыга башлады. СССРның татарлар яшәгән төрле төбәкләрендә милли матбугат дөньяга килде.

Ләкин мәсьәләгә бер яклы гына карау һич дөрес булмас. Бүген безгә берәү дә: «Мәгез, бәйсез дәүләт төзел, теләгәнчә яшәгез!» — дияргә ашыкмый. Шул ук вакытта Мәскәү безне бөтенләй ишетми-аңламый дип тә әйтә алмыйбыз. Дөрес, Рәсәйнең әлегәчә суверен Татарстанны рәсми рәвештә таныганы юк. Тик тарихның үз объектив кануннары бар. Кемнәрнеңдер теләүтеләмәвенә карамастан, Россия (ГКЧП) фетнәсенә кадәр безне тану юлына баскан иде. 1992 елның 12—15 августында Татарстан һәм РСФСРның вәкаләтле делегацияләре арасында сөйләшүләр булып узды. Мин анда делегация җитәкчесе урынбасары сыйфатында катнаштым.

Анда каралган төп мәсьәлә — Татарстанның Союз килешүенә кул кую рәвешен ачыклау иде. Үзәк матбугат, радио, телевидение безнең республиканың пози-

циясе хакында шактый сүз куертып, җәмәгатьчелектә фикер чуалчыклыгы тудырды. Бүген үзен мөстәкыйль дип санаган һәр республиканың үз позициясе бар. Ә Татарстан СССРны саклап калу ягында торды, яңартылган Союзга тигез хокуклы суверен җөмһүрият буларак керергә теләген белдерде. Бу кем дә булса уйлап чыгарган позиция түгел, ә Югары Советның карары. Һәм ул карардан тайпылырга беркемнең дә хакы юк. Сөйләшүләр барышында РСФСР делегациясенә без шушы позицияне аңлаттык, һәм Татарстанның РСФСР эчендә төзелә торган федератив килешүгә кул куймаячагын белдердек. Ләкин, кызганыч, уртак фикергә килә алмадык. Бу мәсьәлә кузгалган саен, каршы як, безнең моны хәл итәрлек вәкаләтебез юк, дип җавап бирде.

Б. Ельцинның киңәшчесе Г. Старовойтова күптән түгел Казанга килгәч, Татарстан Россиядән чыккан, тик бу турыда РСФСР җитәкчеләренә әйтергә оныткан, дип шаяртмакчы булды. Мондый фикерне без сөйләшүләр вакытында ук ишеткән идек инде. Без аларга болай дип аңлаттык. 439 ел дәверендә әле бер генә татарның да Россиягә керү турындагы документка кул куйганы юк, димәк, ул ирекле рәвештә кермәгән. Димәк, аннан чыгу мәсьәләсе турында сүз куерту урынсыз. Шунда С. М. Шахрай: «Алай булгач, сезнең позицияне мин болай аңлыйм,— диде.— Сез Россиядән чыкмыйсыз, ләкин инде аның составына да кермисез».

Ул безне дөрес аңлады кебек. Кабул ителгән документтагы: «РСФСР һәм Татарстан бер-берсенең статусын күтәрүгә үзара ихтирам белән карыйлар»,— диелгән юллар юкка гына түгелдер. Гомумән, бу документның һәр сүзе киләчәктә ике күрше республика арасында тигез хокуклы килешү мөнәсәбәтләре булдыру рухы белән сугарылган. Минемчә, бу вакыйга тагын бер әһәмияткә ия. Ул 439 елдан соң беренче тапкыр

Россия белән тигез хокуклы сөйләшү башлап җибәрү иде. Аны үткән дәвернең дүртенче казанышы дип бәяләргә кирәктер.

2. Бүген без ни хәлдә?

Дошман көчләр, 1991 елның август фетнәсеннән файдаланып, мөстәкыйльлегебезгә аяусыз һөҗүм ачтылар. Һөҗүмнең үзәге — Президент һәм Югары Совет. Аларның лозунглары: «Шәймиевне — **отставкага!**», «Югары Советны — таратырга!». Бу таләп — суверенлык гарантиясен юк итүгә тиң. Әгәр дә Президент һәм Югары Совет отставкага китсә, алар урынына килүчеләр суверенлык Декларациясен юкка чыгарачаклар. РСФСР эчендә төзеләчәк Федератив договорга кул кую ихтималы артачак. Шулай итеп, без элеккечә автономия кысаларына кереп бикләнәчәкбез. Барысын да өр-яңадан башларга туры киләчәк. Ләкин бүгенге көн — безгә азат халык булу өчен тарих биргән соңгы мөмкинлек булуы да бик ихтимал.

Фетнә көннәрендә Татарстан җитәкчеләре хата җибәрмәгәннәрдер, дип әйтеп булмый, ГКЧПга буйсыну гамәлләре дә булмый калмагандыр. Тик җитәкчеләребез эшчәнлегенең ул көннәрдәге төп юнәлеше республикада стабильлек, тынычлык, тәртип саклаудан гыйбарәт иде. Казан тирәсендә генерал Макашов танклары гәрелдәп торганын да онытырга ярамый. Кечкенә генә саксызлык та әлеге үлем машиналарының, гаскәрнең Казанга керүенә сәбәп булырга мөмкин иде. Әйе, җибәрелгән хаталарның исемлеген төзергә мөмкин. Хәер, аны төзиләр дә инде. Югары органнарның һәрберсеннән аңлатма алалар, шул көннәрдә кабул ителгән документларны җентекләп тикшерү бара. Нигездә, республикага карата җинаять эше кузгатылган.

Суверенлыкка каршы көрәштә башка төрле чаралар да кулланыла. Алар арасында, әлбәттә, беренче

урында мәгълүм кадими ысул: «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!». Бүген азатлык өчен көрәшүче көчләрне эчтән таркатырга, аларны «Шәймиевне — долой!» лозунгысы астына көчләп кертергә маташалар. Икенче ысул — депутатлар корпусын какшату. Югары Советның үткән сессиясендә «Народовластие» төркеменең 12 депутаты Президентның отставкага китүен таләп итте, ә эшләре барып чыкмагач, сессияне ташлап чыгып китте. Ул көннәрдә Югары Совет сессиясенең бердәмлеген җимерә алмадылар. Шулай да, борчулы сорау туа — ә иртәгә хәлләр ничек булыр? Әнә бит Казан шәһәр Советы депутатларының байтагы «долой» лозунгысы йогынтысына бирелде. Башка урыннарда да җирле Советларны таркату эше бара. Деструктив көчләр кулланган өченче ысул — шәһәр-районнарны, предприятиеләрне республика җитәкчеләренә каршы котырту. Халыкта ышанмау, өметсезлек тойгылары уятып, аны урамга чыгарга, Президентны, республика җитәкчеләрен бәреп төшерергә өндәү. Кайбер газеталар, үзәк радио, телевидение дә шушы юнәлештә хәрәкәт итә. Алар Татарстанга каршы яла ягу сугышы ачтылар. Республика турында ялган информация ташкыны көчәйде. Моны Казанга Б. Ельцин тәкъдиме белән килгән Г. Старовойтова да таныргa мәҗбүр булды. «Вечерняя Казань» газетасында басылган халык депутатлары Штанин белән Грачевның халыкка мөрәҗәгате, Хафизовның «Анатомия лжи» дигән мәкаләсе кебек дистәләрчә язмалар кешеләрдә ризасызлык тудыруга юнәлдерелгән. Хәтта университетның кайбер профессорлары, укытучыларның хезмәт хакы артмавына мөстәкыйльлек гаепле, димәкчеләр. Әйтерсең, университет инде Татарстан юрисдикциясенә күчкән.

Ә гайбәтчеләрнең берише болай сөйли: «Шәймиевне Мәскәүдә тәмам сындырганнар, ул хәзер ике төрле уен уйный икән. Җылы урыны хакына төкергән ул синең суверенитетыңа!»

Әйе, явыз көчләр җөмһүриятебезгә каршы туплана-лар. Бер заман аларның тагын әллә нинди астыртын гамәлләре калкып чыгуы бар. Калкып чыгар, әмма ул чакта безнең баткан булуыбыз бар...

3. Нишләргә?

Бу сорау күпләрне уйландыра. Хәзер *беренче чиратта* бүгенге вакыйгаларны салкын акыл белән анализлап, хәлебезгә дөрес диагноз бирү зарур. Әйе, ситуация әлегә Татарстан суверенлыгы файдасына түгел. Ләкин бернинди паникага бирелергә ярамый. Без төшенкелеккә бирелсәк, каршы көчләрнең үз-үзләренә ышанычы артачак. Бу аларга тәвәккәллек өстәр, куәт бирер.

Икенчедән, азатлык яклы көчләрнең бердәмлеген күз карасыдай сакларга, ныгытырга кирәк. Әлбәттә, оешмалар, аерым шәхесләр арасында каршылыклар, аңлашылмаучанлык булырга мөмкин. Ләкин аларның барысын да читкә куеп торыйк. Заманында Казан ханлыгы каршы торырга көче җитмәүдән түгел, төрле даирәләрнең үзара ызгышы, бер максатка берләшеп, уртак дошманга каршы бергәләп көрәшә алмаулары аркасында харап булды. Октябрь революциясе чорында Идел-Урал штаты, Татар-Башкорт җөмһүрияте идеясенең тормышка аша алмавына да сәбәп шул ук. Безнең халыкның тискәре сыйфатларының берсе — кирәгендә бердәм була белмәү. Ниһаять, үткән тарихыбыздан сабак алырга вакыт.

Өченчедән, суверенлыкны яклау, аның төп сыйфаты булган бәйсезлекне гамәлгә ашыру өчен ашыгыч оештыру чаралары сорала. Икътисади чаралар: нефть, нефть химиясе, машина төзелеше промышленностен национализацияләү. Татарстан халкы үз җиренә, аның байлыкларына үзе хуҗа булырга хаклы. Шунсыз кешеләрнең тормыш шартларын яхшыртып булмаячак.

Ә бу, үз нәүбәтендә, милләтара ызгышларга мөмкинлек тудыра. Безнең җиребездә гасырлар буе төрле милләт вәкилләренең үзара аңлашып, ярдәмләшеп яшәве гүзәл гадәт булып киткән. Бу иң кыйммәтле капитал. Аны суверенлык файдасына җигү өчен берни дә кызганырга ярамый. Икътисади чаралар арасында җир һәм авыл хуҗалыгы мәсьәләсе аерым урын алып тора. Колхоз-совхозларда хуҗалык итүнең яңа ысуллары юк дәрәҗәсендә. Моның өстенә юлсызлык, социаль-көнкүреш объектлары җитешмәү, сәүдә, сәламәтлек саклау хезмәтенең начар куелышы авыл халкының теңкәсен корыта. Әле бик күп җирләрдә газ кертелмәгән, техника җитми. Нефть һәм нефть продуктлары сатудан кергән керемнән авылга өлешне кызганмаска кирәк.

Дүртенчедән, законнар тудыруны тизләтергә кирәк. Бу өлкәдә шактый соңга калынды. Без әле һаман РСФСР законнары белән яшибез. Суд һәм суд төзелеше турындагы закон инде күптән эшләнгән булса да, әлегәчә кабул ителмәгән. Эчке эшләр министрлыгы белән Дәүләт иминлеге комитеты, 1920 елның 20 маенда кабул ителгән декрет нигезендә, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау һәм башка ведомстволар кебек үк, тулысынча республика карамагында булырга тиеш иде. Бүген ул карарны тормышка ашырырга вакыт. Республикага хезмәт итә торган бер генә каналлы салым системасы булдырып, Татарстанның дәүләт банкын аякка бастыру зарур.

Татарстан Конституциясе проектының эшләнгән берничә варианты бар. Алар тиз арада тикшерелеп, ел ахырына кадәр кабул ителсен иде. Герб, гимн, флаг мәсьәләләрен хәл итүне дә һаман сузабыз. Ә халык бәйсезлек символикаларына бик нык сусаган.

Бишенчедән, башка республикалар белән ике яклы тигез хокуклы договорлар булдыру мәҗбүри. Бу безнең бәйсезлегебезнең нигез ташы. Билгеле булганча, кайбер җөмһүриятләр белән икътисади хезмәттәшлек

турында килешү төзелде дә инде. Бигрәк тә Башкортстан белән уртак тел табуыбыз әһәмияткә лаек. Ләкин шушы килешүләр системасында безнең өчен иң кирәклесе РСФСР белән ике яклы, тигез хокуклы мөнәсәбәтләр урнаштыру.

Булачак сөйләшүләрнең уңышлы булуы өчен күп шартларның үтәлүе кирәк. Арада иң әһәмиятлеләреннән берсе — Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызтан, Азәрбайҗан республикалары белән багланышка кереп, шушы тугандаш халыкларның ныклы таянычына ирешү.

Бүген җөмһүриятебез авыр көннәр кичерә. Ләкин сынауларның иң җаваплылары алда әле. Бәйсезлек ул тиз җуелса да, аны кире кайтару бик зур батырлык, сабырлык, бердәмлек таләп итә. Мин, табигатем буенча, оптимист кеше, ирек таңы атачагына чын күнелемнән ышанам. Ул таңны якынлаштыру үзебездән тора.

Алда безне азатлык көтә.

ФЕДЕРАЦИЯ БУЛГАНМЫ, БАРМЫ, БУЛАЧАКМЫ?

Мөмкин иде

Әйе, Федерация, чыннан да, булырга мөмкин иде. Россиядә федератив хәрәкәт инде 1905—1907 елларда ук барлыкка килә. Бу эштә либераль профессорлар өстенлек итеп, актив рольне күренекле тел галиме Бодуэн де Куртуне уйный. Шунысы кызыклы, шушы хәрәкәттә ул вакытта әле яшь, әмма һәрнәрсә белән кызыксына торган татар зыялысы Муса Бигиев тә катнаша. Ләкин бу елларда федератив хәрәкәт идеясе киң таралыш ала алмый, Кавказда азәрбайҗаннарның «Мусават», әрмәннәрнең «Дашнакцутюн» партияләре генә бу мәсьәләдә үз йөзләрен билгели алалар. Татарлар арасында

бу чорда әле федерация тарафдарлары күп булмый.

1917 ел федератив хәрәкәткә бөтенләй башка төс кертә. Беренчеләрдән буларак, Кавказ шаулый башлый, Финляндия һәм Польша күтәрелеп чыга. Соңгылары, гомумән, тулы бәйсезлек дәгъвалыйлар.

Федератив хәрәкәтнең юлбашчысы Украина була. Аларның Үзәк Радасына милли социал-демократлар һәм эсерлар кушыла. Шул елның май аенда булып үткән гомуммөселман съезды да Россиянең федератив рәвештә төзелүен таләп иткән резолюция кабул итә. Мәшһүр Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларга якын торган, революциядән соң Мәскәү имамы булган Габдулла Сөләймани Россиянең штатлар нигезендә төзелергә, шул штатларның берсе Идел буе мөселманнарыныкы булырга тиешлеген яклап чыга.

Шулай да, баштарак татарлар арасында федеральлек идеясенең өстенлек алмаганлыгын әйтеп үтмәсәк, бу дөреслеккә туры килмәс иде. Татарларда ул фикер әкренләп үсеп, 1917 елның көзендә инде тәмам ныгый. Татар федералистлары башка милләтләрнең федералистлары белән берлектә эш итә башлыйлар.

1917 елның сентябрендә Киевта Россия халыклары съезды булып уза. Монда татарлардан да вәкил катнаша. Съездда халыклар парламенты төзелеп, анда татарлар өчен дә урын калдырыла. Парламентның башында Үзәк Рада җитәкчесе тарих профессоры М. С. Грушевский тора.

Шушы съездда вакытлы хөкүмәт вәкиле Славинский чыгыш ясый һәм Керенский исеменнән Россиянең киләчәктә тик децентральләшергә, ягъни хакимиятнең регионнарга күчәргә тиешлеге турында сөйли. Әлегәчә безнең тарих фәнендә вакытлы хөкүмәт бүленмәс һәм бердәм Россия тарафдары итеп күрсәтелә иде. Ләкин аның әгъзалары Россияне тик федератив рәвештә үзгәртеп корып кына саклап калырга мөмкин икәнлегенә инанган булганнар, күрәсең. Ул чакта Кавказ, Каза-

гызстан, Төркестан, Украина, Балтыйк буе халыклары федерация төшенчәсен бик нык алга сөрәләр.

Большевиклар властька илгә федерация идеясе ишек каккан вакытта киләләр. Һәм алар моның белән санлашмый булдыра алмыйлар. Чынлыкта, алар марксистлар буларак, федерациягә каршы торалар һәм һәрвакыт федератив дәүләткә караганда унитар дәүләтнең өстенлеген исбат итеп киләләр. Шуңа карамастан, алар федерация идеясен үзләренчә аңларга тырышалар һәм аны үз файдаларына бормакчы булалар. Билгеле булганча, Ленин милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын бары тик теге яки бу дәүләттән бүленеп чыгу дип кенә аңлый. Аның уенча, теләгәннәр бүленеп чыккач, дәүләтнең калган өлеше, аның күпмилләтле булуына карамастан, унитар булырга тиеш. Ленин шуңа нык инанган була. Күпчелек милләтләр Россиядән аерылып чыкмасын өчен ул аларга, кәгазьдә булса да, аерылып чыгу хокукы бирергә кирәклеген аңлый. Ләкин тарих шуны күрсәтә: халыклар кемнең дә булса бу хокукны тану-танымавына карамастан, яисә бүленеп чыгарга, яисә федератив дәүләттә үз республикалары белән мөстәкыйль яшәргә теләүләрен белдерәләр, гел шуңа омтылалар.

Большевиклар баштарак федератив хәрәкәтне бастырырга маташсалар да, аны җиңә алмыйлар. Иң элек Кавказ тулысынча бүленеп чыга, анда бәйсез Әрмәнстан, Азәрбайҗан һәм Грузия дәүләтләре барлыкка килә. Финляндия белән Польша да Россиядән аерылып чыгалар. Бу соңгыларның китүен берничек туктатып була алмаганлыктан, большевиклар аларның бәйсезлекләрен танырга мәҗбүр булалар.

Украина белән исә тарткалаш зурга китә. Украина да үзенең мөстәкыйльлеген игълан итә. Ләкин моңа каршы адым рәвешендә большевиклар, Харьковтан Бөтенукраина Советлар съездын җыеп, Украина Совет Республикасын игълан итәләр. Менә шуннан соң гы-

на, ягъни 1917 елның декабрендә генә большевиклар федератив хәрәкәтне бастырып булмаячагын аңлый башлыйлар. Федератив хәрәкәтне тану гына Россияне бердәм дәүләт итеп калдырачагына ышаналар. Менә ни өчен Үзәк хөкүмәт, Россияне федератив дәүләт итеп белдергәнче үк, Советлар съездында төзелгән Украинаны Россиянең федератив өлеше итеп таный. Бу исә большевикларны ашыгырга мәҗбүр итә. Шуннан соң Советларның III Бөтенроссия съезды Россияне федератив республика итеп игълан итә. Документларда әлеге федерациянең тигез хокуклылык һәм ирекле лек принцибында төзелгәнлеге күрсәтелә. Бүген кайберәүләр, мәсәлән, С. Станкевич, моны «большевистские штучки» дип игътибарсыз калдырмакчы була. Юкса, большевикларның федерация принципларын формаль рәвештә генә танырга мәҗбүр булуларын, бу адымны бүленмәс Россияне саклап калу өчен ясаганлыкларын исбат итеп торасы да юк.

Формаль федератив принциплар, формаль төзелгән федерация чын-чынлап реаль эчтәлек ала башлагач, большевиклар аны туктату чараларын да күрәләр. Алар Россия Федерациясенең бер өлеше итеп игълан ителгән Төркестан, Казагыстан, Башкорт автономияләрен танымыйлар. Алар законлы дип үзләре төзегән республикаларны гына таныйлар. Шул ук Төркестанда игълан ителгән автономия органнарын таратып, аның урынына рус большевиклары Төркестан автономияле республикасы төзиләр. Башкорт республикасын исә большевиклар тик 1919 елның мартында гына, башкорт гаскәрләренең Советлар ягына күчү шарты бәрабәренә генә таныйлар. Башкорт хөкүмәте белән төзелгән шартнамәдә башкорт гаскәренең мөстәкыйльлеге, Башкорт хөкүмәте составында хәрби һәм чит ил тәшкиләтләре булырга тиешлеге күрсәтелә. Ләкин эш бетеп, башкорт гаскәрләрен Врангельгә каршы сугышка алып киткәч, Совет хөкүмәте берьяклы рәвештә әлеге тәшкиләтләр-

не бетерә. Башкорт хөкүмәтенең бернинди шартсыз Үзәк хөкүмәткә буйсынып эш итүен таләп кыла. Мондый оятсыз карарга буйсынырга теләмәгән Башкортстан хөкүмәте үз вәкаләтләреннән ваз кичәргә мәҗбүр була. Шушы вакыйгалардан соң барлык автономияле республикалар да стандарт рәвештә диярлек Үзәк хөкүмәт карары белән генә оешалар. Шулай итеп, үзбилгеләнү хокукын өстән билгеләү хокукы, яки большевикларның тулы диктаты алыштыра.

Гражданнар сугышы бетеп, үз хакимияте ныгыган большевиклар бердәмлек һәм бүленмәслек принцибын инде СССР төзүдә тормышка ашыралар. Билгеле булганча, гражданнар сугышы елларында Украинаның һәм Россиягә көчләп кушылган Кавказ республикаларының кайбер мөстәкыйльлек хокуклары да сакланып килә. СССРның төзелүе аларны шушы хокукларыннан ваз кичтерү белән бер була.

Менә шул сәбәпле Грузия һәм Украина большевикларның автономияләштерү планына, яки барлык республикаларны да Россиягә автономияле республикалар сыйфатында кертүгә каршы чыгалар. Шулай итеп, автономияләштерү планы тулысынча барып чыкмый. Республикаларны сортларга бүләргә туры килә. Ләкин мөстәкыйль дип саналган республикаларның да хокуклары гаять чикләнә. Моңа каршы чыккан Украина Совнаркомы рәисе Раковский, Грузия җитәкчесе Махарадзе соңрак аның җәзасын да алалар.

Ә тигез хокукка омтылган Татарстан, Төркестан, Казагыстан, Башкортстан автономияле республикалар дәрәҗәсендә генә калалар.

Мин китергән фактларга таянып, Россия билгеле бер дәрәҗәдә федератив дәүләт булган икән инде, дип нәтиҗә ясаучылар хата җибәрәчәкләр. Чөнки федеративлык һәм автономия принциплары формаль генә була. Илдә Совет органнары түгел, дәүләт үзе түгел, ә большевиклар хакимлек кыла. Илнең бердәнбер хөкү-

мәте булып РКП(б) Политбюросы тора. Аның җирле органнары исә, республикаларның хөкүмәтләре түгел, партия өлкә комитетлары, ә союздаш республикаларда республика партияләренең Үзәк Комитетлары була. Ә партия исә демократик централизм нигезендә төзелә һәм аның җирле органнары өстән төшкән карарларның һәммәсен энәсеннән җебенә кадәр тормышка ашырырга тиеш була. Һәм бу шулай эшләнә дә.

Шулай итеп, большевиклар халыкларның федератив омтылышларын ялган юнәлеш биреп, нигездә унитар дәүләт төзиләр һәм бу алдау үз нәтиҗәсен бирмичә калмый. Большевиклар властька килгәч, элекке Россиядә моңа хәтле һичкем күрмәгән «явызлык империясе», чын мәгънәсендә халыклар төрмәсе үсеп чыга. Ләкин тарихны алдап булмый. Иң элек СССРның, хәзер инде Россиянең таркалуы шуны раслый.

Әлегә федерация юк

1992 елның 31 мартында Россия составында булган автономияле республикалар «федератив договор» дип аталган килешүгә кул куйдылар. Татарстан һәм Чечнядан башкалары. Шуңа күрә законлы сорау туа: «Бу вакыйгадан соң Россия федерациягә әверелдеме соң?» Әгәр дә Россия җитәкчеләренең үзләрен тыңласаң, монда бернинди шик тә булырга мөмкин түгел. Аларның сүзенә караганда, килешүне имза белән беркетүгә үк, Россия республикалары суверен дәүләтләргә әйләнде.

Халыкара хокук суверенлыкны — бәйсезлек, мөстәкыйльлек һәм законнар өстенлеге итеп таный. Бәйсез дип танылган дәүләтләр исә үз көннәрен үзләре күреп, үзләре ничек тели шулай яшәргә тиешләр. Россия автономияләре алай яши аламы? Юк. Алар өчен Россия законнары өстен. Аларның икътисади мөстәкыйльлеге юк. Үз бюджетлары, налоглары, үз банклары — болар-

ның берсе дә юк. Налогларны Россия хөкүмәте җыя, бюджетны ул билгели. Финанс өлкәсендә Россия Үзәк банкы хакимлек кыла. Ул банкның бүген турыдан-туры Россия хөкүмәтенә буйсынганлыгын искә алсак, мөстәкыйльлекнең бөтенләй юк икәнен аңлау кыен булмас.

Кайбер республикалар федератив договорга махсус өстәмәләр керттерделәр. Аларга Россия хөкүмәте һәм республика җитәкчеләре кул куйган. Башкортстан белән төзелгән шартнамә буенча, мәсәлән, Башкортстан хокук органнары республиканың үз юрисдикциясендә булырга тиеш. Җир байлыклары республика халкының мөлкәте итеп таныла. Башкортстан үз налогын, үз бюджетын булдырырга хокуклы. Ләкин бу шартнамә Башкортстан хөкүмәте «федератив договор»га имза салырга берничә минут калгач барлыкка килгән кәгазь кисәге генә.

Башкортстан, 1919 елдагы шикелле үк, алданды. Ул шул вакыттагы шикелле буш кәгазь тотып калды. Күрәсең, тарих Башкортстан җитәкчеләрен бер нәрсәгә дә өйрәтмәгән. Алар үзләре өчен башкалардан аермалырак ташлама ясатмакчылар иде дә, тик Мәскәүдә дә җүләрләр утырмый шул.

Бүген шунысы да ачык: «федератив договор»га өстәмәләр генә түгел, бу документ үзе дә эшләми. Ул да кәгазь генә булып калды.

Ни өчен шулай соң? Чөнки «федератив договор» ул федерация төзү документы түгел. Россия җитәкчеләре федерацияне инде бар дип саныйлар. Ләкин бу үз-үзеңне алдау гына.

Әмма алар Россияне федератив республика итеп төзелүне теләсәләр, башта аны төзү турындагы килешүне булдырырлар иде. Федерация — ул бит союз. Ә чын союз договор нигезендә төзелә. Андый килешү исә бүгенге көндә юк. Мәскәүдә 1992 елның 31 мартында кул куелган документ тик күз буяу өчен генә «фе-

деративы договор» дип атала. Бу документ бары тик федераль органнар һәм республикалар арасындагы вәкаләтләрне бүлү турындагы документ кына. Аның төп идеясе шуңа кайтып кала. Хакимият тулысы белән Үзәк органнар кулында, ләкин ул органнар, демократия принципларыннан чыгып һәм республикаларның таләбе буенча, үзләренең вәкаләтләрен өлешчә урыннарга бирәләр.

Ә бит Россиянең яңа Конституциясе проектында властьның чыганагы — халык дип күрсәтелгән. Әгәр дә федератив договор чын мәгънәсендә ихлас документ икән, анда властьның чыганагы әнә шул республикалар, аларның халкында икәнлеге күрсәтелер иде. Ул чакта власть өстән аска түгел, киресенчә, астан өскә хәрәкәт итәр иде. Ләкин бу килешү җирле республикалардагы хакимиятнең тик өстән төшкән вәкаләтләре нигезендә генә эшләячәгенә нигез сала.

Шунысын онытмаска кирәк, мондый логика нигезендә, вәкаләтләрнең хуҗасы кем булса, шул хакимлек кыла. Вәкаләтләрнең хуҗасы исә аларны бүген бирсә, иртәгә кире үзенә кайтара да ала. Шулай итеп, «федератив договор» федератив дәүләт төзү турындагы документ түгел. Ул унитар дәүләт булдыруны максат иткән документ.

Өстәвенә бу документка көчләп кул куйдыру ысулы кулланылганын да искә алсак, бүген федерациянең бармы — юкмы икәнлегенә тулы җавап алырбыз.

Өмет бик аз

Федерация булырмы дигән сорауга җавап бирер алдыннан бер-ике тарихи фактка тукталып үтмәкче булам. Үзләрен власть башыннан алып ташлар көннәр җиткәндә Вакытлы хөкүмәт башлыклары, мәсәлән, Керенский, булачак Россия тик федератив дәүләт булып кына яши алачак, дигән нәтиҗәгә килгән иде.

Тулысынча җиңелеп эмиграциягә киткән кадетлар җитәкчесе, тарих профессоры П. Н. Милюков та шулай ук «безне бердәм һәм бүленмәс Россия идеясе харап итте» дигән нәтиҗәгә килә.

Бүген дә шуны әйтеп була. Россия фәкать чын федерациягә әверелгәндә генә яши ала. Беркем дә аны башка рәвештә саклап кала алмаячак. Аның составына бүген бәйсез дәүләтләргә әверелгән Украина яки Кавказ республикаларын кире кайтару турында инде сүз булырга да мөмкин түгел. Бүген Татарстанны яки Чечняны тез чүктерергә тырышу шулай ук акылсызлык. Алар инде үз юлларын сайладылар.

Россиянең саклану-сакланмавы, федерациянең булуы-булмавы бүгенге Россия җитәкчеләренең Татарстанга яки Чәчня республикасына мөнәсәбәтләреннән тора. Кайберәүләр, мәсәлән, Татарстанны һәм Чечняны буйсындыру башкаларга сабак булыр, дип уйлыйлар. Куркыту, янау, төрлечә басымнарның нәтиҗә бирәчәгенә ышаналар. Алар шулай гына империяне саклап калып булыр, дип өметләнәләр.

Әйе, бүген бу көчләр өстенлек итә, тик бернәрсә ачык: Татарстанның теләгенә кем дә булса комачаулык тудырып, аңа каршы катгый чаралар күрә икән, ул вакытта Россия халыклары моннан үзләренчә нәтиҗә ясаячак. Бу — Россия һаман да империя һәм халыклар төрмәсе икән, дигән уйның тагын да ныгуына китерәчәк һәм халыкларны коллык режимына каршы көрәшү кирәклеген аңлауга китерәчәк. Ә инде Татарстан яки Чечняга очкын ташлана икән, аннан чыккан ут, барлык башка җирләргә дә таралып, империя үзе бу утта янначак.

Шулай итеп, язмыш бүген Россияне тарихи дилемма каршына куйды. Ул ике юлның берсен сайлый ала. Беренчесе — империячелек юлы белән китү. Икенчесе — Татарстанны тану, ул кабул иткән Конституциягә ревизия ясауны таләп итүдән баш тарту. Россиянең

күл төзәтмәләр кертеп, ямап бетергән империячел Төп Законы — ул Конституция түгел. Бу бары тик Конституциягә имитация генә. Ул чын-чынлап Төп Законга әйләнсен өчен, аның Россия Федерациясе төзелгән чактагы төп документларга — «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»ндә һәм «Россия республикасының федераль учреждениеләре» резолюциясендә бәян ителгән тигезлек һәм иреклелек принципларына нигезләнеп төзелгән булуы шарт. Әгәр бу принципларны, большевиклар чорындагы кебек, күз буяу өчен генә кулланырга уйласалар, бу барыбыз өчен дә, беренче чиратта, Россия өчен һәлакәт булачак. Үзәкнең әлеге адымнан баш тартмавы Татарстан белән булган мөнәсәбәтләрдә ачык күренә, Россия җитәкчеләре сүздә тигезлек һәм иреклелек принципларын танып, чынбарлыкта исә аны буалар. Федерация язмышы турында кайгырткан булып, чынлыкта империя язмышы гына күздә тотыла. Ә Федерациядә яшәүче халыкларның язмышы хакимият өчен кыйммәт түгел.

Әлбәттә, тарихта традицион юллардан, традицион адымнардан баш тарту авыр бирелә. Ләкин шунысы ачык: гадәттә, тик шуңа барырга сәләтле җитәкчеләр генә тарих йөкләгән бурычка лаек булалар.

РОССИЯДӘ ЯҢА МИЛЛИ СӘЯСӘТ БАРМЫ?

Мондый сораулар бүген торган саен ешрак яңгырый. Россия Президентының милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе Г. Старовойтова отставкага җибәрелде. Милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Россия Фәннәр Академиясенең Миклухо-Маклай исемендәге Этнология институты директоры профессор В. Тишковның да хөкүмәт составындагы карьерасы тәмамланды. Урынлы сорау туа: алар урынына кемнәр калды? Хәзер Президент янында иң якын киңәшчеләрнең берсе — С. Станкевич. Хатыны татар булганлыктан, мин аны татарлар-

га карата ихтирамлы, хәтта мәрхәмәтле мөнәсәбәттә түгелме икән дип уйлый идем. Ялгышканмын. Аның белән беренче мәртәбә 1991 елның 14 августында Россиянең Ак йортында очрашкан идек. Ул Татарстан һәм Россия арасындагы сөйләшүләр алып бару өчен төзелгән Россия делегациясе әгъзасы иде. Аннан соң без 1992 елның 31 мартында сөйләшүләрне дәвам итү өчен яңадан җыелгач күрештек. Аның позициясе ачык: бердәм һәм бүленмәс Россияне саклау. «Рус идеясе» аның башына бик нык кереп урнашкан. Башка милләтләрне ул тик русларга буйсынган рәвештә генә күзаллый ала. Россияне саклап калу өчен һәммә нәрсәгә дә әзер икәнлеген һич кенә дә яшерми.

Хәзер В. Тишков урынына С. Шахрай килде. Татарстанда аны яхшы беләләр. Август фетнәсеннән соң ул, Татарстан ГКЧП ягында булды, дигән сылтау белән Казанга килеп төште һәм биредә Россия Президентының турыдан-туры идарәсен кертмәкче булды. Ләкин ул вакыт безнең халкыбыз дәррәү кузгалып Югары Советка басым ясады. Бу мәсьәләне көн тәртибенә куеп, сүз куертырга ирек бирмәде.

С. Шахрай белән дә Мәскәүдә сөйләшүләр вакытында танышкан идек. Ул көннәрдә миндә С. Шахрай яхшы тәэсир калдырган иде. Аның фактларны, килеп туган хәлне анализларга омтылуы, Татарстанның позициясен аңларга тырышуы күренеп тора иде. Бу, бәлки, Россия делегациясен җитәкләгән Г. Бурбулис йогынтысы гына булгандыр. Ихтимал.

Тик аның шушы очрашудан соң Казанга килеп, анда «тәртип урнаштырырга» теләве баштагы тәэсирне үзгәртте. Аның демократ булып кылануын мин һәм, гомумән, безнең Татарстан делегациясе әгъзалары чынга алып ялгышканбыз икән. Шахрай — шул ук Станкевич. Тик «бердәм һәм бүленмәс Россия» идеясен башкачарак үткәрергә тырышуы гына аны кайберәүләрдән аерып тора. Ул чыбыркы урынына прәннек куллануны

хуп күрә. Тик безнең моңа алданмасны күргәч, ул да, Руцкой кебек үк, чыбыркыга ябышты.

Әгәр дә без Россия милли сәясәтен үткәрүчеләр рәтендә О. Румянцевның исемен атамасак, бу аңлашылмас иде. Ул соңгы елларның шаукымы белән өскә калкып чыккан кеше. Үзен демократ итеп күрсәтергә тырышуы аркасында Россия Югары Советына депутат булып үткәннәрнең берсе дисәк, бу дөреслеккә туры килер. Б. Ельцин җитәкчелегендәге Конституция комиссиясе төзелгәч, ул анда җаваплы секретарь итеп билгеләнде. Күрәсең, Б. Ельцин күпләр арасыннан аны максатчан кеше булуын тоеп сайлап алгандыр. Президент аның карьерага омтылучанлыгын, моңа ирешү өчен берни алдында да тукталмый торган кеше икәнен дә күргән булса кирәк. Әйе, күргәндер. Димәк, Россия Президенты О. Румянцевны автономияләр белән көрәшүчеләрнең берсе сыйфатында күз алдында тоткан булып чыга. Конституция комиссиясе эшчәнлегендә генә түгел, агымдагы сәясәттә дә. Мәсәлән, аның Курил атауларына булган мөнәсәбәтен һәм конкрет эшләрен исегезгә төшерегез. Ул бит анда барып, халыкта Японийгә каршы тойгылар уятып йөрде. Ләкин, безнең мәгълүматларга караганда, Курил атавы халкы аны митингларда сүздән мәхрүм иткән.

О. Румянцевның ни өчен Конституция комиссиясе секретаре вәкаләтләренә хас булмаган вазифалар башкарып йөрүе ачык аңлашыла. Аның төп максаты — Конституция комиссиясе аша бердәм һәм бүленмәс Россия идеясен үткәрү. Аңа калганы үзеннән-үзе хәл ителер кебек тоела. О. Румянцевның әле башы яшьрәк шул. Чынбарлыкның күпкә катлаулырак икәнлеген ул әле аңлап бетерми. Бәлки инде аңламас та. Сез аның Конституция комиссиясендәге кыланышларына гына игътибар итегез. Ул, ике сүзнең берендә «демократия» сүзен кулланып, демагогик рәвештә халыкны күккә чөеп мактап эш итсә дә, нигездә Россиядә демократик

строй урнаштыру ягында түгел. Бер чыгышында ул, мәсәлән, «хокукның төп чыганагы — халык, хакимият халыкның үзеннән үсеп чыга», дип белдерә. Ләкин шул ук вакытта Россиянең губерналарга бүленеп, анда каты Президент хакимияте урнаштырылырга тиешлеге турында тәкъдим кертә. Шулай итеп, О. Румянцев «халык» төшенчәсен абстракт рәвештә генә куллана. Аның фикеренчә, Россия составындагы автономияле республикаларның бернинди хокуклары да юк. Халыклар тик Россия өстән иңдергән хәер-фатиха белән генә яшиләр икән.

Алай гына да түгел, ул үзен зур теоретик сыман хис итеп, союздаш һәм автономияле республикаларның баштан ук төрле хокукта булганлыкларын исбат итәргә тырыша, һәм СССР белән РСФСР арасында «кытай стенасы» булдырырга тели. Ләкин шул ук вакытта аның элементар арифметика кебек әйберләрне дә белергә тырышмавы күренә.

Янәсе, СССР республикалары ирекле союз рәвешендә туган булсалар, РСФСР республикалары өстән төшкән вәкаләтләр нигезендә генә яшәп яталар. Бу кеше, күрәсең, башта һәммә республиканың да РСФСР составында яки аның тирәсендә туганлыгын белми. Әйтерсең, аның РСФСРны төзегән документларны гомерендә дә күргәне юк. Ә бит үзен шулкадәр гыйлем иясе итеп күрсәтергә тырышкан кешегә 1918 елның гыйнварында Советларның III Бөтенроссия съезды кабул иткән документларны алып каравы бер дә авыр эш түгел. Нәкъ шул документлар Федератив дәүләт төзүгә нигез булды. Һич шигем юк, О. Румянцев ул документлар белән таныш. Аларны С. Станкевич та белә. Ләкин үзләренә файдалы булмаганлыктан, алар Россия документларын «большевистик штучкалар» дип кенә белдерәләр. Әмма ләкин алардан баш тарту — Федерациянең үзеннән баш тарту. Ул чакта аны яңадан төзергә кирәк була. Хәзер моны башкарып чыгу мөмкинме,

юкмы? Монысы да зур сорау тудыра. Шулай булгач, ничек кенә ошамасалар да, әлеге «большевистик штучкалар»ны танырга туры килә.

Бу мәҗбүрияттән С. Станкевич та, С. Шахрай да берничек котыла алмыйлар. Моны ун мәртәбә кабатларга мәҗбүрмен, ул документларда, ягъни «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»ндә, «Россия республикасының федераль учреждениеләре» резолюциясендә Россия Федерациясенең «тигез һәм ирекле хокук принципларына корылган» икәнлеге, аның «халыклар союзы» булуы ачыктан-ачык язылган. Шунлыктан РСФСРның 1918 елда кабул ителгән Конституциясендә дә Россиянең ирекле һәм тигез хокуклы республикалар союзы икәнлеге күрсәтелгән. Ә аның 2 нче һәм 47 нче маддәләрендә республикаларның РСФСРдан чыгу хокуклары теркәлгән.

Менә ни өчен О. Румянцев бу документларга күз йомып үтмәкче була. С. Станкевич исә алар бөтенләй булмаган шикелле эш итә. Һәм тарихны да, кабул ителгән документларны да, халыкларның ихтыярын да танымаган шушы кешеләр хәзерге көндә Россиянең милли сәясәтен алып баралар.

Рәислектән — гаскәр башына

Россия Президенты В. Тишков урынына С. Шахрайны билгеләгәч, аңа Милләтара мөнәсәбәтләр комитеты рәисе вазифалары гына аз булыр кебек тоелды ахры, С. Шахрай бер үк вакытта вице-премьер дәрәҗәсен дә алды. В. Тишков Төньяк Кавказга тәртип урнаштырырга баргач, гаскәр башына басарга базмады. Вице-премьер С. Шахрай исә Төньяк Осетия һәм Ингуш республикаларында Россия Президенты билгеләгән администрация башлыгы да булды. Аңа барлык коралды көчләр буйсындырылган. Дивизияләр, танклар, самолетлар, ракеталар — барысы да аның кул

астында. С. Шахрай үзе десантниклар формасыннан, изүеннән тельняшкасы күренеп тора. Шул рәвешчә телевидениегә чыга, интервью бирә. Ә гаскәрләргә югары хәрби әзерлектә торырга әмер җиткерелгән. Танклар казылмаларга урнаштырылган, солдатларның кораллары бер секунд эчендә эшкә тотынырга әзер. Чак кына Чечня гаскәрләре белән утлы бәрелеш булмый калды. Төньяк Кавказ республикаларындагы татар иҗтимагый оешмасыннан килгән вәкилләр Россия солдатлары арасында Татарстаннан килгәннәр дә бар, дип хәбәр иттеләр. Россия Президентын сайлауда катнашмаган бу егетләрне Россия Президенты указы белән утка кертергә кемнең хакы бар? Әгәр безнең республика җитәкчеләре бу егетләрне ут сызыгыннан чыгарырга батырчылык күрсәтә алмыйлар икән, димәк, Президент буларак, дәүләт җитәкчесе буларак, алар үзләре өстенә төшкән җаваплылыкны аңлап бетермиләр.

Мондый хәлдә мин ике парадокс яки каршылык күрәм. Беренчедән, әгәр дә бездә Президент сайланган икән, ул инде мөстәкыйль дәүләт башлыгы дигән сүз. Мәстәкыйль дәүләтнең мөстәкыйль хәрби доктринасы да булырга тиеш. Хәрби хезмәткә кемне чакырырга, кая җибәрергә — ул үзе хәл итә. Татарстанның моңа ирешә алганы, хәтта омтылганы да юк. Бу — һичкемгә, бигрәк тә чит илләргә аңлашылмый торган хәл. Икенче парадокс — Россиянең дәүләт төзелеше һәм милләтләр эшләре комиссиясе рәисе, милли республикаларга барып, танкка атлана. Ингушларны һәм Төньяк Кавказдагы халыкларны бер мәртәбә, инде йорт-җирләрен туздырып, сөргән иделәр. Хәзер кабат алар өстеннән танклар үтте. Бу вакыйга Россия хөкүмәтенең конкрет эшләре геноцид һәм халыкларга каты басым ясаудан гыйбарәт икәнлеген бәхәсләшүгә урын калдырмаслык итеп дәлилләде. Бүген С. Шахрай Төньяк Кавказдан торып, барлык милли республикаларга басым ясый. Сәясәттән ерак торучыларга бүген элекке Россия тер-

риториясендә бара торган хәлләр бер-берсенә бәйләнмәгән сыман тоелса да, игътибар беләнрәк караганда, аларның бер сценарий буенча эшләнүе аңлашылып тора. (Референдум чорында Татарстан тирәсендәге ыгы-зыгы хәтерегездәме? Мин бу очракта вак-төяк ыгы-зыгыны күздә тотмыйм. Ә Казан тирәсендә танк моторлары гөрелдәвен, Зеленодол шәһәре тирәсенә гаскәрләр туплануын, ә Р. Хасбулатовның референдум нәтиҗәләрен Волжскига килеп көтеп торуын искә төшерәм.)

Шушы сценарийлар буенча, нигәдер Төньяк Кавказда туплар гөрселдәве Татарстан Конституциясе кабул итүлү һәм аны гамәлгә кертү турында Закон әзерләү чорына туры килә. Россия Югары Советының комиссияләре утырышы О. Румянцевның янау-куркытуы астында үтә. Шул ук Югары Советка депутат итеп сайланган Татарстан вәкилләре В. Фәхретдинов һәм В. Морокин үз республикаларын Россиянең Конституция Судына бирү өчен имзалар җыеп йөриләр. Татарстан Югары Советының «Народовластие», «Согласие» төркемнәре исеменнән халык депутатлары Штанин, Грачев, Михайлов һәм Солтанов аларга булышлык кылалар. Юк, бер С. Шахрай гына танк өстендә басып тормый. Барлык кара көчләр бергәләшеп республиканың «кара көнен» билгеләп үтәргә җыеналар. Кайсы кара материя эзли, кайсы кара җеп хәстәрли. Ә өлгене Конституция Суды тарафыннан көтәләр.

1992 елның 6 ноябре көнне Татарстанның Югары Советы дәүләтебезнең Конституциясен кабул итте. Аңа каршы котки, проект басылып чыккан көннән башланып, көчәйгәннән-көчәя барды. Нишләп котырынмасыннар, ди? Чынлыкта, бит моңа кадәр бездә Конституция булганы юк иде. Конституция булып йөргәне исә һәммә автономияләр өчен бертөсле итеп Россия Конституциясенә буйсындырылып төзелгән, ә дөресрәге, тулысынча шуңардан күчерелгән кәгазь кисәге генә

иде. Империя тарафдарларының борчылуы Татарстанның беренче мәртәбә мөстәкыйль рәвештә үз Төп законын кабул иткәне өчен генә түгел. Эш шунда ки, безнен Конституциябез империячелек таләпләренә капма-каршы килә. Ике арадагы тигезлекне шәхескә генә түгел, милләтара һәм дәүләтара мөнәсәбәтләргә дә тарата.

Чит ил экспертларының әлеге документны хокукый дәүләтнең Төп законы дип тануы империячел көчләрне аеручa ярсытты. Алар Татарстан Конституциясен Россия Конституциясенә буйсындыру өчен ике ай срок биреп, әгәр дә шушы срокка эшләнмәсә, каты чаралар күрергә, дигән тәкъдим белән чыктылар. Ни рәвештә? Беренчедән, Татарстанның оборона предприятиеләрен, югары уку йортларын финанслауны туктатырга. Әйтерсең лә, аларны Татарстан үзе өчен төзегән дә, алардан файда күреп ята. Әйтерсең лә, Татарстан югары уку йортларында кадрларны үзе өчен генә әзерли. Ләкин мондый мантыйк О. Румянцевларны кызыксындырмый.

Алар өстәвенә Татарстан өчен Россиянең пенсия фондын ябарга җыеналар. Мондый янауны халыкка белдерү өчен нинди оятсызлык кирәк! Пенсия фонды — хәйрия фонды түгел, ул кешеләрнең үзләре эшләгән чакта тупланып барган сумма. Әйе, Россиядә демократиянең үзе түгел, исе дә юк. Аның урынына демагогия хакимлек итә. Сез аларның Татарстан Конституциясен Россиянекенә тиңләү таләбенә генә игътибар итегез. Иң башта шуны әйтик, әлегә Россиянең үз Конституциясе юк. Чөнки ул һаман әлеге дә баягы «демократлар» сүгә торган коммунистик чорда төзелгән Конституция белән яши. Аңа ямау салалар, яисә урта бер җиреннән бөтенләе белән бер өлешен кисеп алалар. Шулай итеп бу документ аламаланып бетте. Шул сәләмәне безнең халыкара экспертиза үткән хокукый дәүләт Конституциясен алыштырып, яки аңа тәңгәл-

ләштереп буламы икән? Аларга сәләмә ярый дип, без дә сәләмә киик микән?

Конституцияләрне тәңгәлләштерү дигәндә, минемчә, нигездә аның өч маддәсен күздә тоталар. Берсе — Татарстанның халыкара хокук субъекты булуын күрсәткән маддәсе; ягъни империячел көчләр Татарстанның үз ирке белән башка ил-дәүләтләр белән багланышта булмавын таләп итә. Икенчесе — гражданлыкка кагылганы. Алар фикеренчә, Татарстан һәм Россия гражданлыгы тигез хокукта булырга тиеш түгел. Россиянеке өлкән, Татарстанныкы кече булса гына килешергә мөмкин икән. Ягъни элеккечә, өлкән республикага — кече республика, өлкән туганга, кече туган буйсынган кебек, хәзер дә өлкән гражданлыкка кече гражданлык буйсынырга тиеш икән.

Өченче маддә — Татарстанның Россия белән мөнәсәбәтләре турыдагысы. Алар фикеренчә, бернинди ассоциатив мөнәсәбәтләр булырга мөмкин түгел. Татарстанның Россия Федерациясе субъекты икәне туп-туры күрсәтелсә генә сөйләшүләр алып барырга мөмкин икән. Әгәр дә без империячел хакимият вәкилләренең әлеге таләпләре белән ризалашсак, дәүләт суверенлыгының төп шартларын юкка чыгарган булачакбыз. Без хәзерге көндә 1918 елга — Федерация төзелгән моментка — тигез хокуклы һәм ирекле Федерация төзү мөмкинлегенә кабат әйләнеп кайттык. 1924 ел Конституциясендә әлеге принциплар томанландырып бирелгән булса, 1937 елгы Конституция белән бөтенләй бозылды, ә Брежнев Конституциясендә төшереп үк калдырылды. Бу хәлне гади телдә дәүләт перевороты дип атыйлар. Ләкин СССРның ул вакыттагы хакимияте бернинди халыкара нормалар белән дә санашмый яшәде. Әнә шул Конституциягә переворотка тәңгәл үзгәрешләр кертү дистәләгән халыкларны бөтенләе белән геноцидка китерде. СССР дип аталган, әмма Россия дип

аңланган илдә — бер генә илдә дә, бер генә тиран да кылмаган явызлыклар эшләнде.

Инде бүгенге көнне үзләрен демократия юлына бастык дип игълан иткән кешеләр әнә шул «явызлык империясе»нең Конституциясенә таянып эш итәләр икән — алар, димәк, империя тарафдарлары. Әгәр дә алар шул Конституция нигезендә Татарстанны суд җаваплылыгына тартырга уйлыйлар икән, димәк, алар Сталин сәясәтен дәвам иттерүчеләр.

Россиядә милли сәясәт бармы? Югарыда китерелгән фикерләр моңа бу илдә яңа милли сәясәт юк, дип җавап бирә. Һаман да шул иске, патша заманыннан мирас итеп калдырылган, Сталин тарафыннан «ныгытылган», халыклар төрмәсен саклап калдыруга юнәлдерелгән сәясәт кенә бар.

Әгәр дә Россия гаделлек принцибына корылган яңа дәүләт буларак аякка басарга тели икән, әлеге искелекләр төбе-тамыры белән йолкып алынырга тиеш. Шунсыз Россиянең үзен дә коткарып булмаячак — анда яшәгән халыклар коточкыч һәлакәткә киләчәк.

Россия җитәкчеләре — алар арасында саф акыллы кешеләр юк түгел — шуны аңласыннар иде. Халыкларга сугыш түгел, тынычлык кирәк. Алар куркытуга, янауга мохтаҗ түгел. Алар ирек һәм гаделлек дәгъвалый.

РОССИЯ НИНДИ ЮЛДАН КИТӘР?

Уңгамы, сулгамы?

Бүгенге көндә Россиянең юл чатында торганлыгын берәү дә инкяр итә алмастыр. Ләкин ул нинди юлдан китәр? Бусына шулай ук берәү дә тулы җавап бирми. Россия җитәкчелегенең иң югары баскычларында да илнең иртәгесен күзаллаучы кеше юк, диләр. Россия-

не төрле рәвештә күрергә теләүчеләр бар. Берәүләр өчен ул монархиягә әйләнеп кайтырга тиеш. Романовлар династиясе белән кызыксыну юкка гына артмады бит. Николай II гаиләсе атылган урындагы чиркәүне торгызып, патшаның үзенә һәйкәл кую, телевизордан аның баш сөяген селкеп күрсәтү — берсе дә җирлексез генә килеп чыккан нәрсәләр түгел.

Нигә соң патшалы Россияне сагыналар һәм кемнәр сагына? Бәлки бу патшаның үзен сагыну түгелдер, ә империяне сагынудыр. Аңа кайтырга омтылудыр. Моның шулай булуына дәлилләр юк түгел. Казакларга булган игътибарны гына карагыз. «Военно-исторический журнал» саннан санга казаклык тарихына багышланган мәкаләләр биреп бара. Бу темага багышланган махсус китаплар басылып чыга.

Алай гына да түгел. Казак гаскәрләрен торгызу практик нигезгә салынды. Россиянең һәрбер шәһәрендә диярлек аның регуляр формированиеләре калкып чыга. Казаклар Татарстан тирәсендәге шәһәрләрдә дә активлык күрсәтә башладылар. Хәтта Казанның үзендә дә ара-тирә, уен рәвешендә генә булса да, казаклар күренә.

Шушы эшләр белән Россиянең вице-президенты А. Руцкой махсус шөгыльләнә. Монархия тарафдарлары хөкүмәт составында аз түгел. Алар «бердәм һәм бүленмәс Россия»не тик көч, монарх властена таянган көч кенә саклап кала алачагына инаналар.

Монархия тарафдарларының кулы Россия конституциясенең проектында да күренә. Губерна системасына күчү идеясе әнә шул омтылышны чагылдыра. Аңлы рәвештәме, юкмы, Б. Ельцин үзе дә урыннарга губернаторлар билгели башлады. Губернаторлары булгач, губернасы да булыр инде. Ә губернатор ул патша власте вәкиле.

Икенче тенденция — Россиянең киләчәген бердәм һәм бүленмәс республика итеп күрү. Аның тарафдар-

лары өлге итеп кадетлар күтәргән идеяне алалар. Бүгенге кадетларның һәм аларга якын булган сәяси көчләрнең Россияне көчле республика рәвешендә күрәселәре килә. Болары да Россиянең федератив төзелешенә каршы. Алар, монархия тарафдарлары кебек үк, милли автономияләрне булдырмау ягында. Әгәр дә федератив килешүгә игътибар белән карасаң, анда милли дәүләт төзелешен административ-территориаль принцип белән алмаштыру юллары салынган булуын күрү кыен түгел.

Россия конституциясе проектында тагын бер омтылыш ярылып ята: ул, бүгенге өлкәләрнең статусларын республика дәрәҗәсенә күтәреп һәм аларны милли республикалар белән тигезләп, милли дәүләтчелекне тик вакытлы бер корылма итеп кенә күрергә тырышу. Монархия режимы белән «бердәм һәм бүленмәс Россия» идеясенең аермасы бары тик сүздә генә. Аларның асылы бер үк. Перспективалары тик коралга таянуны гына күздә тота. Чөнки алар нигездә һәммәсе дә империалистик идеяләр.

Өченче фикер тарафдарлары да бердәм һәм бүленмәс империягә каршы түгел. Хәтта киресенчә. Элегрәк аларның да шуннан башканы тыңлыйсылары да килми иде. Ләкин алар реалистлар, объектив тенденцияләрнең юнәлешен яхшы күзаллыйлар. Шуңа күрә Россиянең асимметрияле федерация булуына ризалар. Бу исә алга таба зур адым булачак. Чөнки бу, ниһаять, федерация принцибын тану дигән сүз. Элек бу принцип (Лениннан башлап безнең көннәргә кадәр) фәкать фасад итеп кенә файдаланыла иде. Әгәр бу идея чынлап торып тормышка ашырылса, халыкларга суверенитет алу җиңелрәк булачак.

Чыннан да, элеккеге дәүләт төзелеше концепциясе буенча барлык республикалар да федерация составына бер хокукта, дөресрәге, бертигез хокуксызлык нигезендә керергә тиеш булсалар, хәзер исә республикалар-

ның үзенчәлекләре искә алыначак. Аларның федерациягә керү рәвешләре дә төрлечә булачак. Аңа өлешчә генә керү мөмкинлеге дә туачак. Ә анысын инде республикалар үзләре ачыклап, Россия Федерациясе белән ике яклы шартнамә нигезендә бөтен мөнәсәбәтләрне дә билгеләячәк.

Монда тарихка әйләнеп кайтып бер-ике сүз әйтеп китү урынлы булыр. Әгәр «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»нең соңгы пунктын укып карасак, анда нәкъ без әйткән фикернең салынганлыгын күрербез. Әлеге документны кабул иткән III Бөтенроссия съезды аның соңгы пунктында федерациянең гомуми нигезләрен яки тигез хокуклылык һәм ирекле лек принципларын урнаштыру белән чикләнә, диелгән. Республикалар исә федератив хөкүмәт оештыруда катнашу мәсьәләсен, катнашсалар ни рәвештә икәнен үзләренең Совет съездларында билгеләргә тиеш булалар. Димәк, асимметрияле федерация идеясе әнә шул вакытта ук туган булган. Ул чакта Россиянең бердәмлеген коткарып калырга омтылган большевиклар әлеге алымга барырга мәҗбүр булганнар. Чөнки ул чакта бу идеяне язып куюдан бернинди оттырыш та булмый. Большевиклар бит тик үзләренә буйсынган советларны гына таный килделәр. Ә инде андый съезд һәм советларның нинди карар кабул итәчәкләре алдан ук хәл ителгән була.

Украина Радасы (советы) мөстәкыйльлеккә йөз тоткан иде. Большевиклар шунда ук аңа ультиматум белдереп, сугыш игълан иттеләр. Шуннан соң Харьковта үз тарафдарларыннан торган Советлар съезды чакырып, Украинаны Советлар республикасы — Россиянең федератив өлеше итеп игълан иттеләр. Төркестанда да, Башкортстанда да, Татарстанда да шул ук хәл кабатланды.

Шулай итеп, большевиклар асимметрияле федерацияне сүздә генә танып, нигездә аны үзләре теләгәнчә

кордылар. Федерация флагы астында моңарчы гомер булмаган унитар дәүләт, тоталитар режим төзеделәр.

Хәзер дә большевикларның шушы тәҗрибәсен кулланырга теләүчеләр юк түгел. Кайбер акыллы башлар сүздә алтын таулары вәгъдә итеп, гамәлдә республикаларны, халыкларны империалистик хакимият астында калдыруны хуп күрәләр.

Ләкин бүген ситуация башкачарак. Большевиклар заманында дәүләтнең федератив төзелеше, алар җитәкләгән партиянең унитарлыкка, тимер дисциплинага һәм мәҗбүрияткә корылган булуы каплап килә иде. Хәзер исә андый дәүләт властен алмаштыручы партия юк. Шунлыктан федерацияне тик фасад итеп кенә куллану азыррак. Аны чын-чынлап булдырырга, яки бәтенләй баш тартырга гына мөмкин. Шулай да милли республикалар да хаталанудан хали түгел. Әгәр бервакыт ситуация үзгәреп, Россиядәге сәяси һәм икътисади хәл стабильләшсә һәм үзәк властьлар позицияләрен ныгытса; шулай ук бер-бер артлы законнарга, яки Конституциягә төзәтмәләр кертелеп, башта федерациянең асимметриялелеге яки республикаларның үзләре билгеләгән хокуклары бетерелсә, ул вакытта аларның үзләрен бөтенләе белән юкка чыгарырга да мөмкиннәр. Бу очракта, төрле иҗтимагый хәрәкәтләр сүнгән булганлыктан, мондый башбаштаклыкка ачыктан-ачык каршылык күрсәтүче көч калмаган булуы да ихтимал. Хәтта, кайберәүләр теләгәнчә, монархиягә күчү дә мөмкин булачак.

Тик бу әле эш бетте, бердәм һәм бүленмәс Россия сакланды дигән сүз түгел. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә. Большевикларның ялганнары аркасында, Россия дигән ил бүген катастрофага килеп әләкте. Моннан соң да шулай булачак. Аерма шунда ки, бу эшләр большевиклар хакимияте чорындагы кебек җитмеш елга сузылмас, бер-ике ел эчендә юкка чыгар, һәм дә шуның белән империя дә бетәр.

Бүгенге асимметрияле федерация тарафдарлары арасында моны аңлаучылар юк түгелдер, дип уйларга кирәк. Халыкларны алдауга, аларны изүгә корылган «явызлык империясе» барыбер яшәргә хаклы түгел — бу табигать, иҗтимагый үсеш законнары белән раслана.

Дөрес юл табылмаса?

Бүген туган сәяси үзгәрешләргә караганда, Россия җитәкчелеге шушы дөрес юлдан читкә тайпылды шикелле. Бүген хакимияттә, Россиянең бер метр җирен бирүгә дә бирмибез һәм хакимиятебезне тулысы белән саклыйбыз һәм яклыйбыз, дигән фикердә торучылар өстенлек алды.

Руцкой һәм Румянцев нәкъ шундый кешеләр. Алар вакытында җәнҗал чыгарып, Б. Ельцин Япониягә утраулар сата икән, дип коткы тараттылар. Шулай итеп Россия Президентының Япониягә булачак визитын өзделәр.

Хәзер инде алар Татарстанга ябыштылар. Аның кабул ителгән Конституциясен гамәлгә керттермәс өчен, Россия халык депутатлары съездына куеп, Татарстанны тезләндерүне үзләренә максат иттеләр. Тик бусы барып чыкмады. Шул көчләр үк, Төньяк Кавказга гаскәр кертеп, ингушларга ярдәм итү флагы астында бер республиканы икегә бүлделәр һәм Чечняны да, Ингушетияне дә Россия составындагы республикалар дип игълан иттеләр. Шулай ук Б. Ельцинны бер ташлама артыннан икенчесен ясарга мәҗбүр итәләр. Нигездә алар инде хөкүмәт сәясәтен тулысы белән үзгәртүгә якынлаштылар. Хәзерге максатлары, икътисади өлкәдә башланган реформаларны туктатып, бөтен идарәлек вәкаләтләрен урыннардан кире Үзәккә җыеп алу. Кыскасы, хәрби коммунизм алымнары яңадан торгызыла. Мин Россиядәге икътисади реформаларны дөрес юнәлештә бара дип әйтмим. Ләкин шулай да бу өлкәдә

кайбер иреклелек барлыкка килгәнлеген бирәү дә инкяр итә алмас дип уйларга кирәк. Урындагы властьларның вәкаләтләрен кире тартып алу элеккеге автономияләрнең суверенлык хокукларын яңадан җуюы дигән сүз булыр иде.

Хөкүмәт составында зур үзгәрешләр булды. Милли мәсьәләләрнең юнәлешен билгеләп баручы Галина Старовойтованы урыныннан алдылар. Әлбәттә, бу безнең өчен кулай кеше түгел иде. Хәтта аның да милли сәясәткә булган карашлары кара көчләргә ошап бетмәгән. «Бердәм һәм бүленмәс Россия» тарафдары булуына карамастан, В. Тишков та шулай ук милли мәсьәләләр комитеты рәисе постыннан азат ителде. Ул да ярый алмады. Чөнки Төньяк Кавказда аңардан сүз түгел, хәрәкәт көтелгән иде. Ләкин ул моны булдыра алмады һәм шуның белән үз язмышын хәл итте. Аның урынына Төньяк Кавказга С. Шахрай килде һәм танкка менеп атланды. Димәк, милли мәсьәләдә көч куллану ысулы өстенлек алды. Гүя массакүләм информация чаралары милли һәм башка сәясәттә үз эшләрен эшли алмаганнар. Әйтерсең лә, Татарстанда референдум үткәрелгән вакытта информацион блокада аз булган. Әйтерсең лә, пресса, радио, телевидение демократия ысулларын кирәгеннән артык кулланган булып чыккан. Шулай булмаса массакүләм информация чаралары министры — Президентның иң якыннарыннан берсе М. Полторанин отставкага китмәс иде.

Ләкин моның белән генә эш бетмәде. Телевидение хуҗасы Егор Яковлев та китте. Ул да Б. Ельцинның якыннарыннан иде.

Сәясәттә империя тарафдарларының озын куллары моңарчы нык утырган Г. Бурбулиска да барып җитте. Президент каршындагы дәүләт секретаре посты бетерелде. Президент киңәшчеләре төркеме җитәкчесе итеп билгеләнгән Бурбулис сәяси аренадан китмәде китүен. Шулай да ул акрынлап чигенергә мәҗбүр була. Рос-

-сия халык депутатларының VI съезды алдыннан хөкүмәткә атака башлангач, Ельцин аны беренче вице-премьер вазифаларыннан азат иткән иде. Г. Бурбулиска каныгуның бер сәбәбен мин аның асимметрияле федерация тарафдарлары булуында күрәм. Ул милли хәрәкәтне көч белән җиңеп булмаячагын ныклап аңлаган кеше һәм Россия Президентының бу мәсьәләгә карашы беренче чиратта шушы кешедән чыккан фикер аша формалаша иде. Менә нинди кискен үзгәрешләр күренә бүгенге сәясәт күгендә. Менә нинди тенденцияләр өстенлек ала. Болай булса, тиздән Ельцинның да властьтан коры калуы ихтимал. Аны да Горбачев язмышы көтә. Тик бу үзгәрешләр әле хәл ителмәгән. Иң зур үзгәрешләр, власть өчен зур чәкәләшүләр алда әле.

Дөрес юл бармы?

Татарстан белән Россия арасында булган катлаулы мөнәсәбәтләр шул дөрес юлга чыгу тенденциясен билгели. Безнең Россиягә ясаган тәкъдимнәрнең берсе асимметрияле федерация юлына басуга юнәлдерелгән. Татарстан инде күптән Россиянең федераль хөкүмәтенә карата булган мөнәсәбәтен үзе билгели һәм бу юридик яктан законлы. Россия Федерациясен төзегәндәге документларда язылганча, ул бүген федераль хөкүмәткә катнашыргамы, юкмы икәнлеген хәл итә. Әгәр дөньяның киң җәмәгатьчелеге, беренче нәүбәттә элеккеге союздаш республикалар, Россия белән Татарстан арасында гадел һәм ихласлыкка корылган мөнәсәбәтләр туүын күрсәләр, алар Россиягә булган мөнәсәбәтләрен үзгәртергә мөмкиннәр.

Татарстан Федератив килешүгә кул куймады. Суверен дәүләт буларак, ул Россия белән мөнәсәбәтләрен ике яклы килешүләр нигезендә корырга тели. Бу дөньяга яңгыраган ачык ният.

Шулай булгач, Татарстан Россия белән булган мө-

нәсәбәтләрен өзәмени? Шушы сорау белән безнең тиңкәгә тияләр. Безнең мөнәсәбәтләрне беркем дә, берничек тә өзә алмый. Ике якның да геополитик хәле үзгәрми. Татарстан һаман Россиянең республикалары һәм өлкәләре белән чиктәш булып кала. Ул һаман да тимер юллар аша Мәскәү ягына да, Себер ягына да йөри тора. Ул Идел буйлап аска да, өскә дә пароходларын җибәрә бирә. Боларның берсен дә үзгәртеп булмый бит.

Икътисади мөнәсәбәтләребез шундый ки, кендекләр бер-берсенә бик нык береккән. Әгәр дә аларны кисеп ала башласаң, ике якка да зарар килүе мөмкин. Рухи багланышлар исә тагын да тирәнрәк.

Без боларның һәммәсен дә искә алабыз. Без мөнәсәбәтләребезнең ныгуын телибез. Тик бер генә шартыбыз бар: тигез хокуклылык һәм гаделлек нигезендә.

Россиянең безнең җиребездәге һәммә нәрсәгә үзебезнең хуҗа булуыбызны тануы кирәк. Сездә булган мал сезнеке, бездәгесе — безнеке. Бергәләшеп шул милек-мөлкәтебезне уртак файдага җигик.

Шушыңа җавап итеп без нәрсә ишетәбез соң? Оятын югалткан сәясәтчеләр Татарстан кабул иткән Конституцияне Россия Конституциясенә тәңгәлләштермәкче булалар. Әгәр дә ризалашмасак, безне Россиянең Конституция судына тартмакчы булалар. Ләкин безнең максат билгеләнгән, чигенү юк. Конфронтация юлы белән бару Россиянең үзен дә ныгытмас. Әле кайчан гына М. Горбачев нәкъ шушындый ысуллар белән Балтыйк илләренең мөстәкыйльлеккә омтылышын бумакчы иде. Ул илләр бөтенләй диярлек Россия белән саубуллаштылар.

Шуларны күреп торган Б. Ельцин, автономияле республикалар белән мөнәсәбәтне болай катлауландырмаска вәгъдә итте. Татарстан һәм Башкортстанга карап, суверенитетны күпме телисез, шул кадәр алыгыз, дип белдерде. Ә инде бу ике республика моны чын-

чынлап тормышка ашыра башлагач, Ельцин тирәсендәгеләр, имеш, Президент аны уйлап бетермичә әйткән дип, вәгъдәдән баш тарта башладылар. Бу — Россия Президентының СССР Президенты ялгышларын кабатлавын исбатлый. Елена Боннэр да, телевидениедән чыгыш ясап, шул чагыштыруны китерде. Әлбәттә, милли мәсьәләдә Б. Ельцинның ике колагына ике төрле фикер тукып торалар. Шунлыктан аның сәясәтендә каршылыклар бик күп.

Шулай итеп, без бүгенге сәясәттә ике төрле тенденциянең үзара көрәш алып баруына шаһитбез. Кайсы юнәлеш җиңеп чыкса, Россиянең милли мәсьәләдә барыр юлын шул билгеләячәк.

Әгәр дә Ельцин Горбачев сабакларыннан дөрес нәтиҗә ясаса, Россия сәясәтчеләренең кайберәүләре тараткан коткыга бирелмәсә, Россия исән калыр. Әгәр дә инде тегеләр өстенлеккә чыкса, ул вакытта Россия бөтенләе белән таралачак. Аннан республикалар гына түгел, өлкәләр дә, крайлар да аерылып чыгачак. Чөнки бүгенге көндә диктат астында яшәүдән һәммә кеше дә туйган. Рус халкы үзе дә иреккә, гаделлеккә мохтаҗ.

Империя ул карап торуга гына зур күренә. Аның бит моннан зуррак чаклары да бар иде. Беренчеләрдән булып аның тырнагыннан Польша һәм Финляндия котылдылар. Хәзер инде безнең күз алдында Украина да китте. Ул гомумән акча берлеге зонасыннан да чыкты. Ә бит бу империя тарафдарларын уйландырырга тиешле факт. Киев рус шәһәрләренең анасы. Гомумән, Русьның башы Киевта. Әгәр дә шул баш китә икән, нәрсә кала соң? Әле бүген башка республикалар бәйсез саналсалар да, икътисади һәм акча берлеген якларлар. Ләкин аннан китәр юлларын да чамаламыйлар түгел. Хәтта Кыргызстан да, үз акчасын бастырып, иртәгесе көн өчен хәстәрен күреп куймакчы. Шушыны күреп торган Россия күршесе Татарстан белән мөнә-

сәбәтләрне гадел һәм дөрес оештырса, ул әкренләп республикаларның Россия тирәсенә кабат җыелуына нигез тудырыр иде. Россия өчен бу тарихи шанс. Монархы әле беркайчан да кара көчләрнең өстен калганы юк, Россиядә зирәк акыллы, реалистик сәясәтчеләр юк түгел. Ышанырга кирәк, аларның саны артыр. Шулай булса, безнең өметебез дә юкка чыкмас.

Бүген тарихи процессларның тизләнеш кичергән заманы. Көннәр елларга тора. Кайбер айлар, хәтта көннәр дә үз эченә елларны сыйдыра. Шунлыктан безгә көтәргә инде озак калмады. Күптән көткән азатлык инде ерак түгел. Азатлык шулай ук Россиянең үзе өчен дә яшәү шарты булып кала.

ӘЛЛӘ ШАТЛАНЫРГА, ӘЛЛӘ ОФТАНЫРГА?

Татарстанның яңа Конституциясе кабул ителде. Ә без ни эшләргә дә белмибез — әллә көләргә, әллә еларга. Бу Конституция турында төрле фикерләр бар. Әнә «Шәһри Казан» газетасында бер-бер артлы ике мөхтәрәм галимебез — Әгъдәс Борһанов белән Әбрар Кәримуллинның зур-зур мәкаләләре басылып чыкты. Алар икесе дә милләт турында зур кайгырту хисе белән сугарылган. Аларда Конституциябез турында тирән фикерләр тупланган. Бу очракта Төп Закон турында академик Әбрар Кәримуллин күбрәк яза. Дөресрәге, ул бөтен игътибарын шуңа юнәлтә. Шунлыктан мин мәкаләмне милләтебезнең йөзек кашларыннан саналган мөхтәрәм галимебезнең уйлануларына нигезләмәкче булам.

Баштан ук әйтеп куям, аның язган һәрбер сүзе халкыбыз, аның язмышы, теленең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылулар белән сугарылган. Гомер буе белемен, сәләтен халыкка хезмәт итүгә бирә килгән галимебезнең уй-фикерләренә игътибар итми калу мөмкин түгел. Укучылар минем бу язмамны аңа теләктәшлек

белдерүем итеп кабул итсеннәр иде. Галимнең газиз телебез язмышы өчен сыкрануын кем генә аңламас икән? Кем генә аның, теле бетсә, татар үзе дә бетә, дигән фикере белән килешмәс икән?

Мин бары тик Әбрар Кәримуллинның кирәгеннән артык төшенкелеккә бирелүен генә кабул итә алмыйм. Көрәшебезне ахырына кадәр җиткерү максаты белән аның уйлануларына бераз оптимизм рухы өстәүне үземнең бурычым итеп саныйм.

Татар теленең бердәнбер дәүләт теле итеп игълан ителмәгәнлегенә ризасызлык белдерә ул. Шулай ук милли телсез суверен дәүләт юк дип, мәсьәләне үтә катгый куйган ул, минемчә. Әйе, республикабызда Конституция нигезендә ике дәүләт теле кертелде. Тик бу бит суверенлык Декларациясе һәм Телләр турында закон кабул иткәч үк, әле Конституция барлыкка килгәнче хуп күрелгән иде. Конституция шушы принципны ныгытты, законлаштырды гына.

Тел мәсьәләсенең төрле илдә төрлечә куелуын онытмаска иде. Европаның һичкайчан да коллыкта калмаган илләрендә дәүләт телләре булып аларның үз халкы сөйләшкән телләре генә хезмәт итә. Тик үзенчәлекле тарихка ия булган Швейцариядә генә немец, француз һәм итальян телләре рәсми телләр булып санала. Ә инде кайчандыр коллыкта яшәп тә, инде бәйсезлеккәирешкән илләрдә хәл башкачарак тора. Әйтик, һәммәсе дә суверен булган Латин Америкасы илләрендә рәсми тел функциясен испан яки португал телләре үти. Гвинея-Бисауда, Анголада — португал, Зимбабве, Замбия һәм Нигериядә — инглиз, Нигерда, Заирда — француз телләре бердәнбер рәсми тел булып яши. Һиндстан һәм Пакистанда инглиз теле, һинди һәм урду телләре белән беррәттән, рәсми тел булып санала.

Әлбәттә, Татарстанда эш башкачарак. Безнең телебез махсус игътибарга лаек. Аны гамәлләштерү өчен махсус чаралар күрү кирәк. Тик менә телләрне гамәлгә кертү өчен законнар кабул итү генә җитми икән әле. Казагыстан, Кыргызстан республикаларында төп милләтнең телен дәүләт теле итеп игълан итү генә рус теленең рәсми тел булып яшәвен бетерә алмады.

Чыннан да, 70 проценттан артык халкы рус булган Бишкек яки Алма-Ата бүген-иртәгә генә җирле телдә сөйләшә башлармы икән?! Ә менә Үзбәкстан, Таҗикстан яки Украинада җирле халыкларның телләре инде чын-чынлап гамәлләшкән дисәң дә ярый. Чөнки бу илләрдә 70—80 процент халыкны төп милләт тәшкил итә. Әрмәнстанда халыкның 90 процентан артыгы — әрмән. Шунлыктан, табигый ки, дәүләт теле дә бер генә. Менә безгә дә телебезне саклау, аны чын мәгънәсендә дәүләт теле итү өчен татарның санын арттырырга, республикадагы демографик хәлне кискен үзгәртергә кирәк. Монда борчылырлык урын аз түгел. Татарның саны артмый, бер урында таптана бирә. Хәтта авылыбыз да бу эшкә хәлиткеч өлеш кертә алмый. Ә бит безгә миллионлаган яшь татарны үстереп, аңа милли тәрбия биреп, милләтебезнең яшәү нигезен ныгытырга кирәк.

Кызганычка каршы, без һаман халкыбызның җиде миллионлыгы белән мактанабыз. Чынбарлыкта исә, рәсми мәгълүматларга караганда, татарның саны җиде миллионга да тулмый. Әгәр дә инде тулып та, хәтта аннан бераз узып китсә дә, бу мактанырлык сан түгел. Безгә заманында үзбәкләр ясаган «демографик шартлау»ны булдыру зарур. Миллионлаган яңа татар телле халык дулкыны тел проблемасын чишәрдәй хәлиткеч көч булсын иде. Ә бүген исә татар милләтенең күпчелеген картлар һәм урта буын тәшкил итә. Әгәр

без милләтебезне яшәртүне, ишәйтүне махсус бурыч итеп куймасак, киләчәк торган яшь буынны милли рухлы һәм телле итмәсәк, киләчәгебез өметле булмас, милләтебезнең, дәүләтебезнең бөеклеге һәм шөһрәте әйләнеп кайтмас.

Бүгенге көннең мөмкинлекләренә килгәндә, без аларның булганыннан да тиешенчә файдалана белмибез әле. Әгәр һәммәбез дә дәррәү булып кабул ителгән Телләр турындагы законны тормышка ашыру эшенә керешсәк, трамвайда да, вокзалларда, дәүләт оешмаларында, уку йортларында да татар теле үзенең лаеклы урынын алыр иде. Телебезнең язмышы күп вакытта үзебездән тора икәнлеген онытмыйк.

Моның белән мин берәүне дә тынычландырасым килми. Мөхтәрәм Ә. Кәримуллинның телебез турындагы сыкранулары һәммәбезнең йөрәгенә үтеп керсен иде.

Ә. Кәримуллин, радикаль табигатьле шәхес буларак, бүгеннән үк Татарстанның бәйсез дәүләт булуын тели. Мин дә шуны телим. Ләкин мин шул ук вакытта моның иртәгә генә булмасын да яхшы беләм. Тик иртәгә түгел, ике-өч елдан моның шулай буласына иманым камил. Әгәр дә без аңлашып, кулга-кул тотынышып, акыл белән эш итәбез икән, бу шулай булыр да, шәт.

Бүгенге көндә Россия белән сөйләшүләр дәвам итә. Россия җитәкчелегендә безне аңларга тырышучылар юк түгел. Бу хәл соңгы сөйләшүләр вакытында да үзен яхшы ук сиздерде. Мәсәлән, каты куллы булуына да карамастан, Президент каршындагы дәүләт секретаре Г. Бурбулис, сөйләшүләр башланган 1991 елның 12 август көнендә үк, Татарстанның үз статусын күтәрергә омтылуын бик нигезле дип тапкан иде. Ә 1992 елның 3 августында Татарстанның вице-президенты В. Лихачев белән без икәүләп аның Кремльдәге кабинетында «бүленмәс һәм бердәм Россия» идеясенең ачыктан-ачык тарафдары В. Тишков белән алып барган бәхәс вакытында ул кабат Татарстан позициясен яклады. Россия

җитәкчеләреннән беренче буларак, ул Россиянең асимметрияле Федерация булу мөмкинлеген таныды.

Ул чакта каршы як, Татарстанның барлык гражданнары автоматик рәвештә Россия гражданы да булырга тиеш, дигән идеяне алга сөрде. Ә бу исә Татарстанны Россия составында калдыруга тиң. Ә инде шушы маддәгә кергән, Татарстан гражданнары Россия гражданлыгына да хаклы, дигән сүзләрдә реаль ситуациягә караганда сәяси эчтәлек күбрәк. Яшерен-батырын түгел, бүген халыкның шактый өлеше Россиядән чыгуны, аның гражданлыгын югалтуны авыр кабул итә. Сүз беренче чиратта референдумга катнашып, аның соравына «юк» дип җавап бирүчеләр турында бара. Ә алар 38 процентка якын.

Референдумда катнашмаган битарафлар күпме соң? Референдумда куелган сорау — Россиядән аерылу дигән сүз түгел, дигән аңлатмага таянып кына «әйе» диючеләрне дә искә алсак, мәсьәләнең шактый катлаулы булуын күрербез. Конституциянең шушы 23 маддәсе аларга, сез Россия гражданнары булырга да хокуклы, дип җавап бирә. Ә Россия гражданнары булырга теләмәгән кешеләргә бу маддә ничек җавап бирә? Җавап болайрак яңгырарга тиеш. Әгәр дә сез Россия гражданнары булырга теләмисез икән, рәхим итегез, шул хокукыгыздан баш тартыгыз. Чөнки бу маддә гражданлыкны саклау ирегеи бирә. Сүз нигездә ике гражданлык турында бара. Алай гына да түгел: нигездә ике гражданлыкның да тигез хокуклыгы раслана. Өлкән һәм кече суверенитет булмаган кебек, өлкән һәм кече гражданлык та булалмый.

Якын киләчәктә шушы маддә нигезендә гражданлык турында закон кабул ителергә тиеш. Анда ачыктан-ачык, Татарстан гражданнарының теләгәннәре ике гражданлык хокукы белән файдалана ала, дип әйтелергә тиеш. Шул ук вакытта ике гражданлык хокукына ия кешеләр Татарстанда яшәсәләр, алар тик безнең

дәүләтебез гражданнары гына булып исәпләнәләр. Ягъни Россия гражданнары буларак, аның Югары Советын, Президентын һәм башка органнарын сайлауда катнаша алмыйлар. Аларның Россия гражданлыклары резерв буларак саклана. Алар тик Россия җиренә чыккач кына шул дәүләт гражданлыгы хокукыннан файдалана алачаклар. Гомумән, моннан соң болай Татарстан бернинди Россия сайлауларында да катнашырга тиеш түгел. Конституциянең 23 нче маддәсендә шушы рәвештәге гражданлык принцибы теркәлсә, безнең бәйсезлегебез принцибы тантана итәчәк. Ләкин бу законны кабул иткән вакытта уяулык зур булырга тиеш. Аны Югары Совет аша үткәрү бәйсезлегебезне яклауга тиң икәнне онытмаска кирәк.

Хәзер инде 61 маддәне тикшереп карыйк. Баштан ук шуны әйтеп үтәргә кирәк. Югары Советтагы «Татарстан» төркеменең шушы маддә өчен эшләнгән варианты республиканы Россия составында калдыруга юнәлдерелгән иде. Никадәр матур киемгә киендерелгән булуына карамастан, анда Россия белән Татарстанның дәүләт бердәмлеге идеясе ята иде. Әгәр ул кабул ителгән булса, безнең моңарчы алып барган көрәшебез, шул өлкәдә ирешкән уңышларыбыз бөтенләе белән юкка чыккан булыр иде. Татарстанның Россия составында икәнлеге Конституция нигезендә танылыр иде. «Демократлар» бу вариантка аның «Татарстан» төркеме тарафыннан тәкъдим ителгәне өчен генә тавыш бирмәгәннәр булса кирәк. Югыйсә алар өчен моннан да әйбәт тәкъдимне уйлап чыгарып та булмас иде. Ярый әле аларны «Татарстан» төркеменә булган тискәре мөнәсәбәтләре сукырайтты.

Мин депутатларыбызны гаепләргә җыенмыйм. Шулай да алар уяурак булсыннар иде. Теләсә кем тәкъдименә, аның эчтәлегенә үтеп кермәстән, ризалашу моннан ары булмасын иде. Шул ук вакытта алар шуны сессиядәге кебек хәлиткеч моментларда бик тиз бер-

ләшә алу сыйфатларын да ныгытсыннар иде. Бу шулай булыр да. Чөнки депутатларның «Татарстан» төркемендә милләтебезнең, дәүләтебезнең чын патриотлары тупланган.

Президент М. Шәймиевнең килешү комиссиясе аша узган тәкъдиме кабул ителгәнлеге һәммәбезгә дә мәгълүм. Бу вариантта Татарстан — Россия белән бер-беренә хокуклар бирү турындагы ике яклы килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты диелгән. Моның соңгы ике өлеше халык тарафыннан йөз проценты белән кабул ителер дип уйларга кирәк. Бу, чыннан да, күпләрнең күңеленә хуш килде. Аны Әбрар Кәримуллин да шулай саный. Мин дә тулысынча аңа кушылам.

Әмма бу статьяның беренче өлеше конституцион норма түгел, Конституция ул бернинди килешүгә дә нигезләнми. Киресенчә, теге яки бу килешүләр үзләре шул Төп законга буйсынган рәвештә эшләнергә тиеш. Ләкин берни дә эшләп булмый, без парадокслар заманында яшибез. Компромисска барырга тырышу нигә генә китерми?! Гомер ишетелмәгән, гомер белмәгән нәрсәләргә тап булырга туры килә.

Шул ук вакытта хәзер илнең иминлеген тик компромиссларга таянып кына саклап калып булачак. Шуңа күрә безгә дә Конституциягә аның ише документларга хас булмаган нәрсә кертеп куярга туры килде. Әлеге ассоциацияләшкәнлек турындагы өстәмә ни рәвешле эшне боза соң?

Беренчедән, шуны онытмаска кирәк. Безнең үзебезне Россия белән ассоциацияләшкән дип игълан итүебез Россия моны таныды дигән сүз түгел. Чыннан да, ничек соң әле без, шушы мәсьәләдә бернинди килешү булмастан, аны Конституциягә язып куярга тиешбез? Ассоциацияләшкәнлек нормасын Конституциягә язып кую да безнең яктан бары тик шундый мөнәсәбәттә булырга теләгәнебезне Россиягә белдерү генә. Бу —

Россиягә ясалган конституцион тәкъдимебез. Россия моңа риза булмаска да мөмкин. Әлегәчә ул моңа теше-тырнагы белән каршы тора иде. Хәзер нишләр?

Инде ике вариантны да — Россиянең моңа ризалашкан, яки ризалашмаган очракларын тикшереп карыйк. Әйтик, Россия катгый рәвештә ассоциатив мөнәсәбәтләрдән баш тарта, ди. Ул вакытта сөйләшүләр алып барган делегация Югары Советка Татарстанның конституцион тәкъдиме үтмәгәнлеген хәбәр итә. Югары Совет ни эшләргә тиеш? Аның бердәнбер чарасы әлеге ассоциативлык бавын кисеп төшерү булып кала. Ягъни ассоциатив мөнәсәбәтләр турындагы сүзләр Конституциядән алып ташланырга тиеш була. Ул вакытта Татарстан бернинди шартсыз халыкара хокук субъекты булган суверен дәүләт була да кала.

Россия Татарстан тәкъдименә ризалашкан очракны тикшереп карыйк. Вакытлыча документның эчтәлеген читкә куеп торып, башта фактны тулы һәм бөтен рәвештә күзаллыйк. Һәрбер килешү нинди дә булса бер вакытка төзелә. Безнең очракка килгәндә, моңа кадәр сөйләшүләрдә катнашкан Россия делегациясе өч ел турында сүз алып барды. Нигә өч ел икәнлеген аңлау әллә ни авыр эш түгел. Россия җитәкчеләре, өч ел эчендә бары да үзгәрер, Россия ныгыр, аннан соң инде Татарстан белән башкача сөйләшергә мөмкин булыр, дип уйладылар. Уйлый бирсеннәр. Без исә, киресенчә, Татарстан ныгыр, чәчәк аткан дәүләт булыр, дип ышанабыз. Монда кемнең ничек уйлавы әһәмиятле түгел. Ике якны да әлегә билгеләнгән вакытның канәгатьләндерүе мөһим. Шушы вакыт үткәч, килешү яңартылырга тиеш була, бөтенләй икенче рәвешкә керәп, Конституциядән төшеп калырга да мөмкин. Бу шулай булыр дип ышанырга кирәк.

Хәзер инде ассоциацияләшкәнлекнең нәрсә икәнлеген тикшереп карыйк. Латинчадан тәрҗемә иткәндә, бу сүз союзлашканлыкны аңлата. Димәк, безнең Рос-

сия белән мөнәсәбәтләр союздашлык рәвешендә булырга мөмкин. Бу инде безнең үзара мөнәсәбәтләр Россиянең элеккеге союздаш республикалар, бүгенге бәйсез дәүләтләр белән булган мөнәсәбәтләренә караганда ныграк була дигән сүз.

Ни рәвештә союзлашып булыр иде икән? Берничә пункт буенча бәхәссез ризалашырга мөмкин. Ике дәүләт тә уртак икътисади һәм акча киңлегендә эш итәчәкләр. Бүгенге көндә бу сыйфат күпчелек БДБ дәүләтләренә хас. Бүгеннән үз акчаларын кертергә элеккеге күпчелек союздаш республикалар да әзер түгел. Киләчәктә исә, уртак икътисади киңлектә кала бирен, үз акчаңны кертергә дә мөмкин булыр иде. Бу юнәлештә эш алып бару бик кирәк булырга мөмкин. Чөнки безнең экономикабызның аякка басуы аркасында кибетләребездә товарлар ишәеп, аларның бәясе күршеләрнекеннән күпкә түбән булу сәбәпле малыбызның күршеләргә күчүе ихтимал. Шуларны булдырмау өчен һәр дәүләт үз акчасын кертергә мәҗбүр булачак. Безгә дә монда әзер булу зарур. Ә бүгенге чынбарлык исә әнә шул икътисади һәм акча киңлеге уртаклыгын таләп итә. Димәк, бу өлкәдә уртаклык булып, ул килешүгә керәчәк тә.

Билгеле булганча, безнең Россия белән уртак тимер, һава, су юлларыбыз бар. Без ни генә эшләсәк тә, үз өлешебезне кисеп ала алмаячакбыз. Безнең геополитик яктан урнашуыбыз шундый четерекле ки, без ул юллардан бары тик бергәләшеп кенә файдалана алачакбыз. Бу исә төрле инструкцияләрне, хәрәкәт тәртипләрен бер-берсенә ярарлык итеп төзүне таләп итә. Монда, һичшиксез, вәкаләтләр алмашып эш итү булырга тиеш.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтми булмастыр. Ул да булса, Татарстаннан читтә яшәгән татарларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү. Бу өлкәдә бергә эшләүдә Татарстан күбрәк кызыксыначак. Чөнки, ни ди-

сон дә, милләтебезнең күпчелеге үз ватаныннан читтә яши. Татарстан алар өчен милли мәктәпләр, дәреслекләр, төрле тармакларга багышланган китаплар һәм башка бик күп әсбаплар булдырырга тиеш. Шул ук вакытта республикабыздагы руслар өчен дә шундый ук ихтыяҗ бар икәнлеген онытырга ярамый. Аннан соң Татарстанда башка халык вәкилләре яшәгәнлеген дә истән чыгармыйк.

Менә шушы эшләрне эшләгәндә бер-береңә нинди дә булса вәкаләтләр тапшыру кирәк булыр микән? Кирәктер дип әйтергә мөмкин. Академик Әбрар Кәримуллин дөресләккә якын тора. Башка илләр практикасында әнә шундый үзара вәкаләтләр алмашу практикасы сирәк очрый. Ләкин бит күпчелек илләр арасында безнеке шикелле мөнәсәбәтләр дә юк. Без бит тарихта сирәк очрый торган хәлдә яшибез. Бик сирәк буыннар гына дәүләтләр, бигрәк тә империяләр җимерелгән чорда яши. Без исә нәкъ шундый чор кичерәбез. Безнең илебез 440 ел коллыкта яшәп, инде Россия кендегенә береккән. Әнә шуны аеру турында сүз бара. Гомумән, башта аерылышып, аннан бергә яшәү турында сүз бара.

Ә аерылышу җиңел түгел. Ул төрлечә була. Чехлар һәм словаклар кебек тыныч рәвештә аерылып була. Шул ук вакытта Югославиядәге кебек канга батарга да мөмкин. Аерылу бит ул — мал бүлү. Мал бүлүнең кайда җиңел булганы бар?

Шулай да безнең очрак кайсыдыр ягы белән Һиндстанның Бөекбританиядән аерылып чыккан чорын хәтерләтә. Һиндстан халкы баштарак доминион статусы дәгъвалады. Ә инде берничә елдан үзен тулы бәйсез дәүләт итеп игълан итте. Шушы уңайдан бер дәүләтнен икенчесенә вәкаләт биреп яшәгән очракларның берничәсен китереп китмәкче булам. Мәсәлән, Канада һәм Австралия, бәйсез дәүләтләр булуларына карамастан, үзләрен Халыкларның Британия Дуслыгы (берлеге) әгъзалары итеп саныйлар. Шунлыктан бу илләрдә

кабул ителгән кайбер карарлар, мәсәлән, үлемгә хөкем итү карарлары, бөтенләе белән хәл ителер өчен Англия королевасына раслау өчен җибәрелә.

Бу илләр чын мәгънәсендә бәйсез вә мөстәкыйль булуларына карамастан, аларның судлары хөкемне һаман да король исеменнән чыгара. Аларның хәрби көчләре, полицияләре, университетлары әнә шул корольлек атамасы белән йөри. Боларның күбесе бүген формаль атрибутика гына. Ләкин вакытында боларның берсе дә формаль түгел, ә реаль эчтәлеккә ия булган.

Шуңа күрә, минемчә, бүгенге көнне үзара вәкаләтләр алмашу котылгысыз мәҗбүрият булганлыктан, безгә дә аларга бүгеннән үк формаль эчтәлек кенә бирергә тырышырга кирәк. Бу эшнең реаль эчтәлеге исә бәйсезлек, мөстәкыйльлек булырга тиеш.

Шунысын онытмаска кирәк, империализм хакимиятеннән арыну бер актлы драма гына була алмый. Бу хәтта бүген инде формаль рәвештә бәйсез саналган элеккеге союздаш республикаларга да кагыла. Аларның күбесе инде үзләренең Россиядән башка яши алмаганлыкларын икърар итә. Чын бәйсезлек — безнең өчен генә түгел, алар өчен дә иртәгесе көн.

Академик Әбрар Кәримуллинның «Татарстан Конституциясе яки империя арбасына тагылган дегет чиләге турында уйланулар» исемле мәкаләсе файдалы һәм бик вакытлы икәнен әйтеп үтәсем килә. Ул безнең һәммәбезне дә уяулыкка өнди. Империализм хакимлегеннән инде котылдык, бәйсез дәүләт яулап алдык, инде эш бетте, дигән иллюзияләргә бирелмәскә чакыра. Чыннан да, империянең бетмәгәнлеген, аның тик кием генә алмаштырганлыгын без һич кенә дә онытырга тиеш түгел. Максатыбызның тулы бәйсезлеккә ирешү икәнлеген онытмыйк. Аңа ирешү өчен һәммә нәрсәгә дә әзер булырга кирәклеген истән чыгармыйк.

АҢЛАП ЭШ ИТҮ МӘСЛИХӘТ

«Татарстан Югары Советы ниндидер койрыгы кисελгән Конституция кабул итте. Димәк, Россия империясе шул килеш саклана.

Һаман да безнең үз Ватаныбыз юк. Татарстанга кайта алмыйбыз. Анда урысларны китереп тутырдылар. Татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә алмады (ике тел берьюлы дәүләт теле була алмый). Милләтебезнең киләчәге юк.

Суверенлык Декларациясен кабул итсә дә, бүген Татарстан Төрекмәнстан, Швейцария кебек мөстәкыйль дәүләт түгел. Урыс колонизаторлары үзләренең XII гасырдагы дәүләтләре территориясенә күчеп бетәргә тиешләр, чөнки башка төбәкләр алар тарафыннан басып алынды.

«Үзгәртеп кору» чорында Татарстан үзгәрмичә Россия тозагында торып калды. Ләкин замана үзгәрде, ахыры сез дигәнчә булмас...»

Камил Садриев,
Төрекмәнстан.

Әйе, татарларның күпчелеге, кайда яшәүләренә дә карамастан, үзләренең тарихи Ватаннарының бәйсез булуын тели. Татарстандагы хәлләрне бөтен татар күзәтеп тора дисәм, һич тә ялгышмамдыр.

Үткән елның 21 мартында үткәрелгән референдумның нәтиҗәсен Америкадагы, Австралия һәм Япониядәге, гомумән, дөньяга таралган һәрбер татар төннәрен йокламыйча көтеп торды. Бу факт милләтебезнең үзен бердәм хис итеп яшәвен күрсәтә. Төрле төбәкләрдән килгән хатлар да шул турыда сөйли. Димәк, бер үк идеяләр белән берләшеп яшәвебезгә нигез бар.

Татарстанның яңа Конституциясен бәяләгән хатлар да моңа дәлил булып тора. Татар кешесе, кайда яшәсә дә, үзен милләтнең бер өлеше итеп сизә. Дөресен әй-

тергә кирәк, Конституциягә караш бертөсле генә түгел. Аңа уңай бәя биргән хатлар күбрәк булса да, ризасызлык белдерүчеләр дә юк түгел. Менә Төрекмәнстаннан Камил Садриев әфәнденең хаты да шундыйрак. Хат авторын аңлап була. Ул Төрекмәнстанның бәйсез дәүләткә әверелүен, ә үз Ватанының юлы җиңел түгел икәнлеген аңлап яши, җаны-тәне белән Татарстанның да, Төрекмәнстан кебек үк, бәйсез булуын тели.

Моны бит без дә телибез, газиз милләттәшем. Без дә шуның өчен тырышабыз. Ләкин татар язмышы һәрвакыт башкача булып килде шул. Татар тарихы бай һәм катлаулы. Аллаһы тәгалә татарга камил акыл, зирәклек кенә түгел, шуларга өстәп ачы язмыш та биргән. Бәлки, ул шуның аркасында төрки дөньяда лидерлык дәрәҗәсенә җиткәндер. Бәлки, шунлыктан аның башкаларга да бирерлек акыл-сәләте барлыкка килгәндер, Төрекмәнстанга, Урта Азия республикаларына, гомумән, элек союздаш булган илләргә бәйсезлек куктән иңгәндәй иңде. Нәкъ менә шуның өчен безнең язмышны, тарихны башкаларныкы белән чагыштырып, офтанып яшәргә ярамый. Безнең халык һәрвакыт көрәштә, бу көрәш аның язмышыдыр. Әгәр дә Татарстан инде 1552 елда ук Россия кул астына күчеп, Татарстанда милләтебезнең тик чиреге генә яшәгәнен, аның үз җирендә тик 49 процент кына икәнлеген, Төрекмәнстанның исә 1860 елда гына Россия тарафыннан яуланып, анда бүген төп милләт 80 проценттан артык халыкны тәшкил иткәнен, аның төрле яктан Россия җирләре белән уратып алынмаганлыгын искә алсак, аерманың никадәр зур икәнлеген яхшы ук аңларбыз, дип уйлыйм. Шунысын да онытырга ярамый: безнең Конституция — ул милләтебез тарихында беренче мөстәкыйль дәүләт Конституциясе. Аны кабул итү бик авырлык белән барды. Гомумән, аны кабул итә алмау куркынычы да туды. Ләкин мөмкин булганның барысы

да эшләнде. Безнең шартлар өчен шуннан артыгын эшләп булмый иде.

Бездәге «демократлар» дип аталган «Народовластие» төркеме Конституцияне кабул иттермәс өчен барын да эшләде. Тик урамга корал гына күтәреп чыкмады. Монысына әле ул әзер түгел. Кем белә, бәлки, иртәгә алар моны эшләрләр дә. Уяурак булу безгә бер дә комачауламас, дип уйларга кирәк.

Әгәр дә безнең Конституция бернәрсәгә дә ярарлык түгел икән, ни өчен Россиянең Конституция комиссиясе секретаре О. Румянцев аны Россия Конституциясе белән тәңгәлләштерүне таләп итә?

Ни өчен ассоциацияләшүнең нәрсә икәнлеген аңлату өчен Татарстанга ике ай вакыт бирүне таләп итә? Чөнки алар безнең Конституцияне Татарстанның Россиядән чыгуы дип аңлыйлар. Татарстанның халыкара хокук субъекты икәнлеген Конституциягә язу, чыннан да, тулы мөстәкыйльлек билгесе. Бу безнең республикабызның, мөстәкыйль дәүләт буларак, теләсә кайсы ил белән, теләсә нинди мөнәсәбәтләргә керергә хаклы икәнлеге турында сөйли.

Әнә 1993 елның 2 гыйнварында «Аргументы и факты» газетасында басылып чыккан мәкаләне укып карагыз. Күрерсез анда безнең бәйсезлек дошманнарының ни рәвештә котырынуын. Алар Россиянең коммунистик лидерларын, «патриотик» оппозицияне Татарстанның Россия Федерациясеннән чыгуына бернинди реакция белдермәүдә гаеплиләр, Конституция суды белән яныйлар. Алай гына да түгел, Татарстанга карата көч куллануны таләп итәләр.

Менә шулай, Камил әфәнде, эшләрнең ничек торганлыгын сез инде беразтөшенә башладыгыз булса кирәк. Безгә бүген аек акыл белән сабырлык кирәк. Бу безнең халкыбызның гүзәл бер сыйфаты. Әгәр шушы сыйфатка ия булмасак, бездә дә Карабах яки Та-

җикстан барлыкка килер иде. Ә бит моның ише нәрсәдән куркырга кирәк.

Без бит, Камил әфәнде, Татарстанның үзендә гомер кичерәбез. Монда, бәйсезлек белән бергә, тотрыклылык һәм тынычлык тәэмин итәргә дә омтылабыз. Әгәр дә инде ирешкәннәргә риза булмасак, бүген ирешкән бәйсезлек дәрәҗәбезгә карата килешмәүчәнлек белдерә килсәк, бу эчке һәм тышкы бәйсезлегебезгә каршы эшләнгән көчләрнең тынычлыкны бозуына сәбәп булыр иде. Онытмыйк, шул сәбәпләрне махсус булдырырга тырышучылар да аз түгел. «Бердәм һәм бүленмәс Россия»не саклау һәм яклау өчен алар куллана алмаган чаралар юк.

Шунысын да әйтеп үтү кирәк: җәмәгатьчелекнең психологиясе үзгәрә тора. Әгәр дә ике ел элек халыкның, шул исәптән татарларның да, күпчелеге бәйсезлек төшенчәсен кабул итә алмаслык булса, бүген ул инде тиешле чирканчыкны алды. Хәзер тормыш үзе халыкның моңа каршы булган катлауларын да шуңа күндереп килә. Безнең бурыч — әнә шул массалар психологиясенә тиешле йогынты ясый белүдән тора. Монда да сабырлык кирәк. Ә сабырлыкның төбе сары алтын.

Юк, Камил әфәнде, безнең Конституциябез начар түгел. Аны чын мәгънәсендәге бәйсезлеккә ирешүнең коралы итәргә мөмкин. Һәм шуңа омтылырга да кирәк. Ничек дисезме? Әгәр көрәшебезнең бер этабы Конституция кабул итү белән тәмамланган булса, икенче этабы — аны гамәлгә кертү булырга тиеш. Гамәлгә кертүнең иң авыр һәм җаваплы бурычлары итеп түбәндәгеләрне күрсәтеп булыр иде: 1. Россия белән тигез хокуклы шартнамә төзү, аның белән ассоциатив мөнәсәбәтләр яки союздашлык урнаштыру; 2. Хокук саклау органнарын, шул исәптән Дәүләт иминлеге комитетын, тулысы белән Татарстан юрисдикциясенә күчерү; 3. Татарстанның бәйсезлеген, иминлеген саклау

чараларын кvру; 4. Һәрбер татарга һәм Татарстанда яшәүче күпчелек халык күңеленә хуш килердәй гражданлык турындагы Закон кабул итү; 5. Халыкара аренага чыгып, Татарстанның бәйсезлеген таныту.

Ләкин болар бәйсезлекнең Конституциягә кагылган урыннары гына. Ә аның һәркемгә дә күренми торган, ләкин һәркем тоеп яши торган өлеше бар. Ул да булса — икътисад. Татарстанның бәйсез дәүләт булып яшәрдәй икътисади мөмкинлекләре булырга тиеш. Мөмкинлекне билгеләгәндә, безнең фәлән кадәр нефтебез, фәлән кадәр завод, фабрикабыз бар дип кенә булмый бит. Боларның берсе дә тукланырга да, өскә киярга дә ярамый. Ә халыкны иң беренче чиратта шулар кызыксындыра. Ил башында торучылар булган байлыкны халык тормышын яхшырту өчен файдалануга җаваплылар.

Татарстан бәйсезлеге өчен җаваплы шәхесләр хата ясамыйча тормыйлар, билгеле. Бәлки, хаталар кирәгеннән артыграктыр да. Ә бит бәйсезлек өчен көрәш — ул Татарстанда яшәгәннәрнең генә эше булырга тиеш түгел. Без изге эшкә һәммә татарның өлеше керүен теләр идек.

Билгеле булганча, татар иле, татар халкы 1552 елдан бирле коллыкта яши. Безне чын мәгънәсендә кол итү өчен империя ни генә эшләмәгән. Ә бит бу 440 ел дәверендә дәвам иткән. Шушы коллыктан бүген тулысынча котылып буламы? Моны Президент һәм хөкүмәт үзләре генә башкарып чыга аламы? Бу сорауларның берсенә дә өздереп кенә җавап биреп булмый. Ул сораулар кем дә булса уйлаганга караганда катлаулырак. Ләкин шул ук вакытта аларга җавап юк, дип уйлау да хата булыр иде. Акыл көчебезне, халкыбызның барлык затлы сыйфатларын җигә белү кирәк безгә. Җигә белердәй шәхесләрне булдыру өчен кем җаваплы? Аларны кем һәм кайдан алырга тиеш? Бу сорауларга да җавап биреп була. Тик бер-береңне аңларга

тырышу, бер-берең‌ә карата түземлелек күрсәтә белү кирәк. Тарих безнең буынга күп гасырларга бер мәртәбә генә килә торган мөмкинлек бирде. Әгәр дә без аны чын мәгънәсендә файдаланыйк, милләтебезне коллыктан, илебезне мескенлектән чыгарыйк, дип карар кабул итәбез икән, бер тән, бер җан булып хәрәкәт итик. Бер-беребезгә төрле кушаматлар такмыйк. Кичәге партократлар бүген бәйсезлек эшенә җигелгәннәр икән, без моны хупларга гына тиеш. Шул ук вакытта элек-электән милләт язмышын кайгыртып килгән кайберәүләр бүген хата җибәрәләр икән, моңа да тиешле бәянә бирик. Кичәге эшләребезгә аркаланмыйк. Безнең бөтен көч киләчәккә юнәлтелгән булырга тиеш.

ТӨП ЗАКОНЫБЫЗНЫ ЯКЛАРГА ТИЕШБЕЗ

Башта бер сорауга ачыклык кертергә тырышып карыйк: Конституциягә карата безнең мөнәсәбәтебез нинди булырга тиеш?

Бәлки, бу сорау артык гадидер, башка илләрдә аны урынсыз дип санарлар иде, чөнки Конституция — илнең Төп Законы ул. Шуңа күрә аны ихтирам итәргә, һәр маддәсенә турылыклы булырга тиешлеге кешегә ана сөте белән сеңдерелә. Инде шулай икән, безгә дә үз Конституциябезне яшәү рәвешебезне билгели торган төп документ дип кабул итәргә кирәк.

Әмма безнең хәлебез башка илләрнекенә караганда күпкә катлаулырак. Татарстан әле чын мәгънәсендә бәйсез дәүләт түгел. Ул аңа таба беренче адымнарын гына атлый. Безнең әле һаман Россия карынынннан аерылып бетә алганыбыз юк. Татарстанның бәйсезлегенә каршы көчләр Конституциябезне баштан ук Россия Конституциясенә буйсындырырга тырыштылар. Һәм, әйтергә кирәк, азмы-күпме уңышка ирештеләр дә. Әйтик, гражданлык турындагы маддәне кабул итәр алдыннан безнең «демократлар» һәм алар коткысына

бирелгәннәр аны, проекттагыча үткәрмибез, дип ант иттеләр. Россия белән мөнәсәбәтләрне буйсыну рәвешендә билгеләүне үзләренә бурыч итеп куйдылар. Бу өлкәдә дә күпмедер уңышка ирештеләр. Дөрес, гражданлык мәсьәләсе Конституциядә язылганча әллә ни куркыныч тудырмый кебек. Бу маддә шундый итеп язылган ки, аны үз файдабызга да, безнең бәйсезлекне җимерү максаты белән дә кулланырга мөмкин.

Әгәр дә ике гражданлылык принцибын туры мәгънәсендә таныйбыз икән, без Россия һәм Татарстан гражданнары булып саналачакбыз. Бу бер караганда начар түгел. Чөнки Россия белән мөнәсәбәтләребез шулкадәр тыгыз ки, безгә анда чыгып яки аның аша үтеп йөргән чакта бу ил гражданнары булу файдалы гына.

Ике гражданлылык безнең шартларыбызда бик мөмкин нәрсә. Әмма моның өчен шушы хакта Россия белән килешүгә ирешүебез кирәк. Бу очракта Россиядә яшәгән милләттәшләребез дә үзләрен Татарстан гражданнары итеп рәсмиләштерә алырлар иде. Әлеге килешүдә һәр ике республикада үз гражданлыкларының өстенлеге каралган булырга тиеш. Шул ук вакытта монда бернинди мәҗбүрилеккә урын булмасын. Әгәр кирәк дип тапса, Татарстан кешесе Россия гражданлыгын кабул итәргә дә хаклы. Аны бу хокукыннан берәү дә мәхрүм итә алмаячак.

Кабатлап әйтәсем килә, ике гражданлылыкның төп шарты шуннан гыйбарәт: һәр республикада аның үз законнары тулысы белән өстенлек итәргә тиеш. Югыйсә, безнең кемнәрдер куйган тозакка килеп эләгүебез бик мөмкин.

Ә Россия законнары өстенлек итсә? Бу Россия армиясендә мәҗбүри рәвештә хезмәт итү, Россия Югары Советын, Россия Президентын сайлауларда катнашу дигән сүз. Кайберәүләр, катнашса ни дә, катнашмаса ни, моның нинди зарары бар, дип әйтерләр. Ләкин бө-

тен бәла шунда ки, син ул депутатларны, гомумән, Югары Советны һәм Президентны Орел һәм Новгород өлкәләре белән идарә итү өчен генә сайламыйсың, сайлагансың икән, рәхим итеп Президентына да, Югары Советына да буйсын. Менә шуның белән инде Татарстан законнарының өстенлеге юкка чыга. Ә бит законнар өстенлеге — бәйсезлекнең нигез ташы. Менә шуңа күрә дә Конституциябезне гамәлгә ашыру йөзеннән кабул ителергә тиешле Гражданлык турындагы законда бу принципның салынган булуы мәҗбүри таләп булып кала.

Закон Татарстан кешесенә ике гражданлылыкны көчләп такмаска тиеш. Конституция безнең әнә шул ике гражданлылык хокукына ия икәнебезне генә бәян итә. Әгәр мин шушы хокукка ия икәнмен, димәк, мин аның хуҗасы. Шулай булгач, мин Россия гражданлыгыннан баш тарта да алам. Кемдер әйтер, алай булгач, без Татарстан гражданлыгыннан да баш тартырга хаклы, дияр. Монысы да дөрес. Теләүчеләр бар икән, рәхим итсеннәр. Тик моның белән алар үз хәлләрен генә авырлаштыралар. Беренчедән, мондыйлар Татарстанда яшәгән килеш, Россия гражданлыгының файдасын да күрмичә, Россия армиясенә хезмәткә алынырга мөмкиннәр. Икенчедән, аларга Россия хөкүмәте билгеләгән кайбер салымнарны да түләргә туры килмәгәе. Гомумән, бу кешеләр үзләрен Татарстанда үз илләрендә яшәгән кебек сизмәячәкләр. Алай гына да түгел, низаг чыгып, эше судка китсә, алар хәтта Россия судларына да мөрәҗәгать итә алмаячаклар.

Боларны аңлау өчен Россия составындагы республикалар хәленә күз салу да җитә. Аларда да ике гражданлылык кабул ителгән. Әмма Россия гражданлыгы андагы кешеләргә мәҗбүри рәвештә тагылган. Алай гына да түгел, Россия гражданлыгы өстен итеп куелган. Бу республикалар сүздә үз законнарының өстенлеген игълан иткән булсалар да, нигездә алар Россия

законнарына буйсынып яшәргә мәҗбүрләр. Россия гражданнары буларак, андагы кешеләр Россия армиясендә дә хезмәт итә, Президентны да, Югары Советны да сайлый. Һәм шуның белән үз законнарының өстенлеген юкка чыгара.

Без икенче юл эзлибез. Әлбәттә, Россия белән аңлашып. Без үзебез һәм Россия өчен дә уңай булган тигезлек шартлары булдыруны күздә тотарга тиешбез.

Идеалда исә ике гражданлылык демократиянең якты чагылышы булырга тиеш. Ул һәр кешегә дә үзен чын мәгънәсендә ирекле итеп тоярга, шулай яшәү мөмкинлекләрен тудырырга тиеш. Татарстан да, башка бәйсез илләр кебек үк, үз гражданлыгының өстенлеген, закон рәвешендә билгеләп, бәхәссез приоритетка әверелдерергә тиеш. Башка илләрнең гражданлыгы бездә яшәргә хаклы. Тик хакимлек итү рәвешендә түгел, ә гражданнарның хокукларын тулыландыру, баету юнәлешендә.

Бүгенге көндә без берәүгә дә гражданлыкны көчләп тагарга хаклы түгелбез. Әгәр инде кем дә булса Татарстанда торган килеш тик Россия яки Япония гражданы булып кына яшәргә тели икән, яши бирсен. Әмма бу очракта ул җирле сәясәттә катнаша алмаячак. Кыскасы, гражданнар үз язмышларын үзләре хәл итәргә тиеш.

Шунда кемнең кем икәнлеге күренер, Татарстан патриотымы ул яки битараф бер адәмме? Бүген исә бездәге «демократлар» да үзләрен Татарстанның патриотлары итеп күрсәтмәкче булалар. Бу, чыннан да, шулай микән соң? Әлеге сорауга җавап бирү авыр түгел. Алар Татарстан Конституциясенә каршы чыгалар, О. Румянцев арбасына утырып, шуның җырын җырлыйлар. Ә бит Румянцев Татарстан Конституциясен законсыз дип саный һәм аны Россия Конституциясе белән тәңгәлләштерүне таләп итә.

Бу нәрсә дигән сүз? Бу Россия законнарының өстенлеген тану дигән сүз. Ә бит шул ук «демократ» депутатлар безнең суверенлыгыбыз турындагы Декларациягә бердәм тавыш бирделәр, алар кергән Югары Совет О. Румянцевның соравын кире кага торган Конституцияне кабул итте һәм ул Татарстанның Төп Законына әйләнде. Закон исә һәммә кеше өчен дә мәҗбүри. Әллә соң безнең демократлар Конституциягә буйсынмый гына яшәмәкче булалармы? Әгәр дә буйсынырга теләмиләр икән, икенең берсе — яки алар Татарстан гражданлыгыннан баш тартырга, шуның белән безнең законнарның үзләренә карата мәҗбүрилегеннән котылырга һәм, әлбәттә, безнең сәясәттән читтә булырга тиешләр. Ә инде Конституциягә каршы чыкканнары, Татарстаннан читтә союзниклар эзләп, төрле рәвештәге блоклар төзеп, үз республикаларына каршы көрәшкәннәре — суд җаваплылыгына тартылсыннар.

Безнең халык сабыр һәм түземле. Мондый башбаштаклыклары өчен бүтән җирләрдә алар инде әллә кайчан тиешле җәзаларын алган булырлар иде. Чыннан да, әнә Молдованы алыгыз, яки Балтыйк буендагы илләрдә булып үткән хәлләрне исегезгә төшерегез. Алардагы ыгы-зыгылар нәкъ шундый ялган демократларның кыланышлары аркасында килеп чыкты бит. Андагы халык мондый оятсызлыкларга түзеп тора алмады. Бәлки, бу шулай булырга тиештер дә.

Түземлелек турында сүз алып барганда мин, әлбәттә, татарларны гына күздә тотмыйм. Мин монда безнең белән гомер бакый бергә яшәгән урысларны да истә тотам. Алар да безнең кебек үк сабыр һәм түземле. Алар да безнең шикелле үк үз җирләренең патриотлары. Чуваш, мари, мукшы, яһүдләр дә шулай. Хәер, бу бөтен җирдә дә шулайдыр. Әнә Якут-Саханы гына карагыз. Анда да шушы җирдә борынгыдан ук яшәгән урыслар, якутлар белән бергә, Саханың бәйсезлеге өчен көрәшәләр. Аларга да кемнең дә булса диктаты инде ка-

булып итэлерлек норма түгел. Саханың Гражданлык турындагы закон проектында, республика гражданнары булып Сахада 15 елдан да ким яшәмәгән кешеләр генә санала, диелүе тикмәгә генә түгел. Моны шундагы урыслар хуплый, бу алар мәнфәгатенә дә туры килә. Чөнки зур акчага кызыгып килүчеләр Саха халкына гына түгел, җирле урысларга да куркыныч тудырдылар. Килмешәкләр Сахадагы вазгыятьне кискенләштерүгә сәбәпче булып торалар. Чыннан да, ничек инде ул акча эшләргә килгән кешеләр, үзләренә баерга мөмкинлек биргән республика халкына каршы чыгарга тиешләр? Нишләп соң әле алар, Саханың язмышын хәл итеп, аннары берни булмагандай, үзләренең кайдадыр җылы яктагы куышларына кайтып китәргә тиеш?

Безгә дә моны искә алырга кирәк. Республикабызда барлы-юклы 5-10 ел яшәгән кешеләр, илебезне юньләп белмәгән бәндәләр ничек инде монда хөкем сөрергә тиеш?! Әгәр, чыннан да, Татарстан патриоты буласың килә икән, төп халыкның монда гомер бакый яшәгән кешеләрнең психологиясен, эчке кичерешләрен аңларга тырыш. Әгәр дә җирле сәясәткә катнашасың килә икән, моны намусың саф булса гына эшлә. Ә читтә яшәгәннәрне дә республикага каршы оештырырга ниятлисең икән, синң карата сүзне халык үзе өздереп әйтер.

Михайлов дигән берәү, Татарстан халык депутаты булуына да карамастан, инде шактый вакытлардан бирле республикабызга каршы эш йөртә. Юк, мин Югары Совет сессияләрендәге чыгышларын гына истә тотмыйм. Ул чыгышларга депутатлар бәя бирсеннәр. Мин аның парламенттан тыш алып барган эшләрен, сәясәтен күз алдында тотам. Бервакыт ул «Советская Татария» газетасында, Татарстан экспериментлар аренасына әйләнде, дип язып чыкты. Имеш, Татарстан җитәкчеләре Татарстанда нindидер экспериментлар алып баралар. Баксаң, ул Татарстанның мөстәкыйль дәүләт булырга омтылуын күздә тота икән. Анынча, Россия җитәкче-

ләре экспериментатор түгел, ә Шәймиев эше шикле икән, Ельцин турында бер сүз юк. Әйтерсең лә, Россиянең суверенлыгы турындагы Декларация Ельцин инициативасы белән кабул ителмәгән. Әйе, «чын» экспериментлар бездә түгел, Россиядә үткәрелә. Кем базар икътисадына белер-белмәс килеш чумды? Кем бер кеше дә аңламаслык ниндидер ваучерлар кертте? Кем Россияне хәерчелеккә, бөлгенлеккә төшерде? Менә кайда ул «экспериментаторлар». Ярый, хуш, ялгышу булгандыр. Кем ялгышмый бу заманда. Ә менә Татарстанның былтыр гыйнвар аенда Россия белән алып барган сөйләшүләрендә Михайловның астыртынлык күрсәтүен ничек аңларга? Сөйләшүләр нәтиҗәләрен Татарстан делегациясенең аргументлары җитмәү белән аңлатырга нинди нигез бар иде?

Беренчедән, бу кешенең үз делегациясенә, үз җитәкчелеге позициясенә, кабул ителгән Конституциягә каршы чыгарга бернинди хакы юк. Икенчедән, сөйләшүләрнең ни рәвештә барганын да, анда нинди максат куелганын да белми бит әле ул. Шулай да аның үз туксаны туксан. Ул үзен Татарстан гражданы дип хис итми, үзе яшәгән республиканы Россиянең «бүленмәс бер өлеше» итеп кенә таный һәм шулай дип уйлаучылар белән берләшә. Әгәр дә ул Грузиядә яшәсә, ниндирәк позициядә торган булыр иде икән? Әле күптән түгел генә Грузия дә СССРның бүленмәс өлеше дип танылa иде ич. Әгәр дә Михайлов Грузиядә яшәп, шундый фикерләрне алга сөрсә, аны ничегрәк бәяләрләр иде икән? Түзеп торырлар идеме икән?!

Чыннан да, инде кабул ителгән Конституциягә каршы көрәшергә ярыймы? Аны күңелең белән кабул итмәскә мөмкин, ләкин каршы чыгарга хаклы түгелсең. Конституцияне тәнкыйтьләргә ярыймы? Ярый. Җитешсезлекләре турында әңгәмә уздыру да ярый. Болар барысы да законга сыя. Алай гына да түгел, үзен чын мәгънәсендә гражданин итеп хис иткән кеше хәтта мо-

ңа бурычлы. Әнә, Михайлов һәрвакыт тәнкыйтьләп килгән Фәүзия ханым Бәйрамованы алыгыз. Ул да, Михайлов кебек ук, Конституциянең берничә принципиаль маддәсе белән риза түгел. Шулай да ул аны яклап тавыш бирде. Әмма моның белән эш бетте дип санамады. Ул үзе риза булмаган маддәләрне тәнкыйтьләвен дәвам итә. Кешеләргә үзенең хаклыгын исбат итмәкче була, шуның белән ул киләчәктә Конституциягә тиешле үзгәрешләр кертү өчен җирлек әзерли. Тик бу эшчәнлекнең кайберәүләр алып барган җимерү эше белән чагыштырганда зур аермасы бар. Фәүзия ханым Конституциягә буйсынып яши, шул нигездә ул Ватанының бәйсезлеге өчен көрәшен дәвам иттерә. Әлеге мисал башкаларга да гыйбрәт булырлык. Бу исә Конституцияне, аның бәйсезлеккә юнәлгән позицияләрен яклауга тиң.

Әлбәттә, бүген Конституциягә мәдхия генә җырлап яшәүчеләр дә бар. Мондыйларның бер өлеше ихлас күңелдән эш итә. Чөнки алар бу документны Татарстан тарихында беренче Конституция итеп кабул итәләр. Алар аның нечкәлекләренә кермиләр һәм керә дә алмыйлар. Болар хис кешеләре. Андыйлар да булсын. Икенче төрлеләре дә бар. Алары СССР яки РСФСР Конституцияләреннән күчерелгән документларга да мәдхия җырлый килделәр. Бу — аларның үзләштергән һөнәре. Яраклашып яшәү — аларның фигыле.

Беренчеләре куркыныч түгел, әмма икенчеләреннән сак булырга кирәк. Җил кайсы яктан иссә, алар шул якка борылырга әзер. Бүген безнең Конституцияне яклап чыксалар да, моңа ышанып бетәргә ярамый. Бу халык намуссыз — иблис токымыннан.

Әйе, газиз Ватаныбызның үз Конституциясе барлыкка килде. Ләкин әле бу бәйсезлеккә ирештек дигән сүз түгел. Әлеге документны бәйсезлек өчен көрәштә корал итеп кенә кулланырга мөмкин. Шул ук вакытта аны мөстәкыйльлеккә каршы көрәш коралы итеп фай-

даланырга тырышкан көчләр барын да истән чыгарырга ярамый.

Без 440 ел буена коллыкта яшәдек. Явыз Иван «оҗмахка тиң җир» («подрайская землица») дип атаган илебезне кире татарларга кайтарып бирү нияте белән басып алмагандыр. Аннан соң хөкем сөргән патшалар да безне коллыкның иң түбән баскычына төшерергә тырышканнар. Безнең җиребезне, дәүләтебезне яулап алу гына түгел, рухыбызны да сындырырга омтылганнар. Бу сәясәт гасырлар дәвамында үткәреләкилгән. Шуңа күрә безнең азатлыкка, бәйсезлеккә бару юлыбыз да чиксез авыр. Мәскәү дәүләте безне таптап үтеп, Төньякка да, Көньякка да, Көнчыгышка да — меңәрләгән чакрымнарга кереп урнашкан. Аның аңына безне бөтенләй йотып бетердек, дигән ышаныч кереп утырган. Шунлыктан без әнә шул ялгыш фикерне какшатырга, кешеләргә дөреслекне аңлатырга тиешбез.

Безнең көрәш арсеналыбыз баеганнан байый бара. Башта суверенлык Декларациясе кабул иттек, аннан соң Референдум үткәреп, анда җиңеп чыктык. Инде хәзер Конституциябез дә бар. Боларның барысын да бәйсезлек өчен көрәштә мөмкин кадәр тулырак файдаланасы иде. Моны эшләп була. Тик үзара аңлашу, булган акылыбызны, батырлыгыбызны нәтиҗәле эшкә җигә белү генә кирәк.

СОҢГЫ СҮЗ — ХАЛЫКНЫКЫ

«Идеология» дигән сүз безнең колакны ерта. Без аны күбрәк ялганга, икейөзлелеккә корылган коммунистик идеология белән тиңлибез. Чыннан да, коммунизм төзү максаты тарихи утопия булганлыктан, аңа ирешүгә юнәлдерелгән идеология дә зур корбаннар китерүгә сәбәп булды. Мондый идеологияне алга сөргән чорда ил һәм халык фаҗигагә дучар ителә.

Димәк, идеологиянең дөреслеген куелган максатның

хаклыгы билгели. Шул ук вакытта максат элеге идеологиянең үзәген дә тәшкил итә. Тик реаль максат һәм реаль бурычлар куя алырдай идеология генә яшәргә хаклы дисәк, һич тә ялгышмабыз, дип уйлыйм. Без бәйсезлек идеологиясенә менә шул фикердән чыгып якын килик.

Коллык чорында йотылып бетмичә сакланып калган һәрбер милләт өчен азатлык — тарихи перспектива булып кала. Әгәр дә этнос, яуланганнан соң, хаким милләт тарафыннан юк ителгән яки аңа сеңеп юкка чыккан икән, аның өчен бәйсезлек тарихи перспектива булудан туктый. Ә җаны сакланганнар исә барыбер уяна. Каршылык күрсәтә. Көрәшнең шул чор өчен мөмкин булган формаларын сайлый. Татар халкы тарихында полковник Бәхтияр Канкаев җитәкчелегендәге көрәшне, татар һәм башкортны азатлыкка өндәгән Батырша восстаниесен исегезгә төшерегез. Татарлар һәм башкортларның Степан Разин, Емельян Пугачев восстаниеләрендә актив катнашуы да социаль тигезсезлеккә каршы күтәрелү генә түгел, милли азатлыкка омтылу күренеше дә иде. Ләкин бу әле — империянең үсешкә, күтәрелешкә барган чоры. Ул вакытта җиңүгә ирешү өчен бернинди мөмкинлек булмый.

Ләкин дөнья тарихында әле бер генә империянең дә мәңге яшәгәне юк. Ал. Македонский, Рим империяләре һич таркалмас кебек күренгәннәр. Римның үзен «мәңгелек шәһәр», дип атаганнар. Дистәләрчә халыкларның котын алып, бастырып торган ул империяләр кая соң? Чыңгыз, Бату ханнар төзегән дәүләтләр дә таралып юкка чыккан. Хәер, нигә соң шул кадәр ерак заманнарга китәргә? Әле бит кайчан гына Лондондагы империя тарафдарлары «Британия империясе өстендә беркайчан да кояш батмый», дип мактаналар иде. Ә Лондон шәһәренең мэрына көн саен көндезге сәгать уникедә була торган төшлеккә империянең иң ерак илләреннән китерелгән ташбакадан аш пешерә торган булган-

нар. Бүген инде төшлеккә ташбака ашы пешерү дә, Бөекбритания империясе үзе дә юк. Голландия, Франция колониаль империяләре дә шулай ук чәлпәрәмә килеп юкка чыкты. Тик бер империя генә һаман исән кала бирде. Дөрес, ул инде 1917 елда ук юкка чыгарга тиеш иде. Тик большевиклар аның гомерен 74 елга озынайттылар. Хәзер менә аның соңгы сәгате сукты. Без аның үлем сулышын тоеп яшибез. Элек тә империяләр җимерелгән вакытта, кол хәлендә, азатлыкка омтылып яшәгән халыкларның ирек өчен көрәштә үз идеологияләре барлыкка килгән.

Әлбәттә, идеология хәрәкәт башланган чакта ук бөтен тулылыгы белән гәүдәләнми, аның әле тик төп контурлары гына билгеләнә. Гаделсезлеккә каршы һөҗүм кыяр-кыймас кына башлана, тора-бара ул көчәя. Берниндиди каршылыктан да курыкмый башлый. Әйтик, Һиндстандагы азатлык хәрәкәте башлангыч чорында үз иле өчен доминион (үзе идарә итә торган колония) статусы алуны күздә тоткан иде. Ә соңрак тулы бәйсезлек идеологиясе барлыкка килде.

Африка илләрендә дә баштарак колониаль статуска ризасызлык, аларның хокукларын киңәйтү хәрәкәте генә кузгалды, аннан ул бәйсезлек яулау идеологиясе рәвешенә керде. Моның аерата ачык мисалы — Алжир. Аларда илнең статусын күтәрү идеологиясе азатлык, тулы бәйсезлек идеологиясенә әверелде.

Әгәр СССР тарихына күз ташласак, монда да шул ук хәлне күрербез. Аның тарихы, башыннан ахырына кадәр, СССРга кергән республикалар һәм халыкларның үз статусларын күтәрү өчен көрәшеннән гыйбарәт. Дөрес, баштарак аның төпле бер идеологиясе булды дип әйтеп булмый. Булса да ул идән астында яшерен рәвештә яшәде. Әйтик 20 елларда Грузиядә Мдивани группасы. Украинада Раковский, Казагыстанда Рыскулов тарафдарлары, Татарстан белән Башкортстанда «солтангалиевчеләр» СССРдан чыгуны максат

итеп куймыйлар. Алар тик республикаларның статусын үзгәртү өчен генә көрәшәләр. Чөнки барысы да инде Россия империясе бетте, Советлар Союзы — халыкларга ирек китергән ил булырга тиеш, дигән өмет белән яши. Ләкин ялгышалар. Ил тагын явызлык империясенә әйләнеп, дөньяга шом сала. Республикаларның статусы күтәрелү генә түгел, киресенчә, елдан-ел төшә бара. Аларның кайберләре бөтенләй үк бетерелә, ә халыклары сөрелә. Менә шушы ялгышлар статус күтәрү идеологиясенең тулы бәйсезлек, азатлык идеологиясенә әверелүенә китерә.

Тарих шуны раслый: метрополияләр беркайчан да үзләре теләп колонияләренә ирек бирмиләр. Алар үз империяләрен сакларга соңгы чиккәчә тырышалар. Англиянең мәшһүр премьер-министры Уинстон Черчилль: «Мин Британия империясен таркатуда рәислек кылу өчен королеваның премьер-министры булмадым»,— дигән. Ләкин ни эшләмәк кирәк, тарих законнары Черчилль кебек бөек кешеләрдән дә көчлерәк. Черчилльгә, теләсә-теләмәсә дә, шушы процесста рәислек кылуны башлап җибәрергә туры килде. Франция Президенты мәрхүм Шарль де Голльнең дә башта Алжирның Франция колониаль империясендәге статусын күтәрүгә риза буласы килмәде. Ләкин, прогрессив караштагы шәхес буларак, соңыннан аңа Алжирның тулы бәйсезлеге белән килешергә туры килде.

Метрополияләр колонияләрнең статусларын күтәрүгә, аларның хокукларын арттыруга никадәр ныграк каршылык күрсәтсәләр, статус күтәрү идеологиясе шулкадәр тизрәк бәйсезлек идеологиясенә әверелә. Хәтерегездәме: безнең Татарстан да эшне үзенең статусын күтәрү өчен көрәштән башлады. Моның үз идеологиясе барлыкка килде. Аның башы Мирсәет Солтангалиевнең СССР төзелгәндә үк, аңа Шәрекъ республикаларының, шул исәптән Татарстан һәм Башкортстанның да, яңа дәүләтне төзүчеләр сыйфатында, тулы хокуклы респуб-

лика рәвешендә керергә тиешлегең яклаган чыгышларында, Сталин белән алып барган бәхәсләрендә чагылды. Солтангалиев репрессияләнгәннән соң Татарстанның статусын күтәрү идеологиясе, нигездә, яшерен рәвештә үстерелә. Ә инде 1936 елда, СССРның яңа Конституциясе кабул ителгән вакытта, ул тышка калкып чыга. Эчтә яшерелеп, ачыктан-ачык әйтелергә мөмкин булмаган идея илгә мәгълүм була. Сталин үзенең чыгышында бу идеядән көлә генә. «Татарстан белән Башкортстанның союздаш республика булуы аларның төшләренә генә керергә мөмкин»,— ди. Залдагы куштаннар аңа кушылып көлешәләр, сүзләрен хуплап, аяк döбердәтеп кул чабалар.

Ләкин нинди генә хурлаулар, янаулар күрмәсен, Татарстанның хокукларын күтәрү, статусын үзгәртү идеясе юкка чыкмый. Ул халык арасында таралып, аның йөрәгендә яши бирә. Сталин үлгәч, Хрущев заманында ул зыялылар тарафыннан кабат тикшерелә башлый. Шушы проблема буенча төрле фикерләр туа, арада бәйсезлек турында хыял да була. Анысы империянең барыбер бетәчәгенә инанган кешеләр күңелендә яши. Ләкин әле СССРның, демократик дәүләткә әверелеп, халыкларның җәберләнүе, төрле сортларга бүленүе бетәчәгенә ышаныч зур булмаганлыктан, бәйсезлек идеясе яралгы рәвешендә үз вакыты җиткәнне көтеп ята. Брежнев Конституциясе кабул ителер алдыннан, Татарстанны союздаш республикага әверелдерү идеяләре, төрле яктан яңартылып, Конституция комиссиясенә дә барып ирешә. Шундый тәкъдимнәр белән хәтта башка милләт вәкилләре дә чыгалар. Алар Татарстанның автономия статусы белән генә яшәве гаделсезлек күренеше икәнлеген аңлап эш итәләр. Чөнки шул 60 нчы елларда ук, Татарстан, Башкортстан гына түгел, Абхазия, Тува, Якутия һәм кайбер башка автономияләр дә азатлыкка сусаганлыкларын күрсәтеп, үз

статусларын күтәрү өчен көрәшне инде башлаган булалар.

Яңарыш чорына кергәч, яңа союз договоры булдыру идеясе тормышка аша башлагач, Татарстан инде һич курыкмастан бу шартнамәгә башка союздаш республикалар белән беррәттән тигез хокуклы булып кул куячагын әйтте. Бу мәсьәләнең шундый гади юл белән хәл ителмәвенә Татарстан гаепле түгел, СССР таркалды һәм Татарстанга үз статусын күтәрүнең яңа юлын эзләргә туры килде.

1990 елның 30 августында кабул ителгән дәүләт суверенитеты турындагы Декларация шушы позициянең җиңеп чыгуына киң юл ачты. Бу очракта шунысын да әйтеп китәргә кирәк. Әлеге документны әзерләү һәм кабул итү вакытында Татарстанның Россия субъекты икәнлеген күрсәтү фикере шактый киң таралган иде. Хәтта, беренче вариант буларак, Декларациянең тексты шул рәвешчә басылып та чыккан иде. Күрәсең, Аллаһе тәгалә безне инде тулы азатлык юлына күндергән булгандыр. Россия субъектлыгы идеясе үтмәде. Декларациядә Татарстанның суверен дәүләт икәнлеге теркәлде. Әгәр дә Декларациядә Татарстан Россия Федерациясе субъекты итеп күрсәтелгән булса, Россия составына беркайчан да үз теләге белән кермәгән дәүләтебез, 439 ел үткәч, анда ирекле рәвештә кергән булып чыгар иде.

Без мөстәкыйльлекне үз тәвәккәллегебез, халкыбыз фатихасы белән кыенлыклар аша яулап барабыз. Ә моңарчы союздашлык статусында булган республикалар бернинди көрәшсез-нисез бәйсез дәүләтләргә әверелделәр дә куйдылар. Бәйсезлек, азатлык аларга күктән инде. Моңа без шатланып, ул дәүләтләрнең халыкларына ак юл телибез. Ә безнең алда озак һәм катлаулы көрәш юлы тора әле. Чөнки бүген инде статусны күтәрү — бәйсезлеккә ирешү дигән сүз. Моңа бернинди альтернатива да булырга мөмкин түгел. Туып килә тор-

ган бәйсезлек идеологиясендә бу ачыктан-ачык күрсәтелергә тиеш.

Беркем дә азатлыкның куктән иңәчәгенә исәп тотарга тиеш түгел. 1552 елны урыслар «үтә горур патшалык» («прегордое царство») дип атаган Казан ханлыгын яулап алганда аны, яңадан алтын тәлинкәгә салып, кире кайтарып бирү өчен яуламаганнар. Илбасарлар үзләре әйткәнчә шушы «ожмахка тиң җирләр» мәңгеләштерү, тулысынча йотып, үзләштерү максаты белән яуланган. Россиянең бүгенге хуҗалары да бу мәсьәләдә фикерләрен үзгәртмәгән. Шуны истә тотып, безнең идеология азатлык өчен барган көрәшнең барлык ысулларын кулланырга әзер булуыбызны чагылдырырга тиеш. Әгәр дә без, Россия белән сөйләшүләр бик яхшы бара, башка бернинди чаралар күрүне дә күздә тоту кирәк түгел, дисәк, бигрәк тә халкыбызны шуңа ышандырсак, ул уяулыгын югалтачак. Һәм дә шуның белән зур хата җибәргән булабыз.

* * *

Бу юлда нәрсә эшләнде дә, нәрсә эшләнергә тиеш? Татарстан, кәгазьдә генә булса да, автономияле республикадан суверен дәүләткә әверелде. Бүгенге көндә, шул документларга таянып, Россия һәм башка дәүләтләр алдына Татарстанның бәйсез дәүләт булырга хаклы икәнлеге исбат ителде. Референдум үткәрелеп, бәйсезлекнең юридик нигезе ныгытылды.

Шушы дәүләтчелекнең көченә таянган хәлдә икътисади мөстәкыйльлек булдыру өчен берничә әһәмиятле адым ясалды. Россиянең экономика министры А. Нечаев кебекләрнең тартышуына да карамастан, Россия Татарстандагы милекнең фәкать аның үзенеке икәнлеген таныды. Ниһаять, күп каршылыкларны үтеп, аның үз Конституциясе кабул ителде.

Ләкин Югары Советның әле законнар чыгару һәм

шуның аша суверенитетны ныгыту хокукыннан тулысынча файдаланганы юк. Әйтик, Татарстан чын дәүләткә әверелсен өчен, аның үз-үзен яклардай реаль көчләре булуы мәслихәт. Иң беренчесе — тик үзенә генә буйсынган хокук органнары булуы шарт. Сүз прокуратура, юстиция, милиция һәм мәхкәмә (суд) органнары турында бара. Бу органнары башка дәүләткә буйсынган очракта республика һич кенә дә суверен һәм мөстәкыйль дәүләткә әйләнә алмый.

Шулай ук республиканың үз хәрби көчләре булу да мәслихәт. Татарстанга бирәү дә янамый, нигә аңа хәрби көчләр, дип әйтүчеләр бар. Ләкин монда шуны онытмаска кирәк. Республикабыз халыкара аренада нейтраль статуслы дәүләт сыйфатында танылганчы, аның үз-үзен саклау гарантиясе буларак, үз гаскәре оешырга тиеш. Хәтта, нейтраль дәүләткә әверелсә дә, аңа эчке куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен көчле милиция частьлары кирәк булыр.

Экономикада мөстәкыйльлекне ныгыту өчен Татарстанның үз налог һәм бюджет системасын барлыкка китерүе дә мәҗбүри. Аның бу хокуклары танылды инде. Аны тормышка ашырасы гына калды. Безнең әле бәйсезлекне яклау өчен файдаланып җиткерелмәгән башка мөмкинлекләребез дә шактый. Аларның барысын да эшкә җигәргә кирәк. Дөрес, кайбер урыннарга кереп оялаган суверенитетка каршы көчләр моңа һәрдаим каршылык күрсәтәчәкләр. Алар хокук саклау органнарында да байтак. Шуңлыктан аларның эшчәнлеге хөкүмәт кенә түгел, җәмәгатьчелек контроле астында тотылудан, мөстәкыйльлекне ныгытуда Татарстан — Россия сөйләшүләрен файдалана белүдән дә күп нәрсәләр тора.

Бу сөйләшүләр Россиядән ни дә булса теләнү рәвешендә алып барылмасын иде. Халкыбызның табигый хокукларын каршы якка танытырга кирәкле барлык юридик нормалар бар. Әгәр дә сөйләшүләр шул

рәвешчә барып, уңышлы тәмамланса, без бәйсезлекнең тыныч юллар белән алырга мөмкин булган 95—98 процент өлешенә ирешә алачакбыз. Билгеле ки, бәйсезлек идеологиясен тормышка ашырганда хөкүмәтнең, җитәкчеләрнең генә түгел, халыкның да үз урыны бар. Беренчедән, халыкның оешканлыгы, бердәмлеге барлык эшләрнең, шул исәптән Россия белән барган сөйләшүләрнең уңыш гарантиясе икәнлеген дә онытырга ярамый. Татарстан ягы, үз җилкәсендә халкының сулышын тоеп, аның бу эштә зур таяныч икәнен сизеп хәрәкәт итсә генә уңышка ирешәчәк. Моны өстәлнең теге ягында утыручы кешеләрнең дә аңлавы кирәк. Алар сөйләшүләр алып баручыларның үз фикерләрен генә түгел, ә халыкның омтылышын җиткерүләрен күрә торсалар, файдадан гайре берни дә булмас.

Әйе, Мәскәү белән сөйләшүләргә халык үзе бармый. Ләкин шушы процесска төп юнәлешне бары тик ул гына бирә ала. Халыкның шушы мөмкинлекләрен барлау, аңа юнәлеш бирү — иҗтимагый оешмаларның эше. Бу зур эш. Аны юлбашчылыкка омтылган теләсә кем булдыра алмый. Юлбашчы бүгенге көн, митинглар, лозунглар белән генә яшәргә тиеш түгел. Лидер запас юлланы күреп, резерв булдырып эш итәргә тиеш. Аның сәяси культурасы, зәвыгы һәм әхлагы да тел-теш тидермәслек булсын, җитәкчеләрнең үз идеяләре белән яшьләрне рухландыра алуы аеруча игътибарга лаек. Чөнки яшьләр, беренчедән, җәмгыятьнең иң актив өлеше булсалар, икенче яктан, алар яшәешнең барлык сфераларында төп көч булып катнашалар. Шуңа күрә аларның бәйсезлек идеологиясе белән кызыксынуы, аңа хезмәт итүе милли хәрәкәтнең дәвамлы булуын тәэмин итә. Тик шунысын гына онытырга ярамый, яшьләрнең ышанычы белән шаяру һич гафу ителми. Аларны үзеңә буйсындырырга тырышу — сантыйлык. Яшьләр — мөстәкыйль көч. Элеккеге комсомол әнә шул мөстәкыйльлеген югалту аркасында яшьләр арасында абруен

югалтты. Ул партия карарларын үтәү коралына әйләнде, сүлпәнләнде һәм, гомумән, бу оешма максатсыз калды. Хаталарны кабатлауны тарих кичерми. Әгәр безнең яшьләр мөстәкыйль көч булып оешырга телиләр икән, әгәр дә үзләренең дөньякүләм ассоциацияләрен булдырырга уйлаганнар икән, аларга булышлык күрсәтү — безнең бурыч. Яшьләрнең оешулары никадәр нәтиҗәле булса, бәйсезлек өчен көрәш тә шул дәрәҗәдә уңышлы барыр, дип ышанырга кирәк. Шулай ук хатын-кызлар оешмалары да мөстәкыйльлекне ныгытуда шактый зур басым ясый алалар. Тарихтан татар хатын-кызларының дәүләт тормышында да, гаилә тормышында да шактый йогынтылы көчкә ия булуын беләбез. Татар хатын-кызларының бөтендөнья ассоциациясе туып килә, һәм ул шушы юнәлештә эшләр дип ышаныйк. Болар белән беррәттән, зыялыларның мөмкинлеген дә истән чыгармаска иде. Хәзер безнең белгечләр кайсы илләргә генә чыкмыйлар да, нинди максатларны гына тормышка ашырмыйлар. Әгәр алар профессиональ ассоциацияләр төзеп, Татарстанның бәйсезлеге идеясен дөньяга таратуны бурыч итеп алсалар, республикага зур файда китерерләр иде. Нәкъ менә шундый оешманы журналистлар да бик рәхәтләнеп оештыра алырлар иде. Ул һич кенә дә Татарстан журналистлар берлеген алыштырмас. Киресенчә, алар бер-берсенә өстәмә генә булачак. Ә мондый халыкара оешманың кирәклеген, референдум алдыннан информацион блокада да калдырып, безгә инде бик ачык төшендереп бирделәр.

Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә үзебезнең эшмәкәрләрне берләштерүгә бер адым ясалган иде. Хәзер аларның эшчәнлеген чит ил инвестицияләрен, яңа технологияләрне Татарстанга китерү юнәлешендә алып барырга иде.

Күптән түгел татар табиблары үзләренең оешмасын булдырды. Юристлар да, башка һөнәр ияләре дә, аларны үрнәк итеп, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгы-

туга төрле яклап хезмәт итә алалар. Чөнки суверенитет халыкның барлык катлауларына үтеп керсен өчен, аның һәркемгә аңлаешлы булуы, конкрет идеяләрдән торуы кирәк. Чынлыкта идеология өлкәсендә соңгы сүзне һәрвакыт халык үзе әйтәчәк. Димәк, азатлык, бәйсезлек өчен көрәштә дә соңгы сүз аныкы булачак. Ул сүзнең нинди булуы исә халыкка әлеге идеологияне җиткерә, аның нәтиҗәләрен күрсәтә белүдән тора.

ӨЛКӘН ҺӘМ КЕЧЕ СУВЕРЕНЛЫК БУЛАМЫ?

Татарстан Россиядән чыгамы?

Әле Татарстан белән Россия арасында килешүгә кул куелмаган, аның төп тексты әле ике як тарафыннан да кабул ителмәгән. Ә инде кемнәрдер бу документны тудырмаска, аңа кул куюны булдырмаска тырышалар. «Известия» газетасының 1992 ел, 17 сентябрь санында политолог Харичевның «Татарстан хотел бы совместить несовместимое: выйти из России и остаться в ней» дип аталган мәкаләсе дөнья күрде.

Мондый язманың шушы киң танылган газета битләрендә басылып чыгуы, бер яктан сәер булса, икенче яктан — куркыныч та. Сәерлеге шунда, мәкаләнең авторы делегацияләрнең кайчандыр эш вариантларының берсе булып саналган, кемнеңдер рәсми булмаган төзәтмәләре кертелгән, һичкем кул куймаган документка таянып эш итә. Шунлыктан бу кешегә мондый документны кем һәм ни өчен биргән? дигән сорау туа. Безнең Татарстан делегациясе ягыннан мондый эш белән шөгыльләнүчеләр юк. Чөнки без сөйләшүләр барышында конфеденциальлек принциплары сакланырга тиеш икәнне яхшы беләбез. Хәер, бу эшнең мәкерле максат белән эшләнгәненә шикләнергә туры килми. Аның хәтәр ягы шунда, мәкаләнең авторы киң җәмәгатьчелек-

не Татарстан һәм Россия арасында килешүгә каршы күтәрмәкче булган, ә бит бу уен эш түгел. Аның массаларда бөекмәмләкәтчелек тойгылары уятып, милләтара тынычлыкны бозуга сәбәп булуы ихтимал.

Харичевка ышансаң, имештер, Татарстан ягы Россиядән чыкмыйбыз дип, алдый гына икән. Договор тексты үзе исә киресен, Татарстанның Россиядән чыгуын раслый.

Безнең өчен мондый алымнар яңалык түгел. Без хәтта газетада бу идеянең кемнән чыкканын да әйтә алыр идек. Хәер, вакыты җиткәч әйтербез, анысы бездән тормас.

1991 елның 12—15 августында Россия һәм Татарстан делегацияләре сөйләшү өстәле артына утыргач, С. Шахрай һәм аннан ике көнгә соңгарып килгән С. Станкевич: «Әйтегезче, сез Россиядән чыгасызмы, әллә чыкмыйсызмы?» — дип, теңкәгә тигәннәр иде. Инде елдан артык дәвам иткән сөйләшүләр нәтиҗәсендә бу сорауны тулысы белән ачыкладык, дип уйлап, ялгышканбыз икән. Моңа, бәлки, Г. Бурбулисның: инде мондый сорауларны куеп, бер-беребезнең теңкәсенә тигәнче, кул куярга тиешле килешүнең фактик эчтәлеге өстендә эшләргә кирәк, дип әйтүе сәбәп булгандыр. Бәлки, бу бер-беребезне аңлап эш итүгә кирәгеннән артык ышанудан чыккан хатадыр.

Шулай да баштан ук бер нәрсәне кисәтеп китү кирәк. Без сөйләшүләр дәверендә үзебезнең делегация составының тотрыклы булуын билгеләп үтәргә тиешбездер. Президентыбыз бу мәсьәләдә һәрвакыт принципиаль позициядә торды. Ә. Россия делегациясенең составы һаман үзгәрә килде. Шунлыктан без очрашкан саен «Сез Россиядән чыгасызмы-юкмы?» дигән сорауга өр-яңадан җавап биреп, ул җавапны кат-кат исбатларга мәҗбүр була идек. Тик менә соңгы очрашуларда инде андый сорау яңгырамый башлады.

Инде моны хәл иттек дигәндә, генә, күрәсез, «Изве-

стия» газетасы битләрендә яңадан шушы сорау күтәрелә.

Сез инде, хөрмәтле укучылар, яхшы аңлыйсыздыр: бу кешеләр безнең җавапка бөтенләй мохтаҗ түгел. Аларга шул сорауны кую һәм үзләре куйган сорауга үз җавапларын бирү әһәмиятлерәк. Ә максат шул ук: Россия җәмәгатьчелегендә, Татарстан Россиянең бердәмлеген җимерә, аны бөтенләе белән юк итәргә омтыла, дигән фикерне таратып, Россия белән Татарстан арасында тигез хокуклы шартнамәгә ничек булса да кул куйдырмау.

Ни өчен бу ысул кулланыла соң? Монда бер чагыштырмага тукталып үтү кирәктер. Әле шушы көннәрдә генә Б. Ельцинның Япониягә визиты, срогын да билгеләмичә, кичектерелде. Моны «рус идеясе» белән сөремләнгән төркем үзенең җиңүе дип игълан итәргә ашыкты. Моңа җавап итеп, Россия президенты каршындагы дәүләт секретаре Г. Бурбулис: әгәр шулай дип уйлыйсылары килә икән, уйлый бирсеннәр, диде. Имештер, Б. Ельцин Япониягә барып, анда Россия исеменнән Япониягә дүрт бәхәсле утрауны бирә. Россия җәмәгатьчелеге исә, әнә шул төркем тарафыннан күтәрелеп, бу мәкерле планны юкка чыгара.

Әлбәттә, ничек инде кемгәдер Россиянең бердәмлеген җимерергә рөхсәт ителсен, ди? Татарстан очрагында, сүз ниндидер дүрт кечкенә утрау турында гына түгел, ә Россиянең үзәгендә утырган бай җир турында бара. Моңа юл куелырга тиеш түгел! Янәсе, не позволим! монда кайчандыр Дәүләт думасында яңгыраган «Прочь мелкота, Русь идет» сүзләренә яңгыраш авазлар ишетелә. Әйе, ачыктан-ачык ишетелә.

Әнә шул «рус идеясе» белән исергән даирәләр: инде тәҗрибәбез бар, дип уйлыйлар. Б. Ельцинны Япониягә барып «утраулар сату» планыннан баш тартырга мәҗбүр иттек, Татарстанның да Россиядән чыгу планнарын таркатырбыз, дип хыялланалар.

Кайчак бу хәлләргә шаклар катасың. Бу кешеләр тарих дигән нәрсәне бер дә белмиләр микәнни? Россия бит ул төрле заманда төрлечә булган. Аның башланган җире Киев — инде бөтенләй Россия түгел. Мәскәүдән көньякка таба булган җирләрдә угрофиннар яшәгән. Мурома, Яхрома, Кострома һәм башка атамалар — угрофин сүзләре. Новгород, Нижний Новгород атамалары да бу җирләрнең руслар өчен яңа җирләр булганлыгын раслый.

Юк, мин инде күптән руслар белән тулган, төп халыклары инде юкка чыккан җирләрне элеккеге хуҗаларына кайтарырга кирәк димим. Моның белән мин тик Россиянең территориаль яктан һәрвакыт үзгәрә барганлыгын гына әйтәсем килә. Мәсәлән, аңа 1917 елга кадәр Польша һәм Финляндия дә керә иде. Бүген исә элеккеге Көнчыгыш Пруссия, Калининград өлкәсе булып, аның бер өлешен тәшкил итә. Бер үк вакытта кайчандыр Төркестан, Украина, Белоруссия, Кавказ арты да шулай ук Россияне тәшкил итә иде. Бүген исә болар һәммәсе дә инде тарихта калды.

Нәкъ шуңа күрә «бердәм һәм бүленмәс Россия» идеясен алга сөргән кешеләр һәрвакыт оттырып килделәр. Кадетлар партиясе лидеры П. Н. Милюков үлем түшәгенә ятар алдыннан: «Безне әнә шул — бердәм һәм бүленмәс Россия идеясе харап итте»,— дигән.

Ә инде Татарстанга килсәк, аның үз тарихы бар. Ул шөһрәтле дәүләт буларак, Россия карыныннан тумаган. Аның язмышы шушы империя булырга омтылган ил тарафыннан яулап алынуы нәтиҗәсендә кискен үзгәргән. Гасырлар буе ил булып яшәгән татар җирләре шул империянең провинциясенә әверелгән.

Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары Россиягә иреклe рәвештә кермәгән. Татар халкы үзенең коллыгына беркайчан да риза булмаган, һәрвакыт азатлыгын яңадан кайтару уе белән яшәгән.

Шуның өчен бүген: «Татарстан Россиядән чыгамыни?» — дигән сорауга: «Аның беркайчан да Россиягә ирекле рәвештә кергәне юк», — дигән җавап кына булырга мөмкин. Кермәгән җирдән ничек чыгарга мөмкин соң?

Миңа бервакыт: «Гафу итәсез, алай булгач, сез ничек Россия эчендә калдыгыз соң?» — дигән сорау белән мөрәҗәгать иттеләр. Күрәсең, белмиләрдер. Без Россиягә кермәдек, безне яулап алганнар бит.

«Татарстан хәбәрләре» газетасының 17 сентябрь (1992) санындагы язмамда мин Россия Федерациясен игълан иткән документларның безнең өчен нинди әһәмияткә ия икәнлеген әйткән идем инде. Бүген Совет хөкүмәтенең 1917 елның ноябрендә басылып чыккан «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»нә тукталып үтәсем килә. Бу документта иске Россиянең «халыклар төрмәсе» булганлыгы икърар ителеп, моннан соң шул халыкларның тигез хокуклы һәм суверен, яки бәйсез икәнлекләре игълан ителә. Димәк, бу халыклардан колониаль яки яуланып алынган халыклар статусының алынып ташланганлыгы юридик рәвештә таныла. Аларның яулап алыну нәтиҗәләре юкка чыгарыла. Шулай булгач, алар формаль рәвештә инде Россия составында булмый. Менә ни өчен Совет хөкүмәте, шушы мәҗбүри адымга барганнан соң, бер үк вакытта Россия таркалып бетмәсен өчен, ашыгыч рәвештә аны Федерация итеп корырга керешә.

Чыннан да, юридик яктан ирекле һәм азат дип танылган халыкларның, үзләренең бәйсез дәүләтләрен төзеп, Россияне таркатулары мөмкин түгелме соң? Шуңа күрә дә инде әле субъектлары да барлыкка килмәгән килеш III Бөтенроссия Советлар съезды Россияне Федератив дәүләт итеп үзгәртә. Аннан соң туачак республикалар инде Россия карынында туарга тиеш булалар. Әле бер генә Федерациянең дә бу кадәр мәкер-

ле рәвештә туганы булмый. Шулай да III Бөтенроссия съезды да, формаль рәвештә булса да, халыкларның иреклелеген таный. Федерация ирекле рәвештә төзелгән халыклар союзы итеп билгеләнә. Бу принцип Федерацияне төзегән документларда ачык чагылган. Большевиклар изелгән халыкларның азатлыгы өчен көрәшүчеләр булып күренергә тырышсалар да, чынбарлыкта исә «бердәм һәм бүленмәс Россия»нең тарафдарлары булып калдылар. Алай гына түгел, алар Россия империясенең гомерен тагын 72 елга озайттылар. Бүгенге «рус идеясе» тарафдарлары аларны каһәрләргә түгел, киресенчә, аларга табынырга тиешләр.

Революция елларында, гомумән, совет чорында формаль юридик нәрсәләргә игътибар юк иде, әлбәттә. Ул елларны хокукый законнар түгел, ә революцион законнар өстенлеге хөкем сөрде. Шунлыктан большевиклар кәгазьгә нинди дә булса формаль юридик нормалар язудан курыкмадылар. Алар халыкларга да кәгазьдә — ирек, ә чынбарлыкта — төрмә шартларын саклый килделәр.

Үзләрен ирекле дип игълан иткән халыкларны үзбилгеләнү хокукыннан мәхрүм итү фактлары бик күп. Менә аларның берничәсе генә. Суверен дәүләт итеп корылган Украинага кызыл гаскәр бәреп кереп, 1918 елның гыйнварында Киевны ала. Үз хәлләрен үзе хәл итәргә тырышкан Төркестан автономиясен игълан иткәч, аның хөкүмәте куып таратыла. 1917 елның 16 ноябрендә игълан ителгән Башкортстан республикасы, тик башкорт гаскәре Советлар ягына күчкәннән соң, 1919 елның мартында гына рәсми рәвештә танылa. Ләкин берничә ай эчендә ике хөкүмәт арасында төзелгән шартнамә большевиклар тарафыннан юк ителә. Башкортстанда террор режимы урнаштырыла. НКВД коллегиясе әгъзасы, Урал большевикларының берсе Б. М. Эльцин Башкортстанны бөтенләе белән юк итү мәсьәләсен күтәреп чыга.

Татарлар Идел-Урал штатын игълан итәр алдыннан Мәскәү, аларның арасына чөй кагып, бу идеяне алдап-йолдап Татар-Башкорт республикасы проекты белән алыштыра. Бу республиканы да төзетмиләр. Монысы инде татар һәм башкорт халыклары арасына чөй кагу юлы белән эшләнә. Соңрак Татарстанны төзегәндә, 1,5 млн. татар яшәгән җирләрне Татарстанга кертми калдырып, аларны Башкортстанга кушып, өтек территорияле Татарстан төзелә. СССР төзелгәндә исә Татарстан да, ирекле җөмһүрият буларак, анда СССРны төзүчеләрнең берсе булып керергә ниятләгәч, бу идея тарафдарлары, аларның күренеклесе мәшһүр Мирсәет Солтангалиев репрессиягә эләгәләр. Бу башбаштаклык, һичнинди нормалар белән санлашмауның мисалы түгелмени? Ә соңрак, репрессияләр котырынып, алар дәүләтнең яшәү рәвешенә әверелеп киткәч, дистәләрчә халыклар бөтенләе белән репрессиягә эләгеп сөрелделәр. Шул вакыттагы гаделсезлекне әле бүген дә танымаска тырышулар күзәтелми мени? Әнә газиз кардәшләребез — Кырым татарларының язмышына күз салыгыз. Аларның җирләрендә бүген бөтенләй башка кешеләр, җирле халыкның үзбилгеләнү хокукын үз файдаларына җигеп, автономияле республика игълан иттеләр. Инде хәзер, гомумән, бәйсез дәүләт игълан итмәкче булалар. Әмма үзләрен «демократ» дип атаган берәү дә Кырым татарларының хокукын якларга җыенмый.

Әйе, мисал китерүне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Ләкин чикләнергә туры килә. Мин бу фактларны тик бүген идарәче даирәләрнең хокукый дәүләт төзибез дип шапырынуларына җавап итеп кенә китердем.

Юк, мин хокукый дәүләт идеясен хуплыйм. Аңа һич каршы килмим. Тик бу идеянең дә әнә шул кәгазь демократиясенә генә әверелеп калуыннан куркам.

Безгә һәрвакыт «андый куркыныч юк», дип әйтә киләләр. Шулай булгач, әйдәгез, Россия Федерациясе тө-

зелгән замандагы, шул вакытта халыкларның тик кәгазьдә генә калган тигезлек һәм суверенлык законнарын танығыз. Әгәр дә сез, чыннан да, демократлар һәм хокукый дәүләт тарафдарлары икәнсез, «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»н, «Россия республикасының федераль учреждениеләре» резолюциясен танығыз. Совет хөкүмәтенең Россия һәм чит ил мөселманнарына мөрәҗәгатен яңадан бер кат укыгыз. Укыгыз да, үз вакытында юлбашчыларыгыз вәгъдә иткән ирекләрне мөселман халыкларына бирегез! Мөселман халыкларының әллә кайчан танылган табигый хокукларын инде 74 елдан соң булса да тормышка ашырыгыз! Менә шунда инде үзегезнең хокукый дәүләт тарафдарлары икәнегезне, демократлар икәнегезне исбат итә алырсыз.

Дөрес, Харичев Татарстанның Россиядән чыгу хокукы бар, дип яза. Тик, аныңча, моның өчен яңадан референдум үткәрү кирәк икән. Аныңча, 1992 елның 21 мартында үткәрелгән референдум моңа нигез була алмый икән. Сез, Харичев әфәнде, Россиянең Конституция суды рәисе В. Зорькинның Югары Советта референдум буенча ясаган чыгышын укыгыз. Анда ул референдумның шуңа нигез икәнлеген ачынып сөйли. Алай гына да түгел, аны һәр юрист шулай аңларга тиеш, ди. Моның шулай икәнен Татарстанның демократик реформалар хәрәкәте дә таныды.

Сез «Татарстан Россияне алдый, ул аны тарката», дип каравыл кычкырмагыз! Киресенчә, сез Россияне алдыйсыз! Татарстанның изге тойгыларын, азатлыкка, гаделлеккә омтылышын әнә шулай бозып күрсәтергә тырышучы — сез!

Татарстан китә, имеш...

Россиянең газета-журналлары, радиосы һәм телевидениесе: «Татарстан Россиядән китә»,— дип күп язды, күп сөйләде. Референдум алдыннан картадагы

Татарстан урыны шартлаган, аның урынында ниндидер кара бушлык хасил булган ямьсез плакат та бастырып чыгарылды. Юкса татар зыялылары инде күптән, халык тойгыларын чагылдырып: «Без китмибез!» — дип әйтеләр бит. Хәзер без кабат: «Китмибез!» — дип әйтәбез.

Без тик үз җиребезнең, үз илебезнең, үз Ватаныбызның Россия белән тигез хокуклылыгын, ике дәүләтнең мөнәсәбәтләре иреклелек принцибында булуын гына телибез. Без Россиягә аерылуны түгел, тигезлеккә корылган союзны тәкъдим итәбез.

Россиядә һәрвакыт аек фикерле, ихлас күңелле демократлар була килде. Иншалла, шушы тарихи яктан авыр булган чорда да анда аек акыллы кешеләр, халыклар дуслыгы һәм тигезлеге тарафдарлары табылыр. Россия бит ул Харичевлардан гына тормый. Ул, чын мәгънәсендә бөек дәүләт буларак, үз халкының изге һәм гадел тойгыларын бүгенге максатларга җигә алыр, дип ышанабыз. Бу аның һәлакәттән котылуына бердәнбер чара. «Татарстан Россиядән чыгамы?» — дигән сорауга безнең җавап менә шул рәвештәрәк булырга тиеш.

Татарстан Россия белән нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? Бу сорауга бик кыска итеп җавап бирергә дә мөмкин булыр иде. Әгәр дә без ул мөнәсәбәтләр тигез һәм гадел булырга тиеш дисәк, һич тә ялгышмабыз. Ләкин инде киң җәмәгатьчелек күптән шушы җавапның тулылануын таләп итә, аның төп принципларын булдыруны тели. Нәкъ менә шуңа җавап йөзеннән әлеге мөнәсәбәтләрнең ике яклы тигез хокуклылык принцибына корылган шартнамәгә нигезләнгән булуы алга сөрелә. Бу идея инде ике елга якын, төрле киртәләрне җимереп, үзенә юл сала. Әгәр дә без шушы шартнамәне булдыруда барлык җәмәгатьчелек катнаша дисәк, һич тә ялгышмыйбыз. Чөнки радио-телевидение, газета-журналлар көн саен диярлек Россия белән булырга тиеш-

ле мөнәсәбәтләргә багышланган чыгышлар, материаллар биреп киләләр.

Килер бер көн, тарихчылар әлеге материалларны тикшереп, бу хакта тулырак сүз әйтерләр. Ләкин инде бүген, фикер каршылыклары булуга да карамастан, бер фикернең уртак икәнлеге ачыкланды. Ул — безнең Россия белән мөнәсәбәтләр тигезлек һәм гаделлек принципларына корылган булудан гыйбарәт.

Икенче уртаклык — Татарстанның тулы мөстәкыйльлеген тормышка ашыру дисәм, шулай ук хата булмас. Татар мәдәниятенең язмышына, татар теленең бүгенге көне һәм киләчәгенә багышланган дискуссияләр, милли мәктәп концепциясе, икътисади куәт мәсьәләсе. Бу проблемалар чын мәгънәсендә бөтен халык катнашында тикшерелде һәм нәтиҗәдә уртак фикер барлыкка килде. Монысы да хакыйкатькә туры килә һәм шартнамә дә шуңа җавап бирергә тиеш.

Без барыбыз да Татарстанның башка дәүләтләр арасында лаеклы урын алуын телибез. Аның чәчәк аткан дәүләт сыйфатында бүгенге тарих барышына уңай йогынты ясаучы факторга әверелүен максат итеп куябыз. Бу безнең өчен чит илләр белән үзебез теләгәнчә, үз хаҗәтебездән чыгып мөгамәлә һәм багланышлар урнаштыру дигән сүз.

Әйе, кайберәүләргә, мәсәлән, Россия Тышкы эшләр министрлыгына, бу идея әллә ни ошап бетми бетүен. Ләкин хәзер инде хәтта Руслан Хасбулатовка да Татарстанның БМО әгъзасы булырга тиешлеге әллә ни ят булып ишетелми. Гомумән, бүген Россия җитәкчелегендә Татарстанның халыкара хокук субъекты булу ихтималы инде аңлау таба. Алай гына да түгел, без Россиянең Татарстанга карата аналар бурычын үтәү йөзеннән аны халыкара аренага үзе алып чыгарга тиешлеген дә күрәбез. Шунысы шатландыра, Россия җитәкчелегендә моны дөрес аңларга теләүчеләр юк түгел.

Ә бит Россия, чыннан да, шушы эшне башкарса, Татарстан, аның игелекле халкы, җир йөзендәге барлык татарлар, аңа рәхмәтле булыр иде. Бу исә ике дәүләтнең бердәмлеген, теләктәшлеген ныгытыр, Россиягә шөһрәт өстәр иде. Татарстан халкы Россиядәге һәм җир йөзендәге барлык татарларның бер милләт булып яшәвен тели. Гомумән, моны милләтебезнең күпчелеге хуп күрә. Газета һәм журналларыбызга килгән дистәләрчә хатлар шуны күрсәтә. Димәк, без Россия һәм башка дәүләтләр белән дустанә яшәргә тиешбез. Аларның һәммәсе белән дә төзеләчәк шартнамәләр шуңа юл ачарга тиеш.

Инде әйтеп үткәнемчә, Татарстан урыныннан кубарылып очып китәргә җыенмый. Ә аның геополитик хәле шундый ки, ул чит җирләргә бары тик Россия аша гына чыга ала. Форсаттан файдаланып шуны да әйтәсем килә, Татарстанны ниндидер бер анклав, ягъни Россиянең уртасында утырган уенчык дәүләт итеп күз алдына китерү дә дөреслеккә туры килми. Беренчедән, инде күптән Казанны биш диңгез порты дип атыйлар. Ул бит, чыннан да, Идел аша шул биш диңгезгә чыга, шулар аша бөтен дөнья белән мөгамәлә кора ала. Башкаласы биш диңгез порты булган дәүләтне анклав дип атап булырмы икән соң? Бусы — бер. Икенчедән, Татарстан Россиягә генә терәлеп тормый бит. Аның чикләрендә Башкортстан, Чувашия, Мари Эл. Ә бит алар бүгенге көндә суверен дәүләтләр дип танылдылар. Көньяк-көнчыгыш чикләребездә Оренбург өлкәсе. Андагы татарлар, башкортлар, казакълар, руслар яшәгән җирләр Казагыстанга килеп терәлә.

Ниһаять, үзебезнең фәнни-техник революция заманында яшәгәнебезне онытмаска кирәк. Хәзерге мөмкинлекләр Татарстанга көчле диңгез-елга флоты, югары сыйфатлы һава флоты белән бергә, шундый ук автомобиль транспорты булдырырга да юл ача. Хәзерге телесистема, радио, спутник элемтәсе секунд-минут эчен-

дә дөньяның теләсә кайсы почмагы белән элемтәгә керү мөмкинлекләрен ача.

Россия исә Татарстанның шундый көчле дәүләт булуыннан тик отачак кына. Беренчедән, бу аның үз экономикасын үстерүгә стимул булса, икенчедән, ул аның тотрыклы дәүләт булып әверелүенә искиткеч уңай шартлар тудыра.

Әгәр кем дә булса Татарстан мөстәкыйль дәүләт буларак, Россиянең бердәм булып яшәвенә комачаулык тудыра, аны таркатуга юл ача, дип уйлый икән, ул кеше бик нык ялгыша. Россияне Татарстан түгел, хәерчелек һәм бөлгенлек, экономик яктан җимерелү тарката. Бүген мөстәкыйльлеккә Татарстан гына түгел, хәтта Россиянең үз регионнары да омтыла. Чөнки алар Россиядән түгел, хәерчелектән, бөлгенлектән качалар.

Татарстан исә үзенең Россия белән бер экономик киңлектә, бер акча зонасында калуы белән аны тик ныгыта гына. Без кул куярга тиешле шартнамә проектында моңа да зур урын бирелүе юкка гына түгелдер.

ТИШКОВКА НИ ҖИТМИ?

Бу сорауны бирүемә Россия хөкүмәтенең Милләтләр эшләре комитеты рәисе мөхтәрәм профессор В. Тишковның 1992 елның 18 сентябрендә «Известия Татарстана» газетасында басылган тагын бер интервьюсы сәбәп булды. Чыннан да, нигә соң әле шушы интервьюсында мөхтәрәм рәис гражданлык мәсьәләсен күтәреп чыккан, Россия һәм Татарстан гражданлыгына, икеләтә гражданлыкка үзенең шактый сәер карашын белдергән?

Мин ни өчен бу карашны сәер дип әйтергә мәҗбүрмен? Чөнки безнең инде аның белән күп мәсьәләләр буенча, шул исәптән гражданлык мәсьәләсендә дә шактый бәхәсләр булып алды. Эчтәлекле, файдалы бәхәсләр, дияр идем мин. Тик шунысы гаҗәпләндерә: инде

ике арада ирекле һәм тигез хокуклы килешүгә кул куярга сүз куешканнан соң нигә өлкән һәм кече гражданлык идеясен алга сөрергә кирәк булды икән соң? Әллә без һаман да, элеккеге кебек, бер-беребезне купшы сүзләр белән алдау гадәтеннән арынып җитә алмадыкмы?

Юкса, Россия һәм Татарстанны тигез хокуклы дип игълан итеп тә, аларның гражданлыкларын берсен икенчесенә буйсындырып куюны башкача аңлап булмый. Инде бит экспертлар белән бергәләп кече һәм өлкән суверенитетлар булмый, суверенлык тигез генә була ала, дигән нәтиҗәгә килгән идек ләбаса! Гражданлык мәсьәләсе әнә шул суверенлыкның бер конкрет чагылышы гына түгелме соң? Әгәр дә без Россия һәм Татарстанның суверенитетлары тигез хокукта дип таныйбыз икән, аларның гражданлыклары да тигез хокукта булырга тиеш бит.

Күрәсең, монда логикадан да өстенрәк нәрсәләр бардыр. Әгәр дә бар икән, ул нәрсә соң? В. Тишков әфәнде бик киң карашлы галим. Аның тирән фикерле кеше икәнлеген фәнни җәмәгатьчелек яхшы белә. Шулай булгач, монда эш куелган максатның теләсә нинди логикадан өстен торуында гына.

Ә максат — «бердәм һәм бүленмәс Россия». Шуңа ирешү өчен нинди алымнар кулланырга кирәк булса, барысы да кулланылырга тиеш. Шул идеяне сыйпап үткәрергә мөмкин булса — сыйпарга, алай үткәреп булмаса — кыйнарга.

Ләкин шунысын онытырга ярамый. Бер нәрсәне баштан ук ике як та таныды, алар — Россия Федерациясен барлыкка китергән юридик нормалар. Без бит артык нәрсәне һич кенә дә таләп итмибез. Безгә шушы нормаларның танылуы, ниһаять, тормышка ашырылуы кирәк.

Әгәр дә бүгенге көндә кем дә булса Россия гражданлыгының өстенлеген дәгъвалый икән, Татарстан гражданлыгын ялган фасадка гына әйләндерергә мата-

ша икән, ул кеше безнең республиканы яңадан коллыкка кайтармакчы була дигән сүз.

Нәрсә соң ул гражданлыкларның тигезлеге? Әгәр дә шундый тигезлек була икән, ул вакытта ике гражданлылык мөмкин нәрсәме?

Бу сораулар бик төгәл җавап таләп итәләр. Ләкин нинди генә җавап бирелсә дә, аңа кем генә җавап бирсә дә, бер нәрсә ачык булырга тиеш: гражданлыклар үзара тигез булганлыктан, алар беркайчан да бер-берсе белән сугышырга тиеш түгел. В. Тишков әфәнденең фикеренчә, Россия гражданлыгы һәрвакыт югары булып чыга.

Билгеле булганча, референдум үткәрер алдыннан Татарстан җитәкчеләре үзләрен ике гражданлылык тарафдарлары дип игълан иттеләр. Бу — әгәр дә Татарстан гражданнары үзләрен тик Татарстан гражданнары булуларын гына телиләр икән — була бирсеннәр дигән сүз. Әгәр дә инде кемдер шуның өстенә Россия гражданлыгын да саклап калырга тели икән — саклый бирсен. Татарстан җирлегендә, әлбәттә, ике гражданлылар бары тик Татарстан законнарына гына буйсына. Ә инде Татарстаннан Россиягә чыгалар икән, алар анда тулы хокуклы Россия гражданнары; шулай итеп, кайберәүләр ике гражданлы да була ала. Моны алар Татарстанда яшәгән килеш ике илнең дә законнарына буйсынып яшәү, дип уйлыйлар. Әгәр инде аларга Татарстан законнары ярап бетми икән, алар Россиягә, аның законнарына мөрәҗәгать итәләр булып чыга. Алар үзләренә карата чыгарылган Татарстан судлары карарлары белән риза булмасалар, Россия судларына мөрәҗәгать итә алалар, дип фикер йөртәләр. Алай гына да түгел, шундыйларның күбесе Татарстанда яшәгән килеш Россия органнарына, аның президентын сайлауга катнашырга хокуклары бар, дип уйлыйлар.

Юк, бу һич тә алай түгел. Татарстанда яшәүче ике гражданлы кешеләр тик Татарстан гражданлыгы хо-

кукларыннан гына файдалана алалар. Аларның икенче гражданлыклары резерв рәвешендә генә кала.

Нигә кирәк аларга бу резерв? Беренчедән, алар аны мораль фактор итеп саный. Үзенең Россия белән бердәм яшәвенең билгесе итеп күрә. Икенчедән, әгәр дә гражданлык хокуклары бозыла икән, Россия органнарына мөрәҗәгать итеп, үзе өчен гаделлек таләп итә ала. Өченчедән, Россия җиренә килеп керү белән, Россия гражданы хокукларыннан файдалана.

Әгәр дә Татарстан һәм Россия арасында шушы рәвештә ике гражданлылык турында килешү төзелә икән, ул вакытта Россиядә яшәгән татарлар да өстәмә рәвештә Татарстан гражданлыгы алырга мөмкин. Ул вакытта аларның хәле дә Татарстандагы ике гражданлылык хокукы белән файдаланучыларныкы шикелле була.

Кайсы гражданлык өстен соң бу очракта? Әлбәттә, кешенең үзе яшәгән ил гражданлыгы. Менә шушы принцип гражданлыкларның тигезлеген тәшкил итә. Әлбәттә, ике гражданлыкның берничә варианты бар. Алары турында да сүз алып барып булыр иде. Ләкин бу юлы мин менә шушы төп, нигез принципны гына күрсәтеп үтмәкче булдым.

Профессор В. Тишков исә ике гражданлылыкны башкачарак аңлый. Аның фикеренчә, Татарстан гражданнары, телиләрме-теләмиләрме, бер үк вакытта Россия гражданнары да булып саналырга тиеш. Әмма бу принцип үзеннән-үзе Татарстанның суверенитетын бозуга китерә. Аныңча, Татарстан гражданнары Россия президентын, аның Югары Советына депутатлар сайлауда мәҗбүри рәвештә катнашырга тиеш. Әгәр дә инде алар президент һәм Югары Советны сайлаганнар икән, алар шуңа буйсынып та яшәргә мәҗбүр булалар түгелме соң?

Ул чагында Татарстан гражданнары өчен Россиянең суд власте да мәҗбүри була. Россиядә кабул ителгән законнар Татарстан территориясендә өстенлек итә.

Ә суверенлыкның төп нигезе булган Татарстан законнарының өстенлеге ни хәлдә була соң? Ул юкка чыгарыла дигән сүз. Үткән елның декабрендә икътисади мәсьәләләр буенча сөйләшүләр вакытында Е. Гайдар: бернинди законнар өстенлеге турында сүз булырга мөмкин түгел, без Татарстан өчен генә нинди дер аерым шартлар тудырырга җыенмыйбыз, дигән иде. Күрәсең, бу да юкка гына булмагандыр.

Чыннан да, әгәр дә Татарстан гражданнары Россия дәүләт органнарын сайлауда катнашалар икән, алар шул органнар чыгарган законнарга, чыгарган карарларга буйсынырга тиеш. Шулай булмаганда ул органнар аңа нигә кирәк?

Юк, гражданлык мәсьәләсе — гади мәсьәлә түгел. Ул суверенлыкның нигез ташларыннан берсе. Тигез хокуклы гражданлык тигез хокуклы суверенитетларга тиң. Өлкән һәм кече суверенитет булмаган кебек, өлкән һәм кече гражданлык та була алмый.

Бер гражданлыкның икенчесенә буйсынуы — бер суверенитетның икенчесенә буйсынуы дигән сүз ул. Бу юридик яктан абсурд. Әгәр дә шул абсурдка юл куела икән, ул вакытта суверенитет тик декорация булып кына калачак. Татарстан элеккегедән дә гаделсез шартларда «бердәм һәм бүленмәс Россия»гә буйсыначак.

Безнең халык референдумда биргән җавабында үз сүзен әйтте инде. Халык сүзен гамәлгә ашыру — сәясәтчеләр эше. Ә вакыты җиткәч шул сәясәтчеләр халык алдында җавабын да бирерләр. Халык алдында гына түгел, тарих алдында да.

БӘЙСЕЗЛЕКНЕҢ БЕРНИЧӘ ШАРТЫ

Мин бу мәкаләмдә Татарстанның бәйсезлегенә кагылган берничә шарт турында сүз алып бармакчы булам. Ләкин бәйсезлек өчен көрәшнең буйсынып яши торган һәммә халыклар өчен гомуми шартлары булуын да

истән чыгармыйк. Шунлыктан сүзне иң башта алардан башламакчы булам.

Шартларның беренчесе — изелеп, кол булып яшәгән халык үз хәлен-халәтен яхшы аңларга тиеш. Әгәр дә ул үзенең кол икәнлеген, җәберләнгәнлеген һәм буйсынып яшәгәнлеген аңламаса, азатлык өчен көрәшкә әле өлгермәгән булып чыга. Кыскасы, халыкның ирек өчен көрәшкә уянганлыгы — җиңеп чыгуының төп шарты булып тора.

Башка халыкларның үзеңнән өстенлеген табигый дип кабул иткәндә, бәйсезлек турында сүз алып барып булмый. Монда тик шуны онытырга ярамый. Бер генә халык та үз хәлен үзеннән-үзе төшенеп җитә алмый. Аның бәйсезлек көрәшенең идеологиясен эшләрлек һәм шуны халкына аңлатырлык кешеләре — идеологлары булу мөһим. Ләкин аның әзерләнеп беткән килеш күктән иңүен көтеп утыру да хата булыр иде.

Аны тормыш үзе тудыра, үзе төзәтмәләрен кертә. Шуны да онытмыйк, теория эшсез ятса, ул күгәреп юкка чыга. Аны кулланучылар кирәк. Халыкка алып чыгучылар кирәк. Иң элек бу рольне дә шул ук идеологлар үзләре башкарырга мөмкин. Билгеле, азатлык концепциясе кабинетларда гына бикләнеп эшләнми. Ул халык арасында чарлана. Шулай итеп, бәйсезлек тәгълиматы коллектив фикер булып өлгерә.

Әлбәттә, теоретиклар да, идеологлар да зыялы халык арасыннан чыга. Әгәр дә теге яки бу милләтнең интеллигенциясе үз халкының милли аңы арттыгына битараф кала икән, ул вакытта бәйсезлек турында шулай ук сүз алып бару мөмкин булмый. Зыялылары өлгермәгән халык кол булып кала. Гадәттә азатлык идеясе гуманитар зыялылар — радио-телевидениедә, газета-журналларда, фәнни институтларда, югары уку йортларында, мәктәпләрдә, колхоз һәм совхозларда эшләүчеләр арасында туа. Бу татарларда да шулай булды. Ләкин бездә, кызганычка каршы, бүгенге көндә шушы

изге эшкә хәтта гуманитар интеллигенциянең дә күбесе чын-чынлап катнашмый, ә техник интеллигенция турында сүз кузгатуы да авыр. Шул ук вакытта эшчеләр, колхозчылар арасында милли аңы үскән шәхесләр шактый. Аларга тәвәккәллек җитә, әмма белем, культура җитми. Чаллы, Әлмәт, Казан һәм башка шәһәрләр, шул исәптән республикага кермәгән төбәкләрдән дә моның уннарча мисалын китерергә мөмкин. Шулай итеп, милли азатлык идеясенең тууы, яшәве генә җитми, аның материаль көчкә әверелеп, халык массаларына киң һәм тирән үтеп керүе тагын бер әһәмиятле шарт булып тора.

Тарихка күз салсак, бастырылган халыкларның әледән-әле милли азатлык көрәшенә күтәрелеп торуын күрәбез. Ләкин шартлар өлгермәү аркасында алар җиңеп чыга алмаганнар. Мәсәлән, 1905—1907, 1917—1920 елларда бу шулай була. Ә 1917 елгы революция монархиянең юкка чыгуына гына китерә. Бу хәл империя таркалу миражын тудыра. Әлеге миражны чынбарлык белән бутаган Россия халыклары, нигездә, монархиянең җимерелүеннән туган шартлардан файдалана алмый калалар. Тик Польша һәм Финляндия генә үз максатларына ирешәләр. Бу илләрнең күпчелек зыялылары үзара аңлашмаучылыкларны читкә куеп, тик бәйсезлекне генә төп максат итеп алалар. Үзен ата социалист санаган Польша лидеры Пилсудский да, үзе әйтмешли, социализм поездыннан бәйсезлек тукталышында төшеп калган. Ягъни ул социалистик революциягә караганда милли азатлыкны өстенрәк күргән.

Ә менә башка халыкларның социалистлары, көрәш приоритетын дөрес сайлый алмаганлыктан, социализм поездына ахыргача утырып барганнар. Шунлыктан алар үзләре генә түгел, халыкларын да төп башына утырттканнар. Тарихта бик сирәк була торган мөмкинлекне ычкындырганнар. Димәк, бүгенге милли азатлык кө-

рәшенең төп максатына ирешү өчен халык бер йодрык булып төйнәлергә-берләшергә тиеш.

Чыннан да, Совет империясе жимерелеп килә. Тик инде ул бетте, империалистик көчләр юкка чыкты, дип уйлау хата булыр иде. Тарих патша бәреп төшерелгәч, империя җимерелде дип уйлауның зур ялгыш булуын раслады. Чынлыкта империя тик кием генә алыштырган икән. Бүген дә кием алыштыру эше бара. Демократ булып кыланган Шеварднадзе Төньяк Кавказны канга батыручыларның берсенә әйләнеп китте. Россиядә Руцкой «бердәм һәм бүленмәс Россия» идеясенә хезмәт итүен яшерми. Менә шуның өчен дә бәйсезлек юлына баскан халык бар нәрсәгә дә әзер булырга тиеш. Аның җитәкчеләреннән моның өчен фидакярлек һәм батырлык сорала. Әмма көрәшнең тыныч юлын сайларга кирәк. Корал, кан коюга соңгы чара итеп карарга кирәк.

Безнең Татарстан җитәкчелеге әнә шул тыныч юлны сайлады. Авыр булса да, Россия белән сөйләшеп ике яклы килешү булдыру юлына басты. Шул рәвешчә Россиядән безнең бәйсезлекне таныту максатын куйды.

Ләкин тактик хаталар да ясалды. Мәсәлән, 21 март референдумы нәтиҗәләрен Югары Советта аерым документ белән ныгыту мөһим иде. Татарстанның суверен дәүләт хокуклары закон рәвешендә ныгытылмый калуы Россия белән сөйләшүләрне авырлаштыра. Шул нәрсәнең эшләнмәве нәтиҗәсендә хокук саклау органнарын республика карамагына күчерү эше дә тоткарланды. Моның тискәре нәтиҗәләре инде үзен сиздерә дә.

Бу хатаны хәзер кичекмәстән суверен дәүләт Конституциясен кабул итү белән генә төзәтеп була. Бәйсезлекнең хокукый ягын булдыру — аны яклау-саклауның бер гарантиясе ул.

Тагын бер мәсьәлә. Әгәр җитәкчеләр халык фикеренә таянып эш итәргә уйлаганнар, ә халык аларны хуплап чыккан икән, алга куелган максатны тормышка ашыру — җитәкчеләрнең бурычы. Юкса алар халык-

ның ышанычын югалтачаклар. Икенчедән, аларның икеләнүен сизеп алган каршы як та беренче максаттан чигенергә мәҗбүр итәрлек чаралар кулланачак. Курыкканны кызганмыйлар, кыйныйлар гына. Димәк, көн тәртибенә куелган мәсьәләне хәл итүдә ныклык күрсәтү — бу шулай ук җиңүнең тагын бер шарты.

Билгеле, Татарстанның үз эчке тормышы бәйсезлек өчен көрәшнең төп нигезе булып тора. Монда мин өч факторны күрәм. Беренчесе — төп милләтнең рухи халәте. Икенчесе — аның үзе белән бергә яшәгән халыклар белән бәйләнеше. Өченчесе — республиканың икътисади хәле һәм мөмкинлекләре.

Моны ничегрәк аңларга кирәк соң?

Бүгенге чынбарлык милли-иҗтимагый хәрәкәтләргә, аларның җитәкчеләренә, зыялыларга бердәмлек җитмәүне күрсәтә. Безнең таркаулыктан башкалар бик оста файдалана. Милли оппозициянең хөкүмәтне кирәк чакта тәнкыйть итүче һәм аның мөстәкыйльлегебезне тормышка ашыруга юнәлдергән адымнарын яклый торган көч булуы бик зарур. Чыннан да, хөкүмәтнең бу өлкәдәге уңышларын, икътисади сәясәтнең башкаларга караганда зуррак маһирлык белән алып барылганын күрми калу мөмкин түгел. Маңгайга бәреп тәнкыйтьләү, барлык эшне каралтып күрсәтү — радикаллык билгесе түгел. Шуңа күрә үзара көрәшне туктату мәслихәт. Чөнки үткән революция елларында Фуат Туктаров, Садри Максуди кебек әһелләребезнең бердәмлеккә өндәвенә колак салмау милли хәрәкәтне җиңелүгә дучар итте. Кызганыч, Мирсәет Солтангалиев кебек шәхесләр моны соң аңладылар. Алар үз тарафдарлары белән җыелышып, большевиклар сүзен тыңлап, туып килә торган Идел-Урал штатын пыр туздырдылар. Ә инде хаталарын аңлаганда эш үткән иде.

Солтангалиев бердәмлек кирәген, бәйсезлеккә йөз тоткан халыкларның таркалырга, бер-берсе белән тартышучы оешмалар төзергә хакы юклыгын башкаларга

васыять итеп калдырды. Шул васыять Азия һәм Африка илләренә барып иреште. Илленче елларда уңышлы тәмамланган милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләре, мәсәлән, Алжир революциясе лидеры Әхмәт Бен-Белла, Мисыр революциясе юлбашчысы Гамәль Әбдел Нәсер әлеге васыятьне үзләренә күрсәтмә итеп алдылар. Аларның кабинетларында мәшһүр Солтангалиевнең сурәте эленеп торган. Солтангалиев өченче дөньяның идеологы итеп танылды. Минемчә, безгә шул васыятьне искә төшерергә бик вакыт.

Ярый әле безнең республикада моңа кадәр беркайчан да милләтара конфликтлар булганы юк. Булмасын да. Шул сәбәпле республикабыз халкының 51 процентын тәшкил иткән татардан башка халыкларны бәйсезлегебез өчен көрәштә союзник итәргә кирәк безгә. Инде аның шактые безгә авышып, бәйсезлекнең һәммә кешегә дә файдалы икәненә ышанды. Референдумда катнашкан кешеләрнең 61 проценты юкка гына «әйе» дип җавап бирмәде бит. Ә нинди генә янаулар һәм куркытулар булмады. Димәк, республика халыкларының үзара дуслыкка, аңлашып яшәүгә омтылышы зур. Татарстан халыкларының съездында бердәмлеккә сәяси нигез салынды. Ләкин аларны бәйсезлегебезне яклый торган көч итү әлегә башлангыч чорында гына. Әгәр дә без ышанычлы күпчелекне булдырмасак, мөстәкыйльлегебез яуланыр-яуланмас килеш кыл өстендә калачак. Икътисади уңышларыбыз Татарстанда яшәүче һәркемгә дә суверенитетның коры сүз генә түгел, ә тормыш шартларын бермә-бер яхшырту мөмкинлеге икәнлеген аңлата. Халкыбыз экономик яктан үзен ышанычлырак сизә. Быел бердәм рәвештә үстергән уңышны җыеп алдык. Тирә-күршеләргә азык-төлек теләнеп йөрмәвебез һәр милләт кешесендә патриотлык хисе уята. Ләкин моны ныгытылган нәтиҗә дип әйтеп булмый. Авыл хуҗалыгыбыз яңа технологияләргә, яңа сортлы орлыкка, мул продукцияле мал-туарга һәм башкаларга мохтаҗ.

Татарстанда бушап калган, таркалган авыллар күп. Шунда читтә яшәгән милләттәшләребезне кайтаруны оештырырга кирәк. Кайтучылар күп булыр. Шунысы ачык, әгәр дә бу эштә кискен борылыш ясый алмасак, азык-төлек проблемасы гына түгел, гомумән, милләтнең физик яктан исән калу проблемасы да килеп басачак. Халык саны артуның төп чыганагы авыл булган кебек, аның әхлагын, гореф-гадәтләрен, телен саклау да моңарчы авыл хисабына барды. Шуңа күрә авылга берни дә кызганырга ярамый. Әле күп авылларда су, газ, адәм рәтле юллар юк. Торак төзелешендә дә өстенлекне авылга бирмичә булмый. Конверсия уңаеннан промышленностьны үзгәртеп барганда яңа тармакларны да торгызып җибәрергә туры киләчәк.

Әйтик, үзебез һәр елны 30 миллион тоннага якын нефть чыгаруыбызга да карамастан, әлегәчә бензинны читтән алырга мәҗбүрбез. Төзелеш материаллары, беренче чиратта цемент җитештерү белән дә шундый ук хәл. Әлегә җир асты байлыкларыбызның да тиешенчә барланганы юк.

Борынгы заманнарда Болгар дәүләтендә, Европада беренче буларак, тимер эшкәртә башлаганнар. Димәк, кайдадыр тимер запаслары да булуы ихтимал. Инде бездә бакыр ятмалары барлыгы мәгълүм. Татар эшмәкәрләре XVIII—XIX гасырларда ук аларны эшкәртү юнәлешендә эш алып барганнар. Совет чорында икенче бишьеллык планы буенча да бу эшне җәелдереп җибәрү күздә тотылган булган. Әмма аны дәвам иттерү бурычы бүгенге көннәрдә генә билгеләнде. Бәлки, мин инде фантазия, хыял юлына басамдыр. Ләкин бакыр булган җирдә алтын да була диләр. Кайберәүләр исә аның, чыннан да, бар икәнлеген күрсәтеп сөйли. Дөресме бу, юкмы, ләкин боларның һәммәсен истә тотып эш итәргә кирәк.

Әйе, сәяси бәйсезлек икътисади бәйсезлектән башка була алмый. Әлегә безнең республика икътисадының

барлык тармаклары бердәм экономик организм булып эш итә алмый. Күп предприятиеләр читтәгеләргә нык бәйле. Билгеле, моңардан качып та булмый. Ләкин әгәр безнең предприятиеләр бурычка эшләмичә, вакытында исәп-хисап ясап барырлык хәлдә булсалар, алардан беркем дә йөз чөерә алмый. Мондый элемтәләрне көйләүдә читтәге татар диаспорасыннан, аның галимнәреннән, завод-фабрика җитәкләүче шәхесләрдән файдаланырга була. Икътисади бәйләнешләр турында сөйләгәндә Россияне нииндидер бердәм монолит итеп кенә кабул итү дөрес түгел. Безнең иң якын күршеләребез Башкортстан, Чувашия, Мари Эл, Удмуртия. Болары белән без дәүләтара мөнәсәбәтләр урнаштырабыз. Шул ук вакытта борын чөеп, күрше-тирә өлкәләр тарафыннан безгә таба сузылган кулларны кабул итмәсәк, бу — хаталану булыр. Аларның да максималь рәвештә мөстәкыйльлеккә омтылуларын онытырга ярамый. Нижний Новгород хәтта үз акчаларын сугарга җыена. Шулай булгач, аның да, Екатеринбург, Самара, Ульяновск өлкәләренең дә безнең белән уртаклыклары бар. Без алар белән элемтәләрне ныгытып, кирәк вакытта үзебезне яклап чыгардай дәрәҗәгә җитәргә тиешбез. Гомумән, Идел-Урал җирлегендә төрле-төрле бердәмлекләрне булдыру безнең бәйсезлек өчен көрәшкә тик көч кенә өстәр, дип уйларга кирәк. Без Татарстанның үзен төрки дөньяның бер өлеше икәнен дә оныта алмыйбыз. Шунлыктан Төркия, Урта Азия дәүләтләре, Казагыстан белән махсус мөнәсәбәтләр булдырылыр, дип уйларга кирәк. Инде Үзбәкстан, Кыргызстан, Казагыстан белән дә ике яклы тыгыз багланышлар урнаша башлады.

Халкыбыз төрки дөньяның үзе өчен чын союзник икәнен тоеп яшәсен иде. Ул республикаларның үзләрендә дә безгә карата шундый өмет бар. 31 август көнне, бәйсезлекнең бер еллыгына багышланган кабул итү вакытында ясаган чыгышында Кыргызстан президенты

Әскәр Акаев «бәйсезлек сукмагына баскан Кыргызстан ялгыз түгел», дип аның союзниклары арасында Татарстан белән Башкортстанны да атады.

Безнең республиканың хәле шундый ки, аның берьюлы һәммә дәүләт тә танымас. Аларның күбесе, башта сезне Россия танысын, аннан соң күз күрер, дип тора. Бу аңлашыла да. Чөнки Россиядән күпләр курка. Һәм моңа нигез дә бар. Шунлыктан бу илләргә үпкәләргә кирәк түгел. Аларның берәүләре безне иртәгә үк танырга әзер булса, икенчеләре өлешчә генә таныр. Вакыт һичшиксез безнең файдага эшли. Тик түземле, сабыр була белергә кирәк. Инде бит Балтыйк буе республикалары, Молдова һәм кайбер башка илләр белән икътисади мөнәсәбәтләр урнаштырылды. Шул мөнәсәбәтләр торган саен сәяси төс алып, алар тарафыннан безне дипломатик тануга якынайталар.

Әгәр дә инде ерактагы чит илләргә килсәк, ягъни АКШ, Англия, Германия, Канада, Япония турында сүз алып барсак, алар бүген безне күзәтәләр. Һәм, шуны әйтергә кирәк, бездәге чагыштырмача икътисади тотрыклылык аларны нык кызыксындыра. Алар да акрын булса да Татарстан белән икътисади мөнәсәбәтләргә керәләр. Алар безне партнерлык алып барырлык җитди икътисади ил итеп таныйлар икән, безгә монысы да зур файда. Чөнки ул безнең бәйсезлегебезгә бер терәк.

Әлбәттә, әйтеп үткәннәр Татарстанның башка илләр тарафыннан дипломатик рәвештә танылуын, аны БМОга кабул итү эшләрен теләсә никадәр сузарга ярый, дигән сүз түгел. Безгә, һичшиксез, Тышкы эшләр министрлыгы төзеп, дипломат кадрлар туплау эшен бүген үк башлап җибәрергә кирәк. Бу очракта шулай ук башка җирләрдә хезмәт итә торган татар дипломатларын барлап чыгу да зарар булмастыр. Татарстанны дипломатик танытуда төрле илләрдә яшәгән абруйлы милләттәшләребезнең дә ярдәменнән файдалану мөһим.

Өстәп тагын шуны гына әйтәсе килә, бәйсезлеккә бару юлында барыннан да әһәмиятлерәк, иң төп шарт — халыкның, милләтнең үз җитәкчеләренә ышануы. Ә җитәкчеләрнең, хәтта хәйләле-дипломатик, сәяси-тактик адымнар ясаганда да, үз халкында шик тудырмаслык итеп хәрәкәт итүе — моның алшарты булып тора.

МИЛЛӘТНЕҢ БЕРДӘМЛЕГЕ — ТӨП ШАРТ

«Бүлгәлә һәм хакимлек ит». Шушы принцип белән эш итү һәм дошманнарны бер-берсенә каршы кую, аларны бетмәс-төкәнмәс низаг-сугыш юлына бастыру, күрәсең, борынгы Римда гына түгел, ә кешелек дөньясының үзе белән бергә тугандыр. Бу ысулны Россия дә бик зур осталык белән кулланып килде. Шулай булмаганда, дөньяның бер башыннан икенчесенә барып җиткән империя төзеп булыр идеме? Ул бит кеше яшәмәгән җирләрне җай белән генә үзләштереп киңәйгән дәүләт түгел. Киресенчә, киң үзәннәрдә, зур-зур урманнарда, очсыз-кырыйсыз далаларда яшәгән бик күп халыкларны буйсындыру, яулап алу ысулы белән барлыкка килгән империя ул.

Татар ханлыкларын яулауны гына искә төшерик. Урыс патшалыгы аларның арасына низаг салу өчен бик күп көч куя. Сатып алу дисеңме, хезмәткә яллап, льготалар тудыру дисеңме, чукындырып кыз бирү дисеңме? Бүгенге Урысларда татардан чыккан дистәләрчә, йөзләрчә шөһрәтле нәселләр юкка гына барлыкка килмәгән бит. Урыс патшалары татарларның иң асылларын үзенә тарткан. Кем хан тарафыннан кимсетелгән, җәберләнгән, шул Урыс патшасына барып сыена торган булган. Алар татар сарайларына үтеп кереп эш йөртә торган булганнар. Әнә шулар инде татарны бер-берсенә каршы куеп, хан властен какшата барганнар.

Казанны урыслар гына алмый, ә сатлык татарлар тапшыра. Әгәр дә татар бердәм булса, үз башкаласын

саклар өчен 30 мең генә гаскәр тотмас иде. Ул, гомумән, дошманны Казанга якын җибәрмәс тә иде. Бәлки, бу ерак тарихка тукталып та тормыйча, үткән эшкә салават дип, боларны онытырга да мөмкин булыр иде. Ләкин бит бүгенге буталчык заманда, элеккеге СССРның таркалып юкка чыккан вакытында, без төрле җирләрдә нәкъ борынгы заман мисалларын күрәбез. Әйтерсең лә, гасырлар үтмәгән, кеше һаман шул ук булып калган.

Таҗикстанда бер милләт, бер дин кешеләре үзара сугышалар, бер-берсенең канын коялар. Шул ук вакытта Россия гаскәрләре анда тәртип урнаштыра, сугышучы якларны килештерүче көч булып чыга. Ә килештерәме икән соң ул аларны? Бер-берсенә каршы куеп, үз файдасын гына карамыймы икән? Мәгълүм булган фактлар монда да борынгы «бүлгәлә һәм хакимлек ит» сәясәтенең гамәлдә икәнен раслыйлар.

Таҗикстанның күршесе Әфганстанга күз салыгыз. Анда да шул ук сәясәт икәнен күрерсез. Анда да мөселманнар бер-берсенең канын коя. Ә бит моның оеткысын Совет хөкүмәте салып калдырды. Анда гаскәр кертү тулысы белән алдан оештырылган икәнлеге бүген яхшы мәгълүм. Ләкин бит аның нәтиҗәсе бигрәк тә аяныч. Ул гаскәрне кире чыгарганда, Әфганстанның эченә инде ут капкан иде. Анда гражданнар сугышы үз көченә кергән иде. Ә хәзер кемнеңдер кулы шул Әфганстандагы утны Таҗикстанга күчерде һәм аны бөтен Урта Азия төбәгенә таратырга маташа.

Әлбәттә монда ниндидер бер аерым көч турында гына сүз барырга тиеш түгелдер. Боларның барысын да Россия эшләп ята, дип әйтү дә дөреслеккә туры килмидер. Ләкин шунысы ачык — монда халыкны бүлгәлиләр, аның бер өлешен икенчесенә каршы куялар. Нәтиҗә исә бик хәвефле булуы мөмкин. Күп кан түкәннән соң бу халыкларның үз бәйсезлекләреннән бөтенләй колак кагулары ихтимал.

Бәлки, кем дә булса мине куркыту эше белән шөгыльләнә дип уйлар. Уйласын, тик дөрес нәтиҗә генә ясасын. Андый кан коюлардан, әлбәттә, куркырга кирәк. Аны булдырмас өчен барын да эшләргә кирәк.

1917 елда патша бәреп төшерелгәннән соң төрле сыйныфлар арасында низаг чыккан иде. Шул шаукым татарлар арасына да килеп керде. Аның азатлык өчен көрәштә үтә зарарлы икәнен күрүчеләр булмады түгел, булды. Мәшһүр Фуат Туктаров, үзара аңлашмауларны читкә куеп, бөтен татарларны да бер өстәл янына чакырды. Байлар, ярлылар, әйдәгез, бергә җыелыйк, дип сөрән салды. Аның «Корылтай» исемле газетасы көн саен диярлек әнә шул милли бердәмлеккә өндәгән материаллар бастыра килде. Ул татарларны кадетлар артыннан да, большевиклар артыннан да бармаска, үз юлларын билгеләп, шул юлдан барырга өндәде.

«Вакыт» газетасы да әнә шул бердәмлеккә чакырып чаң сукты. Гомумән, күп татар газетасы, әйтик, Казандагы «Кояш», Мәскәүдәге Гаяз Исхакый чыгарган «Ил» газеталары да әнә шул сыйнфыйлык принцибыннан читкә чыгып эш итәргә өндәделәр.

Ләкин ул заманда сыйнфыйлык принцибы модада, ул өстенлек итә иде. Монда мин Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев яки Шәһит Әхмәдиевләрнең бакчаларына таш ыргытырга җыенмыйм. Алар һәммәсе дә ихлас затлар. Тик алар милләтебезнең бәхетен әнә шул сыйнфый көрәш юлында гына күргәннәр. Алар чыгарган «Кызыл байрак», «Аваз» газеталары моны бик яхшы раслый. Бу кешеләр бит татарлар арасында да гаделсезлекне күрә килгәннәр. Байларның баеганын, ярлыларның бөлгәнен күреп әрнегәннәр.

Әмма сүз монда хакыйкатьнең икенче ягы турында бара. Болай да изелгән, зәгыйфь милләт шундый җаваплы чорда, үзенең язмышы хәл ителә торган заманда, сыйнфыйлык сәясәтенә таянып эш итәргә хаклымы икән? Шул сорауга дөрес җавап бирү кирәк була.

Татарлар арасында бердәмлек булмауга аларның төрле җирләргә таралып яшәве дә комачаулый. Юкка гына түгелдер, аларны берләштерү максаты белән Мулланур Вахитов төрле төбәкләрдә үзенең Мөселман социалистлар комитеты оешмаларын төзи, мөселман социалистларын берләштерү максатын куя. Бу эшне дә милли бердәмлеккә таба ясалган адым дип карау дөрес булыр иде. Без әлегәчә шушы оешмага бер төрлерәк кенә бәя биреп килә идек. Аны ничек булса да большевиклар белән бәйләүне һаман алга сөрдек. Ләкин бит Мулланур Вахитов большевик булмаган. Ул үзенең эшчәнлеген Казан большевиклары комитетына буйсыну рәвешендә дә алып бармаган. Монда без шушы шәхеснең милли азатлык хәрәкәтендәге аерым роленә игътибар итәргә тиешбез.

Галимҗан Ибраһимов, татар әдәбиятының бер йолдызы буларак, шулай ук милли хәрәкәткә, татар халкының чын-чынлап азат булуына өметләнеп, инанып эш иткән. Әле моңарчы киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган фактлар Галимҗан Ибраһимовның революциягә кадәр үк чын мәгънәсендә социалистик булган милли азатлык партиясе төзергә йөрүен раслый. Хәзер инде моны да тулысынча ачып салу зарур.

Шул ук вакытта Мулланур Вахитов та, Галимҗан Ибраһимов та әлеге революция чорында сыйнфыйлык принцибын милли бердәмлек принцибыннан өстенрәк куйганнар. Кызганычка каршы, бу шәхесләребезгә милли бердәмлекнең беренче урында торырга тиешлеген аңлау соңрак килә.

Боларны бәян иткәндә, бер нәрсәне яхшы аңларга тиешбез. Сыйнфыйлык ул вакытта Россиядә, аның һәммә җирендә дә өстенлек иткән. Ә бит ил күләмендә дә милли бердәмлеккә өндәүләр булган. Аңа хәтта кыска гына вакытка ирешелә дә. Шул бердәмлек патшаны бәреп төшерүгә китерә. Ләкин ул инде 1917 елның март аенда ук юкка чыга. Нәкъ шул вакытта гражданнар

сугышы башлана. Анның иң зур җимешләренең берсе большевикларның властька килүе була. Әгәр дә Учредительное собрание җыелып, гомуммилли проблемаларны, шул исәптән власть мәсьәләсен дә барлык халык ихтыяҗларыннан чыгып хәл иткән булса, Россия, бәлки, киләчәк афәтләрдән котылган да булыр иде. Шулай булгач, сыйныфлар, партияләр арасындагы зур колачлы көрәштән татарлар гына читтә кала алган булырлар идеме? Күрәсең, юктыр. Россиянең күпчелек халыклары аннан читтә кала алмады. Хәтта украиннар да.

Минем боларны искә төшерүемнең сәбәбе — башка изелгән халыкларның Россия тарихыннан үзләренә тиешле сабак ала белүендә. Азия һәм Африка колониаль империяләргә каршы көрәш башлаганда, ул илләрнең азатлык байрагын күтәргән юлбашчылары нәкъ шул тәҗрибәне өйрәнерлек дәрәҗәдә булалар. Алар, бер яктан, үзләренә матди һәм мораль яктан ярдәм итүче итеп Советлар Союзын сайлыйлар. СССР исә, дөньякүләм социалистик революция булдыру максатыннан чыгып, аларга бу ярдәмне чыннан да күрсәтә.

Икенче яктан, алар рус революциясен җиңүгә китергән сыйнфыйлык принцибын кабул итмиләр. Бу очракта аларга ул революция үзе түгел, ә шул революция дәверендә уңышсыз тәмамланган милли азатлык хәрәкәте яхшырак сабак бирә. Аларга Мирсәет Солтангалиевнең соңрак шул хәрәкәттән ясаган нәтиҗәләре кулайрак күренә. Шул сабакның беренчесе — азатлык юлына, бәйсезлек өчен көрәш юлына баскан милләт сыйнфый көрәш юлын кире кагарга тиеш. Сыйнфыйлык принцибы читкә алып куелып, тик тулы җиңүгә ирешкәннән соң гына гамәлгә керә башларга мөмкин.

Икенче сабак — шушы көрәш дәверендә бердәнбер милли оешма булдырырга, яисә төрле оешмаларның, партияләрнең бердәм фронтын оештырырга кирәк. Ни өчен соң әле мәсьәлә шулай куела? Беренчедән, болай да аз булган көчне таркатмау максатыннан, икенчедән,

милли хәрәкәтнең бердәмлеген бирәү дә тарката алмасын өчен. Кыскасы, империалистик көчләрнең бүлгәләп хаким итүләрен дәвам иттермәс өчен.

Шул ук вакытта Солтангалиевнең тагын бер сабагы файдага эшли. Солтангалиев үз заманында Колониаль Интернационал төзү хыялы белән йөри һәм шул юнәлештә хәрәкәт тә итә башлый. Ул Россиядәге Шәрекъ республикаларын Туран берлеген төзү ягына бормакчы була. Боларның берсе дә тормышка ашмый, чөнки бу чаралар инде соңга кала. Моны исә 50 елларда башланган азатлык хәрәкәте юлбашчылары ныклап хәтерләренә салып куялар. Алар азатлык өчен көрәшкән илләрнең Африка берлеген булдыралар. Шулай итеп, бер халыкны икенчесенә каршы кую юлларын ябалар.

Күрәбез, безнең тәҗрибә колониаль системага каршы көрәшкән көчләргә файдага киткән. Нигә соң әле безгә үз тәҗрибәбездән йөз чөерергә? Нигә соң әле аны бүген чын мәгънәсендә өйрәнеп, башкаларның тәҗрибәсе белән баетылган рәвештә кулланмаска?

Бүгенге Татарстанда әле, бәхеткә, милли оешмалар үзара низаг юлына басмадылар. Алар әле үзара чын мәгънәсендә тартышмыйлар. Ләкин бу бит бүген. Ә иртәгә? Иртәгә андый куркыныч бармы? Һичшиксез, бар. Андый куркыныч һәрвакыт теләсә нинди азатлык хәрәкәтенә яный. Эш шунда ки, соңга калынмаса, вакыт дөрес сайланса, аны җиңеп була. Милли лидерларның төп бурычы — әнә шул җиңүне тәэмин итүдән тора. Зирәклекләре шуның белән билгеләнә.

Татарстандагы милли оешмаларның бердәм эшчәнлеген булдыру өчен, аларның бер тамырдан башланып киткәнлеген искә төшерергә кирәк. Иң беренче буларак, азатлык таңында Татарстан иҗтимагый үзәге (ТИҮ) барлыкка килде. Калган оешмалар, шул исәптән «Иттифак» партиясе дә, шуннан үсеп чыкты. Шунлыктан еш кына милли оешмаларның җитәкчеләре — кичәге фикердәшләр, бер-берсенә теләктәшлек күрсәтеп кил-

гән кешеләр. Әнә шул уртак фикер аларны укмаштыручы көч булырга мөмкин. Аларның уртак ниятләре, әлбәттә, Татарстанны азат итеп кору, аны бәйсез һәм тигез хокуклы дәүләт итү.

Аларның арасына башка фикердәгеләрнең керүе һәм бүләргә тырышуы бик ихтимал. Алар нәрсәгә таянып эш итәләр? Сүзсез, башка мәсьәләләрдәге фикер таркаулыкларына, төп максатка ирешүгә юнәлдерелгән ысулларның аерылуына һәм дә хөкүмәткә мөнәсәбәтләрнең бер төсле булмавына. Хөкүмәт, Президент, Югары Советта шулай ук мөстәкыйльлек өчен көрәш алып баралар. Ләкин аларның көрәш ысуллары республиканың һәммә катламына, һәр халкына ярардай сәясәт юллары табудан тора. Ә бу җиңел эш түгел. Шунлыктан хата киткән чаклар да булгалый.

Республика җитәкчелеге алдында Россия хөкүмәте белән лояль мөнәсәбәтләр саклау бурычы да тора. Монда да хаталар китми дип әйтеп булмый. Ләкин эш анда түгел. Иң хәтәре — шул хаталарны тәнкыйть итүчеләр арасында милли оешмалар гына түгел, ә мөстәкыйльлеккә каршы көчләр дә бар. Шулай итеп капмакаршы көчләр хөкүмәтне тәкыйтьләүдә бердәм фронт булып чыгалар.

Бу ситуация җиңел түгел. Ни өчен дигәндә, әле без демократия чорына керергә генә җыенабыз. Керә алабызмы, юкмы, анысы да әле шик астында. Шунлыктан үзара тәнкыйть, кемнедер уртак тәнкыйть итүләр безнең өчен әле ят нәрсә. Без бит һәммәбез дә — безнең белән булмаганнар — безгә дошман, дип яшәгән дәвердән үсеп чыккан кешеләр. Моның дөрес түгеллеген безнең әлегәчә аңлап бетерә алганыбыз юк.

Чыннан да, нигә соң әле безнең белән булмаган кешеләр безгә каршы булырга тиеш? Нишләп соң әле барлык кеше һәммә мәсьәләләрдә дә бер фикердә булырга тиеш?

Безнең оешмаларга бүгенге хәлләргә анализ ясый белмәү хас. Аларның тиешле рәвештә эшләрдәй аналитик группалары да юк. Үз тирәләренә җыелган, шуны башкара алырдай зыялылары да җитми.

Бәлки, безнең милли оешмаларыбызга гомуми аналитик хезмәт булдыру кирәктер? Бәлки, сәяси һәм икътисади мәсьәләләрне тикшерү өчен аларга аена бер мәртәбә булса да җыелышып сөйләшүне нормага кертергәдер? Әлеге җыелышларда хөкүмәт вәкилләре дә тигез хокуклы рәвештә катнаша алырлар иде. Бу исә үзара аңлашуга шактый ныклы нигез тудыра алыр иде. Монда башка милләтләрнең оешмалары да катнаша аламы? Махсус чакыру белән теләсә кем катнаша алыр иде. Шул ук вакытта алар белән ара-тирә очрашуның нормага керүе дә зарур.

Әлбәттә, бәйсезлек ягында торган теләсә нинди оешма белән тирән багланышка керергә мөмкин. Алай гына да түгел, шушы нигездә киң халык фронты төзеп булыр иде. Әгәр бу эш барып чыкса, ул вакытта әлеге фронт эчендәге бердәмлекне ныгыту төп бурычка әйләнергә тиеш була. Монда бер нәрсәне күз алдында тоту кирәктер: шушы киң фронт эченә, аны таркату максаты белән, дошман көчләрнең керүе бик ихтимал. Бездә әле чын мәгънәсендә уяулык дигән нәрсә юк. Каршы көчләрнең арага үтеп керергә тырышуына киртә салу чаралары эшләнмәгән. Гомумән, сер саклау, максатчан рәвештә коткы, ялган хәбәр яки дезинформация таратуга каршы чаралар уйланылмаган. Ә бит безнең күз алдында гына никадәр имеш-мимеш хәбәрләр таратылды. Күбесенең кем тарафыннан, ни өчен эшләнгәнлеге бөтенләй билгесез калды, ә күпмесе дөрес мәгълүмат итеп кабул ителде, һәм шул рәвешчә халыкка барып иреште дә! Боларны да тиешенчә тикшереп бетерә алганыбыз юк.

Әйе, бердәмлекне булдыру ул — сәнгать. Без әле ул сәнгатьне тиешле рәвештә үзләштерә алганыбыз юк.

Шул ук вакытта башкалар бердәмлекне таркату сәнгатен күптән һәм бик яхшы үзләштергән. Аларның моңа мөмкинлекләре дә күбрәк. Һәм социаль базасы нык. Халыкның теге яки бу имеш-мимешләргә ышанучан икәнлеген дә онытмыйк. Кайчак шымчылык хезмәтенең дә безгә каршы эшләгәнен истә тотыйк. Элеккеге шикаятьчеләр яңа шартларда шымчылык вазифасын үтиләр. Алардан сак булырга кирәк. Әгәр бердәмлегебезне көннән-көн ныгытып, бәйсезлек сафларын яңа тарафдарлар белән тулыландыра барабыз икән, ул вакытта бәйсезлеккә ирешүебездә бернинди шик булырга тиеш түгел.

ДИН ҺӘМ БӘЙСЕЗЛЕК

Шушы ике төшенчәнең үзара мөнәсәбәтләре ни рәвешле булырга тиеш? Бүген дөньяда аларны бәйләүче факторларның әһәмияте артканнан-арта бара. Бусы — бер. Икенчедән, күп урыннарда барган сәяси тартышларда динне көрәш байрагы итеп күтәрү очраклары да ешая. Кыскасы, бүгенге дөньяда ислам факторының көчәюе берәү өчен дә сер түгел. Әлбәттә, моны һәрвакыт һәм бөтен җирдә дә уңай роль уйный дип әйтеп булмый. Ләкин шул ук вакытта аның вакыйгаларга җитди тәэсир итүен танымыйча да булмый. Диннең халыклар язмышына уңай тәэсир иткәнлегенә тарих үзе шаһит. Кавказ халыкларының бәйсезлек өчен көрәш тарихын искә төшерик. Имам Шамил исеме әле бүген дә күпләр өчен гаделлек һәм азатлык көрәше символы булып кала. Аны күпме генә кара буяуга буяп күрсәтергә тырышсалар да, ул халык хәтеренә азатлык каһарманы булып кереп калган.

Безнең татар халкы язмышында да диннең роле ифрат зур. 1552 елның октябрь көннәрендә башкалабыз Казанны Явыз Иван гаскәрләреннән саклаган дин башлыгы Колшәриф оборона оештыру эшенең башында торган. Курку белмәс батыр гаскәребезгә дәрт вә илһам

биргән. Ә инде халкыбызның шуннан соңгы фаҗигале тарихында милләтебезне саклап калучы төп көч ислам дине булган. Беренчедән, дин халыкта өмет тудырган һәм аны саклап килгән. Шунлыктан халкыбызда киләчәктә азатлыкка ирешәсенә ышаныч беркайчан да сүнмәгән. Алай гына да түгел, азатлык рухы еш кына мәдрәсәләрдә, шәкертләр һәм руханилар арасында яшәп килгән. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен «Хөсәения», «Мөхәммәдия», Иж-Буби мәдрәсәләренең тарихына күз ташлау да җитә. Шул мәдрәсәләрдә халыкның тарихи хәтерен саклый торган җырлар, бәетләр һәм күңелгә сеңәрдәй шигъри юллар барлыкка килгән.

Икенчедән, татарның ассимиляциягә нык бирелгән халык икәнлеген, аның башка милләтләр белән күп аралашуын, алар белән актив мөнәсәбәттә яшәвен дә искә алсаң, диннең бу очракта да уңай роль уйнаганын аңларбыз. Нәкъ менә ислам дине халыкка тотнаклылык бирә, аның башка милләтләр белән, дөресрәге, башка диндә торучы кешеләр белән кан катыштыруын чикләргә тырыша. Шушы уңайдан укучыларның игътибарын бүгенге көндә милләтебезгә янаган тагын бер куркыныч нәрсәгә юнәлтәсем килә. Ул милләтебез яшьләре арасына башка дин йогынтысы үтеп керә башлау. Аларның бер төрлесе, әйтик, әхмәдичеләр, ислам байрагы астында хәрәкәт итә. Икенчеләре, ислам һәм башка диннәрне турыдан-туры хурлап, үз юлының өстенлеген исбат итмәкче була. Бу очракта мин протестантизмны истә тотам. Шушы протестантлар, матур-матур ритуаллар булдырып, яшьләр яраткан оештыру формалары табып, аларны инде үз якларына авыштыра да башладылар. Марат Гайнетдинов дигән берәү, аларның вәгазьчесенә әйләнеп, үз тирәсенә татар яшьләрен инде җыярга да керешкән.

Бездә вөҗдан иреге игълан ителгән, нигә сез кешенең үз кыйбласын эзләвенә киртә салмакчы буласыз, дияргә мөмкиннәр. Ләкин бит монда нинди дә булса

административ киртә кую турында сүз бармый. Сүз бары тик шушы эшләрнең милләтебезгә ясаячак йогынтысы турында бара. Бу очракта аның бердәмлеген какшата торган факторлар гына истә тотыла. Ә инде кемдер христиан яки башка дингә күчәргә тели, яисә милләтен ук алыштыра, вөҗданы һәм намусы шуны кабул итә икән, китә-тәгәри бирсен...

Минем милләтебезне чын күңелдән сөеп тә, хата юлга басулары мөмкин булган намуслы яшьләребезне генә кисәтәсем килә. Инде форсаттан файдаланып христиан динендәге милләттәшләрем турында бер-ике сүз әйтәсем килә. Мин язган сүзләр һич тә аларга каршы юнәлдерелмәгән. Христиан дине инде аларның традицион диненә әверелгән. Алар үзләренең яшәешләрен шуның белән бәйләгәннәр. Минем бары тик халкыбыз өчен җаваплы чорда бергә булыйк, милләтләшләр, дип кенә әйтәсем килә.

Шунысы бар — Аллага ышанмаган атеистлар арасына ассимиляция тизрәк үтеп керә. Нәкъ менә атеизм чәчәк аткан совет чорында милләтебез сан ягыннан бермә-бер кимеде. Совет чорында мәчетләрнең саны нык кыскарды. Бигрәк тә коллективлаштыру елларында муллаларны төрлечә кысу, Коръәннәрне яндырулар кешене дини тойгыларын яшереп яшәргә мәҗбүр итте. СССР Югары Советының 1941 ел, 15 июнь указы нигезендә тик Татарстанда гына да 1924 мәчетнең 1812 се ябылды. Бу киң масштаблы сәясәт иде. Әмма, кысрыклауларга да карамастан, халыкның йөрәгендә ислам нуры яши килде. Рухыбыз, гореф-гадәтләребез сакланмаса, татар халкы юкка чыккан булыр иде. Аллага шөкер, ул исән. Моның өчен динебезгә бурычлыбыз.

Бүгенге милли азатлык хәрәкәтендә диннең роле нинди булырга тиеш соң? Билгеле булганча, 1788 елда Әби патша (Екатерина II) тарафыннан Оренбург Дания нәзарәте төзелгән. Аны оештырганда Әби патша,

әлбәттә, мөселманнар файдасын беренче урынга куймаган. Ул Диния нәзарәте Россия мөселманнарын, бигрәк тә татарларны тәхеткә турылыклы итеп тәрбияләр, төрле-төрле фетнәләрдән саклап калыр дип уйлаган. Ялгышмаган да. Хөкүмәтнең үзе тарафыннан билгеләнгән күпчелек мөфтиләр тәхеткә турылыклы булалар. Шунлыктан татар җәмәгатьчелегендә һәрвакыт нәзарәтнең эшен үзгәртеп коруны таләп иткән тавышлар яңгырап торган.

Мондый хәл, кагыйдә буларак, революцион чорларда күзәтелә. Әйтик, 1905—1907 елларда. Шушы елларда бик күп дин әһелләре Диния нәзарәте белән каршылыкка килә. Бу очракта Муса Бигиев һәм Рәшит казый Ибраһимовларның исемнәрен телгә алып китәргә кирәктер. Киресенчә, алар уйлавынча, ислам динендәге кешеләр бердәм булып дөньядагы гаделсезлекләргә каршы көрәшергә тиешләр. Шул гаделсезлекләрнең зур бер сәбәбен алар патша режимында күрәләр. Шул рәвешле тәхет белән кулга-кул тотынышып эш иткән мөфтиләргә каршы чыгалар. Алар нәзарәтне ислахлаштыруны (реформа), үзгәртеп кору мәсьәләләрен күтәрәләр. Юк, алар аны бетерү яки бүлгәләү ягында түгел. Мөселман бердәмлеге бу әдипләр өчен иң беренче урында тора. Алар мөселман халыклары бердәм булса гына уңышка ирешәчәкләр дип уйлаганнар. Алар нәзарәтнең эшенә демократик рух, сайлау һәм җәмәгатьчелек алдында отчет тоту тәртибен кертергә омтылганнар.

1917 елда ислахчылык нәзарәткә үтеп керә. Дин әһелләре, гомум-мөселман съездларында катнашудан башка, махсус руханилар съездын да үткәрәләр. I Бөтенроссия мөселман съездында мөфтилеккә альтернатив рәвештә сайлаулар үткәрелә. Анда мөхтәрәм дин белгече, абруйлы галим һәм мәгърифәтче Галимҗан хәзрәт Галиев (Баруди) җиңеп чыга.

Бу үзгәреш нәзарәтнең абруен үстерә. Галимҗан хәзрәт исә иң мәшһүр дин эшлеклесе, галим буларак, нәзарәтнең эшчәнлеген фәнни нигезгә кую эшен башлый. Дөрес, аңа әллә ни киң җәелергә мөмкинлек булмый. Большевиклар хакимияткә килгәч, ул алар белән уртак гел табарга тырыша. Бигрәк тә 1921 елгы ачлык вакытында милләтне үлем тырнагыннан саклап калу өчен барлык көчен куя. Үзенең халыкара элемтәләрен дә эшкә җигә. Дөнья мөселманнарының ярдәмен булдыру өчен күп эшләр эшли. Монда ул Татарстан хөкүмәтенә дә нык ярдәм итә. Шул эшләр белән йөргәндә Галимҗан Баруди, үзе дә авырып китеп, 1921 елда Мәскәүдә Боткин шифаханәсендә вафат була.

Татарстан хөкүмәте аның табутын тантаналы рәвештә кайтарып Казанда күмүне оештырмакчы була. Ләкин, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бу эшне тыя. Мөфти хәзрәтне ничек туры килсә шул рәвешле җирлиләр. Гаделлек өчен сөргеннәргә сөрелгән, халык бәхете өчен көрәшкән дин әһеленә Совет властеның рәхмәте менә шундый булды.

Илдә демократик процесслар башланган вакытта мөфти итеп Тәлгать Таҗетдин сайланып куелды. Әнә шул демократизм бүген тирәнәйтелүне сорый. Ни рәвешле? Милли азатлык хәрәкәте колач җәя башлаган дәвердә Диния нәзарәте дә демократик үзгәрешләрдән читтә торып кала алмаячак. Бу үзгәрешләрнең төрлечә булуы мөмкин. Мәсәлән, берәүләр суверен дәүләтләрдә мөстәкыйль Диния нәзарәте булырга тиеш дигән фикерне алга сөрәләр. Икенчеләре — юк, дини берлекне таратырга ярамый, дип саный. «Кем хаклы?» дигән сорауга: «Икесе дә»,— дип җавап бирергә мөмкин.

Ни өчен? Чөнки суверенлык, бәйсезлек өчен көрәшкә дин әһелләренең дә өлешләре керергә тиеш бит. Мөстәкыйль нәзарәт тарафдарлары, әгәр дә Татарстанның үз мөфтие булса, ул мөстәкыйльлек өчен көрәшкә

дин әһелләрен җәлеп итәр иде, диләр. Икенчеләре, моңа җавап итеп, дин әһелләренең актив рәвештә сәясәткә катнашулары, аларның үзара низаглары куеруга китерә, диләр. Әнә Таҗикстанга гына күз салыгыз. Анда дин әһелләре таҗик мөселманнарының төрле төркемнәргә бүленеп үзара сугышуларында катнашалар. Нәтиҗәдә таҗикларның бөтенләе белән бер-берсен кырып бетерүләре мөмкин. Инде анда 100 меңләп кеше үлгән дигән мәгълүматлар бар.

Мондый хәлләр бездә дә булырга мөмкин. Татарлар болай да үзара әллә ни тату яшәмиләр. Моны истән чыгарырга кирәкмәс иде. Әгәр дә дин әһелләре, мөселманнар үзләре Татарстан һәм Башкортстан өчен аерым нәзарәтләр кирәк дип табалар икән, була күрсен. Нигә моңа комачаулык тудырырга? Тик менә мондый бүленү эшләрен үзара аңлашып эшләү мәслихәт. Чехословакия икегә аерылган шикелле, тыныч, дустанә рәвештә аерылу кирәк. Аннан соң Татарстан белән Башкортстаннан гайре республика-өлкәләр дә бар бит әле. Тик, минемчә, мондый аерылышуны тынычрак заманга калдыру яхшырак булыр иде. Ашыкмыйча, дөньялар утыргач та эшләп була бит аны.

Мәгълүм булганча, безнең дин әһелләре арасында низаг килеп чыкты. Аларның бер төркеме, Татарстан һәм Башкортстан өчен аерым нәзарәтләр булдыруны хуп күреп, съездлар җыеп, ике республика өчен дә аерым мөфтиләр сайладылар. Дөрес, ике съездда да, Уфада да, Казанда да җитәрлек кворум — сайланган вәкилләр тулысынча булмаган. Кызганыч, нәзарәт бүлү тыныч рәвештә түгел, куркыту, янау, хәтта көч куллану ысуллары белән барган. Бу турыда матбугатта инде күп язылды.

Мөфти хәзрәт Тәлгать Таҗетдинның җибәргән кайбер хаталары шушы бүленүгә сәбәп итеп файдаланыла. Бөтенләй хатасыз кеше булмый. Мөфти хәзрәт тә адәм баласы. Ләкин Чаллыдагы ямьсез вакыйгалар-

ның кайберләрен булдырмаска мөмкин иде. Ул моны аңласын иде.

Дин әһелләребезнең икенче төркеме исә бу мәсьәләдә тиешле сыгылмалык күрсәтә алмады. Шуңа күрә низаг чыкты. Аны бары тик дин әһелләре тарафыннан оештырылган корылтай гына хәл итә алачак иде.

Уфа шәһәрендә БДБның Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының XI корылтае 1992 елның 9 ноябрендә ачылды. Анда 800 дән артык вәкил катнашып, кабул ителгән карарларның тулы вәкаләтлеген тәэмин итте. Татарстандагы 173 мәхәлләнең 127 се үз вәкилләрен анда җибәргән иде. Башкортстанның 203 мәхәлләсеннән 172 вәкил корылтайда катнашты. Шулай итеп бу гадәттән тыш корылтай закон көчен алды.

Дөрес, төрле шом таратулар да булмады түгел. Мәсәлән, Уфада, Татарстаннан автобусларга утырып боевиклар килә икән, дигән хәбәр таралган иде. Алар башкорт боевиклары белән бергәләп бу съездны өзәчәкләр, имеш.

Аллага шөкер, гамәлдә корылтай тыныч үтте. Чыннан да, безнең халык зирәк бит ул: теләсә кемнең теләсә нинди авантюрасына бирелә торганнардан түгел. Ә бит андый хәл булса, үзара кан коюга барып җитү мөмкин иде. Иншалла, болар булмады.

Корылтай Мәккәдән килгән Нигъмәтулла хәзрәтнең Коръән укуы белән ачылды. Аннан соң мөфти Тәлгать Таҗетдин бер сәгатьлек доклад белән чыкты. Мин аның сүзләрен кабатлап чыгарга җыенмыйм. Тик докладның тирән эчтәлекле һәм бәхәсле булуын гына әйтеп үтәсем килә. Бәхәсле моментларның берсе — Чаллыда һәм кайбер башка урыннарда булган вакыйгаларны тик кемнәрнеңдер явыз нияте аркасында гына килеп чыккан дип аңлатырга тырышу.

Ә бит аларның тирән сәбәпләре бар. Аның иң беренчесе — милләтебезнең буйсынып яшәүдән баш тартып, ирекле һәм лаеклы тормышка омтылуы. Бу, әл-

бәттә, дин тормышында да чагылыш таба. Монда да бит, Мәскәү имамы Равил хәзрәт Гайнетдин кебек, заманча фикер йөртүче, үзгәреп торган дөньяга аек күз белән караучылар шактый. Шуларның берсе мөфти хәзрәт үзе. Нәкъ шуларны күрә һәм аңлый белүе аркасында ул үзенең 12 еллык мөфтилек хезмәтендә зур уңышларга иреште. Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуын бөтен дөньяга шаулатып бәйрәм итә алуы үзе генә дә ни тора. Ә дистәләрчә, хәтта йөзләрчә мәчетләр, мәдрәсәләр төзү дә җиңел эш түгел. Дини тәрбия эшләре гамәлләшеп килә. Тагын бик күп үзгәрешләр турында сөйләп булыр иде. Ләкин без кемгә дә булса мәдхия җырлау эшеннән ерак торабыз.

Корылтай Уфадагы һәм Казандагы съездларны, нәзарәтләрне законсыз дип тапты, Диния нәзарәтенең бүленмәс рәвештә яшәргә тиешлеген хуплап чыкты. Хәзер бу карарларга һәммә дин әһеле буйсынырга тиештер. Чөнки үзен демократ дип санаган һәр кеше демократиянең гомуми принципларына буйсынырга мәҗбүр. Ләкин эшләр әлегә шактый катлаулы. Без киләчәкне дә исәпкә алырга тиешбез. Бүгенге көндә Диния нәзарәтен саклап калу, әлбәттә, милләтебезнең бердәмлеген саклап калуга, аны ныгытуга бер шарт булсын иде, Үзара ызгышуларны булдырмаска иде.

Мин шушы корылтайда ясаган чыгышымда дин әһелләренең үзара дус, тату яши алулары милләтебез өчен үрнәк булсын, дигән фикер әйткән идем. Чыннан да, үзләре тату яши алмаганнар башкаларны шушы татулык юлы белән алып бара алырмы соң? Ә бит заманында дан казанган мөфтиләребез Галимҗан хәзрәт Баруди, Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиновлар дин әһелләрен әнә шул татулыкка өнди килгәннәр, халкыбызның бердәмлеген азатлыкка ирешүнең бер шарты итеп куйганнар. Бер җан, бер тән булуны иң бөек максатларның берсе итеп күргәннәр.

Бу таркалуларның тагын бер куркынычы бар: дин әһелләренең сәясәткә тартылуы. Ә бу исә аларның үзләрен генә түгел, халыкның да төркемнәргә бүленүенә китерә. Хәзерге кайнаган заманда дини, милли бүленештән канлы көрәшкә тик бер генә адым кала.

Безнең динебез һәрвакыт түземлелек, аңлылык мисалы булып килгән. Казан ханлыгында чиркәүләргә дә урын табылган. Халкыбызның холкы да шулай формалашкан, ул беренче булып корал күтәрмәгән.

Әйе, дин әһелләренең низагы артында сәяси уеннар ята. Кемнәрнеңдер безне бер-беребезгә каршы куясы килә. «Бердәм һәм бүленмәс Россия» тарафдарларына бу бик кулай. Безнең үзара бәрелеш юлына басуыбыз алар өчен зур бүләк булыр иде. Минемчә, бүген үзара бәхәсләргә, талашларга урын калдырмаска кирәк. Аңлашып, бер-береңә ихтирам белән эш иткәндә дин оешмаларының төзелешен үзгәртү, аларны камилләштерү бик мөмкин.

Дин әһелләре милләтебезне бердәмлеккә күндереп килсеннәр иде. Үзләре сәясәткә катышмастан, сәясәтчеләргә бердәмлек, әхлаклылык мисалы бирсеннәр иде. Шул ук вакытта сәясәтчеләргә дә дин оешмаларының эшенә тыгылмау яхшырак булыр. Һәркемнең үз эше бар. Һәммәбез бер эшне — милли уяну, бәйсезлек өчен өстебезгә алган вазифаларны намуслы итеп башкарсак иде. Халкыбыз тарихында сирәк була торган кискен борылыш чорында бердәм булыйк. Арабызга ут та кермәсен, су да үтмәсен. Иман безгә көч бирсен, туганнар!

ХАЛКЫБЫЗНЫ БОГАУДА КАЛДЫРМЫЙК!

Соңгы вакытта бездә Россия референдумында актив катнашуга өндәгән сүзләр яңгырый башлады. Әнә «Татарстан хәбәрләре» газетасының актив авторына әверелеп киткән профессор Фидаи Фәткуллин да шушы

фикерне алга сөрә (1993 елның 8 апрель саны). Дөрес, ул бу фикерен бик оста, шома гына үткәрмәкче була. Имештер, Россиядә үткәрелә торган реформалар Татарстанга да китереп сукканлыктан, безнең халыкның да үз фикерен әйтергә «хакы бар». Бу логикага таянып эш итсәң, референдумда Украина, Беларусь һәм БДБның башка дәүләтләре дә катнашырга тиеш була. Чөнки Россиядәге реформалар аларның да һәммәсенә ныклап китереп суга тора. Тик менә безнең профессорның бу фикерен шушы дәүләтләргә ирештереп, аларның халыкларын референдум үткәрергә күндереп булырмы икән?

Ярый, бу кадәресен мәкалә авторы үзе хәл итсен. Без исә Ф. Фәткуллинның нинди максатны күз алдында тотканлыгын ачыкларга тырышып карыйк. Бер карaганда, ул дөрес тә сөйләгән кебек. «Россия Конституциясендә Татарстанны Россиянең бер өлеше (субъекты) итеп караган статьяның конституцион булмавын бастырып әйтер чак җитте»,— дип яза ул. Дөрес, бу сүзләрне аңлавы җиңел түгел түгелен. Ничек инде Конституциядәге статья конституцион булмаска мөмкин?! Болай булгач, «конституцион» төшенчәсен ничек аңларга кирәк икән соң? Ләкин авторның Россиягә үз ниятебезне өздереп әйтү кирәклеге турындагы сүзләре бик яхшы аңлашыла. Тик нәрсәне өздереп әйтергә кирәклеген, «үз ниятебезнең» нинди икәнлеген генә ачыклыйсы кала: сүз Татарстанның Россиянең бер өлеше түгел икәнлеген өздереп әйтүдәме, әллә башка берәр нәрсә турында барамы?

Хәер, монда җавап эзләп баш ватасы да юк. Җавапны автор үзе үк бирә. Ул референдум сорауларына өстәп: «Татарстанның өр-яңа формада — ике яклы, тигез хокуклы килешү нигезендә дәүләт берләшүен саклап калуга сез ризамы?» — дигән сорауны кертүне тәкъдим итә.

Ә сораулар һаман арта: нәрсәне саклап калу ту-

рында сүз алып бара соң безнең юрист? Һәммә кешегә мәгълүм булганча, тик булган нәрсәне генә саклап калып була. Шунлыктан уйга каласың: әллә безнең Россия белән тигез хокуклы договорыбыз бар да, аны тик без генә белмибезме икән? Алай булгач, инде ел ярымга якын вакыт эчендә Россия һәм Татарстан арасында нинди сөйләшүләр бара соң? Бәлки, алар, гомумән, кирәк түгелдер, бу турыда тик безнең Президентыбыз гына белмидер?

Ә бәлки Россия һәм Татарстан арасында башка төрле тигез хокуклы мөнәсәбәтләр урнашкандыр? Бәлки, Ф. Фәткуллин алга сөргән дәүләт берләшүе бардыр? (Ичмасам, дәүләтләр берләшүе дип кенә әйтсә дә, йөрәк бу кадәр әрнемәс иде!)

Дәүләтләр берләшүе чыннан да бар. Аны безнең автор үзе үк таный һәм «конституцион түгел», дип бәяли. Тик шулай булгач, кая соң монда тигез хокуклылык, безне нәрсәне саклап калырга өнди ул?

Аның телгә алынган һәм «Советская Татария» (1993 елның 3 нче март саны) газетасындагы мәкаләсен укыганнан соң, авторның 1918 елның гыйнварында булып үткән III Бөтенроссия Советлар съезды кабул иткән документларга ишарә ясаганын шәйлисең. Әйе, тик шәйлисең генә. Чөнки башкаларның тырнак астыннан кер эзләргә яраткан юристыбыз шул съездны 1918 елның 19 гыйнварында булып үткән, дип яза. Ләкин бу көнне бернинди съезд да булмый. Ул моннан бер көн элек тәмамланган була. Һәм, әйтергә кирәк, ул, Фәткуллин язганча, бер көн түгел, ә тугыз көн дәвам итә.

Моның ише вак-төяккә игътибар да итмәскә мөмкин булыр иде. Ләкин фән белән шөгыльләнгән кешедән төгәллек һәм пөхтәлек таләп ителә. Без дә бу юлы Ф. Фәткуллинны гафу итеп, әлеге III Бөтенроссия Советлар съезды кабул иткән карарларның бары тик ирекле һәм тигез хокуклы федерация яки республика-

лар союзы төзү турындагы декларация яки игълан гына булып калганлыгын бәян итик, Татарстанның Россия составына ни рәвештә кертелгәнлеген искә төшереп үтик. Мин бу очракта Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы турында сүз алып барырга уйламыйм. Укучыларның игътибарын бары тик РСФСРның ВЦИК һәм СНКсы 1920 елның 27 нче маенда кабул иткән Татарстанны төзү турындагы декретка гына җәлеп итмәкче булам.

Татарстан республика буларак үз ирке белән төзелми, аны богаулы һәм ирексез рәвештә әвәлиләр. Менә шушы декретның безне богаулап куйган сүзләре аның беренче статьясында ни рәвешле яңгырый: «Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасын Россия Совет Социалистик Федератив Республикасының өлеше итеп төзергә». Шулай итеп, Татарстан, мөхтәрәм әдибебез Салих Баттал сүзләре белән әйткәнчә, «Россия карынында туа алмый азапланган баланы хәтерләтеп» кала. Туарга тырышып та, инде 73 ел буе туа алмый газап кичерә. Ф. Фәткуллинча, тигез хокуклылык шушы халәтне саклауга кайтып кала. Эш, мәсьәлә башкача хәл ителсә, Россия империя буларак җимерелә, рус халкы коточкыч һәлакәткә юлыга, имеш.

Менә ни өчен без, хөрмәтле укучылар, профессор Ф. Фәткуллинны референдумга өстәмә рәвештә куярга теләгән соравында Татарстанның богавын саклап калырга теләүдән башка берни дә күрә алмыйбыз.

Юк, ят референдумнар белән алдамыйк без халкыбызны. Әгәр дә без үзебезне суверен дәүләт дип таныйбыз икән, монда башкалар алдында бернинди койрык болгауларга да урын калмаска тиеш. Әлеге референдумның өстәмә соравы да, үзе дә кирәк түгел!

Халкыбыз моны белергә тиеш!

БЕЗ КӨРӘШКӘНДӘ БАШКАЛАРГА ҖИҢЕЛРӘК...

Россия референдумы алдыннан анда катнашыргамы, юкмы, катнаша калганда аның сорауларына ничек җавап бирергә, дигән бәхәс газета битләрен тутырган иде. Берәүләр ул референдумның тик Россия референдумы гына икәнлеген күрсәтеп, халыкны анда катнашмаска өндәделәр. Икенчеләре Россияне ялгыз калдырырга кирәк түгел, аның хәле болай да бик авыр бит диеп, анда катнашырга чакырдылар. Инде кайберәүләр хәтта анда үз соравыбыз белән катнашыйк, дип халык башын бутадылар.

Менә референдум үтте. Татарстан халкы үз сүзен анда өздереп әйтте. Бу референдумда безнең бары тик 22,8 процент сайлаучыларыбыз гына катнашты. Калганнары исә Россия эшләренә тыкшынып йөрүгә карағанда үз эшләре белән мәшгуль булуны хуп күрде. Халык хаклы булып чыкты.

Референдум алдыннан, аның нинди нәтиҗә бирүенә дә карамастан, Россиядә тотрыклылык урнашмас, анда тик көрәш кенә кискенләшер, дип фараз кылынган иде. Бу да дөреслеккә туры килде. Мәскәүдә 1 Май көнне капма-каршы сәяси көчләр канлы бәрелешкә кадәр барып җиттеләр. Демонстрантлар, ә алар арасында урам сугышы алып барырдайлар шактый күп булган, күрәсең, ОМОН белән сугыштылар. Мин бу эшләргә битараф булып, йә булмаса, «шул кирәк», дип авыз ерүны һич кенә дә хупламыйм. Ләкин безнең халкыбыз Россия референдумында катнашкан булса, Мәскәүдәге вакыйгаларның иртәгә безгә дә килеп җитүе бик ихтимал иде.

Үзләрен сәясәт үзәгендә кайнаучы дип санаучы кайберәүләр, Татарстан халкының уяулыгын һәм зирәклеген күреп сокланасы, аның сабырлыгын, түземлеген үзләренә үрнәк итеп аласы урынга, референдум нәтиҗәләрен үзләренчә анализларга омтылалар. Алар фи-

керенчә, халыкның референдумда катнашмавы аның куркаклыгына бәйле икән. Югары Советның референдумда катнашырга теләүчеләр өчен бөтен шартларны тудыру турында карар кабул итүе, барлык участокларда комиссияләр төзелеп, тавыш бирү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылуын да алар шулай ук куркыту дип кабул иткәннәр, күрәсең.

Кайберәүләрнең сүзенә караганда, авылларда халыкка референдумга бармаска кушылган. Мин инде болай сөйләүчеләрнең халыкны сарык көтүенә тиңләгәнлеген әйтмим дә. Халык мәнфәгатьләре, аның фикере белән санашмау аларның гадәтенә кергән. Минем монда тик кайбер фактларны гына искә төшереп үтәсем килә. Һәр авыл Советында бөтен төгәллеге белән референдум үткәрү өчен комиссияләр төзелде. Ә инде референдум көнне авыл Советлары бригада авылларына сайлау участокларына килү өчен автобуслар җибәрде. Ә бит референдумда катнашырга теләүчеләр тәпи-тәпи килсәләр дә начар булмас иде. Юк, хөрмәтле укучылар, бу сүзләр минеке түгел. Аны әлеге автобусны бер пассажирсыз килеш авыл Советы карамагына кире кайтарып җибәргән Биектау районының Сасмак авылы кешеләре әйтте («Татарстан» колхозы). Моны белеп торганга демократларның борчылуы көчле дә. Юк, әфәнделәр, башыгызны ватмагыз. Җылы, җиһазланган кабинетларыгыздан чыгып, халыкның арасында йөрегез. Әгәр дә моны референдум алдыннан ук эшләгән булсагыз, сез дә, минем кебек үк, сайлаучыларның утыз процент да артыгы катнашмаячагын чамалый алган булыр идегез. Моны күрәзәләү өчен, йөзләрчә мең сум дәүләт акчасын түгел, социологик тикшеренүләр үткәрү дә кирәк булмас иде.

Бездә, гомумән, социологик тикшеренүләр дигән фән бармы соң ул? Кем ни рәвештә, нинди процент чыгарырга тели, шуны чыгара да куя, шау-гөр килә. Татарстанның кайбер социологлары референдумда 70 про-

центлап кеше катнашачагын күрсәткәннәр иде. Дөрес, Татарстан халык депутаты Иван Грачев бераз тыйнаклык күрсәтте. Ул 50 проценттан артыграк кеше катнашачак, дип язды. Һәм Россия референдумына өметләр баглады. Шуның кадәр халык килсә, Татарстан референдумының нәтиҗәләре юкка чыгачагын фараз кылды. Димәк, безнең демократлар әлеге референдумны Татарстаның статусына кагылган, аны хәл итә торган икенче референдум дип санадылар. Алар фикеренчә, әгәр дә ул бездә үтсә, ягъни анда сайлаучыларның илле процентан артыгы катнашса, республика бернинди суверен дәүләт тә түгел, халыкара хокук субъекты да түгел, ә нәкъ элеккечә гап-гади Россия субъекты булып калырга тиеш иде. Аларның максаты, референдумның Татарстан статусын хәл итәчәгенә өметләнеп, халыкка котгы салырга, аны алдап-йолдап референдумга китерү иде.

Безнең халык явызлыкны тиз оныта, ул ачу саклаучан түгел. Шулай да аны бөтенләй үк хәтерсез дип тә әйтеп булмастыр. Ул әле 1992 елның 21 март референдумы вакытындагы янау-куркытуларны хәтереннән җуеп бетерә алмаган. Ә бит Мәскәү әһелләре Татарстандагы рус гражданнарын, әгәр дә референдум соравына «әйе» дип җавап бирелсә, икенче сортлы кеше булып калуыгыз бар, дип куркытканнар иде. Ләкин Татарстанда яшәгән кешеләр бирердә халыкның гомер бакый сортларга бүленмәгәнен яхшы белә. Гади халык элек тә дус һәм тату иде. Хәзер дә шулай. 1992 елгы референдум да ул хәлне үзгәртмәде. Киресенчә, кешеләрнең бер-берсенә ышанычы арта гына төште. Әгәр дә 1992 елны референдумда катнашучыларның 61 проценты Татарстан мөстәкыйльлеген яклап чыккан булса, быел 71,2 процент сайларга хакы булган кеше Россия референдумында катнашмады. Халык, хөрмәтле «демократларыбыз» тырышлыгы аркасында, бу адымның нәрсәгә бәрабәр икәнлеген яхшы аңлап эш итте.

Референдум нәтиҗәләре, ким дигәндә, ике нәрсәне ачыклый. Аның беренчесе — Татарстанның гадел һәм бөтен кешегә файдалы юл белән суверенитет яулавы — ул халык ихтыяры. Әлегә кадәр ирешелгән ярым-йорты мөстәкыйльлегебез дә халкыбызның яшәү шартларын уңай хәлдә тота. Татарстан 1992 елда күп еллар буе күренмәгән иген уңышы җыеп алды. Аның хәзерге запаслары хуҗаларча тотканда икенче елга да җитәрлек. Базар мөнәсәбәтләренә йомшак керү сәясәте дә үз нәтиҗәләрен бирде. Ул Россиядәге сәясәткә карaганда уңайрак һәм кулайрак булып чыкты. Хәзер Татарстанда социаль яклауның адреслысы, ягъни иң мохтаҗларга юнәлдерелгәне тормышка ашырыла. Гражданнарыбыз моның ни дәрәҗәдә файдалы икәнлеген аңладылар. Референдумда халык шушы сәясәткә ышанычын күрсәтте. Бу аның Татарстан хөкүмәтенә ышаныч белдерүе булды.

Икенче нәтиҗә — Татарстан халкы бернинди котыкка да бирелә торган түгел. Казанның үзәк районнарында кайбер диварларга акбур белән «Здесь — Россия», «Мы в России» дигән сүзләр язылa. Шушыңа халыкның тыныч каравы игътибарны җәлеп итә. Мондый язуларга берәү дә илтифат итми, тавыш куптармый. Яза бирсеннәр, аңа карап хәл үзгәрми диләр, күрәсең.

Ә инде Россия белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, халык шуны белә: Татарстан Россиягә дошман түгел. Татар халкы руслар белән гасырлар буена дустанә мөнәсәбәтләрдә яши. Шушы мөнәсәбәтләрне берәү дә үзгәртергә җыенмый. Моны бездәге руслар да, татарлар да, чувашлар да, марилар да һәм башка милләт вәкилләре дә яхшы белә. Сүз тик кемнең дә булса диктаты астыннан чыгу турында бара. Нигә соң әле бөтен галәм бердәм рәвештә ирек даулаганда, Татарстан гына үзенең азатлыгына омтылмаска тиеш?

Халыкның эчке кичерешләре әнә шул мөстәкыйльлекне хуплый. Берәүнең дә кол булып яшисе килми. Халык һәммә милләтләрнең дә үзара аңлашып гомер итүен тели. Ул шулай ук кеше хокукларын яклаган һәм халыклар дуслыгына гарантия тудырган Татарстан Конституциясен зур ышаныч белән кабул итте.

Әйе, халык үз фикерен әйтте. Әйдәгез, без ул фикерне ихтирам итик. Ни рәвештә?

Бу буш сорау түгел. Чөнки ихтирам итү тик сүздә генә булырга да мөмкин. Ә мондый сүздәге ихтирамнан инде халык туйган. Сүздә халыкның даһилыгына, бөеклегенә, зирәклегенә һәм башка асыл сыйфатларына кемнәр генә дан җырламады? Ә гамәлдә исә аның фикере берәүне дә кызыксындырмады. Безнең бюрократлар фикер әйтергә теләүчеләргә турыдан-туры: «Фикерегезне үзегездә калдырыгыз» дип җавап бирәләр иде. Ләкин инде демократик җәмгыять төзергә уйлыйбыз икән, үзләрен демократ дип санаган кешеләр халык фикере белән исәпләшергә тиешләр. Россия халык депутаты М. Рокицкий матбугатта, референдум алдыннан анда катнашкан кешеләр үзләрен Россия гражданнары итеп таный, һәм, киресенчә, анда катнашмаганнар үзләрен Татарстан гражданы итеп кенә саный, дигән фикер чыгарды. Хөрмәтле профессор бик тә вакытлы кисәтү ясады. Халык моны ишетте һәм сүзен өздереп әйтте. Татарстанда яшәүчеләрнең күпчелеге үзләрен Татарстан гражданнары гына итеп тануларын шушы референдум нәтиҗәләре буенча аңлап була. Димәк, гражданлык турындагы законда аның бу теләге исәпкә алынырга тиеш.

Әлбәттә, Татарстанда Россия белән хушлашырга теләмәгән кешеләр байтак булган кебек, ике гражданлылык ягында торучылар да бардыр. Әйе, ике гражданлык дөньякүләм танылган принцип. Тик мондый гражданлылык төрләрендә аермалык була. Россия законнары үзләре дә аның үз составындагы республика-

ларда ике гражданлылык булуны таный. Лэкин алар республика гражданлыгының Россия гражданлыгына буйсынган булуын гына шарт итеп куялар.

Безнең референдум нәкъ менә шушы принципны кире какты. Әгәр республика халкы Россия референдумын танымаган икән, моннан киләчәк өчен кайбер нәтиҗәләр чыга. Беренчедән, алда мондый референдумнарны үткәрү-үткәрмәү турында карар чыгарып тору файдасыз. Шулай ук Россия Югары Советына депутатлар сайлау да мәслихәт эш булмаячак. Болай булгач, инде ике гражданлылыкның нәрсәсе генә кала диючеләр булыр? Булачак закон моңа бәйнә-бәйнә җавап бирергә тиештер. Ике гражданлылык мәсьәләсе Россия белән төзелгән килешүдә дә ачык чагылырга тиеш. Тик аның республика мөстәкыйльлеген шик астына куюы белән килешеп булмый. Закон моңа урын калдырмасын иде. Гражданлылык турында закон, аның төп принциплары халыкның яшәү рәвешен билгели, аның күп нәрсәгә карата мөнәсәбәтләрен ачыклый. Монда хәрби хезмәт мәсьәләсен аерым билгеләп үтү кирәктер, дип уйлыйм, чөнки Татарстанда Россия армиясенә мәҗбүри чакыру дәвам итә. Югыйсә кабул ителгән Конституциябез моңа каршы җавап та бирә кебек. Анда бит Россия гражданлыгының мәҗбүри түгел икәнлеге ачык язылган. Шулай булгач, безнең яшьләр бу армиягә барыргамы-юкмы икәнлеген үзләре хәл итәргә тиеш. Гражданлылык турында закон моңа тулысынча ачыклык кертер.

Татарстан халкы әлегә хосусыйлаштыруның кая таба барганын да аңлап бетерми. Россия ваучерлары өләшеп, без Татарстан милкен таратып бетермәбезме? Колхоз, совхозларны нәрсә көтә? Фатирлар язмышы ничек булыр? Бу сорауларны законнарның ачыклавы, матбугатның аңлатып бирүе кирәк.

Күптән түгел мин Татарстан делегациясе составында Венгриядә булдым. Бу визит Татарстанның теләсә

кайсы ил белән тигез шартларда эш алып барырга әзер, һәм лаеклы икәнлеген күрсәтте. Ләкин мондый аралашуларның киңәюе Россия белән мөнәсәбәтләргә бәйле икәнлеге һәркемгә билгеле. Шулай да без моңа артык игьтибар итәбез кебек. Чит илләрдә икътисади тәшкиләтләр булдыруда тәвәккәлрәк эшлисе иде. Минемчә, безгә бу өлкәдә Якутия-Сахадан мисал алырга кирәк. Саха инде Япониядә шундый тәшкиләтен булдырды. Ул үзенең җир асты байлыкларын башка илләргә дә чыгара, Көньяк Африка республикасы, Израиль дәүләте белән үзе өчен файдалы уртак эшләр алып бара. «Сез көрәшәсез, без эшлибез, сез көрәшкәндә безгә җиңелрәк»,— диделәр безгә Яңа ел алдыннан махсус чакыру белән Саха республикасында булганда.

Соңгы сүз итеп тагын бер авыр мәсьәләгә тукталасы килә. Ул үзебезнең дәүләт тәшкиләтләрен, яки министрлыклар һәм ведомстволарны тулысы белән Татарстан юрисдикциясенә күчерү мәсьәләсе. Шул ук Саха бу турыда хәтта бәхәсләр дә алып бармый. Ул югары уку йортларын, фәнни учреждениеләрне, хокук яклау органнарын үз юрисдикциясенә күчерүне куеп, бәхәсләшеп тә тормастан, аларны үзе финанслый, мәсьәләләрне үзе хәл итә, димәк, үзенә кирәкчә эшләтә. Эчке эшләр министрын билгеләүне дә үзе хәл итте. Безнең хокук саклау тәшкиләтләре Татарстанны оештыру турындагы 1920 елгы декрет буенча ук республиканың үз юрисдикциясендә иде. Димәк, шуңа әйләнеп кайтырга гына кирәк. Әгәр бу эшләр озакка сузылса, без акрынлап артка чигенгәнебезне сизми дә калырга мөмкин. Ә бу суверенлыгыбызны бөтенләе белән югалтуга китерәчәк.

Халык, Россия референдумына катнашмыйча, үз сүзен әйтте. Хәзер ул сүзне Президенттан, Югары Советтан, хөкүмәттән көтә. Мәскәүдәге сөйләшүләр, Конституцион киңәшмәдә катнашу шушыларны истә тотып алып барылсын иде.

ТҮРДӘ УТЫРУ ФАЙДАГАМЫ?

Укучылар Татарстан җитәкчеләре белән Россия җитәкчеләре очрашкан вакытта Б. Ельцинның түрдә хуҗа булып утыруын телевизордан күреп тордылар. Нишләп ул безнең Президентыбыз каршына утырмаган? Нигә ул аның белән күзгә-күз карашып сөйләшми?

Кызык кына килеп чыга: ике дәүләт җитәкчеләре үзара сөйләшүләр алып бара, ә Б. Ельцин аларның һәммәсеннән дә өстен. Һәр сүзгә тамга салып утыра сыман. Ә бит без, ягъни Татарстан гражданнары, Б. Ельцинны президент итеп сайламадык. Безнең үзебез сайлаган Президентыбыз бар. Шулай булгач, ни өчен Б. Ельцин бу сөйләшү вакытында түрдә утырырга тиеш икән соң?

Әйе, шундый бик күп сораулар биреп булыр иде. Ләкин аларның барысына да җавап бер — Б. Ельцин Татарстанны Россия белән тигез хокуклы дәүләт итеп танымый. Танырга да җыенмый. Ул безнең Президентыбызны да үзенә тиң итеп санамый. Санарга да теләми. Ни өчен? Моңа да җавап бар. Ул Россияне империя рәвешендә саклап калмакчы була. Татарстанны элеге империянең бер колониясе итеп калдырырга тели. Шуңа күрә түрдә утыра да ул хуҗа булып.

М. Горбачев та шулай бердәм һәм бүленмәс империяне саклап калмакчы иде. Ләкин Литвага соңгы баруында аңа өй эше рәвешендә шундый сорау биреп җибәрделәр: «Әйтегезче, Михаил Сергеевич,— диделәр аңа,— «Союз нерушимый республик свободных навеки сплотила великая Русь?» дигән җөмләнең мәгънәсе ничегрәк икән? Мөмкин булса, аның һәр сүзенә аңлатма бирсәгез иде?» Мөхтәрәм М. Горбачев шул сорауларга җавап бирә алмыйча Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗ-

бүр булды. Бәлки, М. Горбачев алдына куелган сорауга бүген Б. Ельцин җавап бирер?

Әйе, Б. Ельцин «бердәм һәм бүленмәс Россия»не саклап калуны үзенә максат итеп куйган. Әнә, ул тәкъдим иткән Конституция проектын гына карагыз, беркемнән дә сорап тормыйча, Татарстанны Россия Федерациясе субъектлары арасына кертеп куйган ич. Империячел сәясәт шулай була инде. Ә бит ул заманында, мин беркайчан да Горбачев җибәргән хаталарны җибәрмәм, дигән иде, Татарстан белән Башкортстанга үзләре теләгәнчә мөстәкыйльлек вәгъдә итте. Әмма Б. Ельцин бу вәгъдәләрен үтәмәде.

Елдан артык дәвам иткән сөйләшүләр нәтиҗәсендә, Татарстан белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләр тигез хокуклылык принципларына нигезләнгән булырга тиеш, дигән фикер ныгыган иде. Әмма бу принциплар үтәләме соң? Безнең яктан алар тулысы белән тормышка ашырылды. Республикабыз Конституциясендә Россия белән Татарстанның мөнәсәбәтләре нәкъ шушы принципларга нигезләнгәнлеге чагылган. Ике яклы килешү проектына да без әлеге принципларга турылыклы маддәләр керттек. Шуңа күрә Татарстан күршесе Россия белән сөйләшүләр алып барганда кемнең дә булса рәислек итүен теләми. Шулай булгач, Б. Ельцин өстәл башында утырырга тиешме? Һич кенә дә тиеш түгел. Безгә яны белән утырмасын иде ул.

Халкыбызның мең елдан артык булган дәүләтчелек тарихы бар. Ул һәр татарның хәтерендә нык саклана. Шуңлыктан ул тарихи гаделлекнең тантана итәчәгенә, бәйсез дәүләтнең аякка басачагына нык ышана. Халкыбызның иреккә, гаделлеккә омтылуының хокукый нигезләре дә бар. Бүген Татарстан үзенең бәйсезлеген торгызу сәясәтендә әнә шуларга таянып эш итә. Бу уңайдан кайбер фикерләремне белдереп китүне кирәк саныйм.

Мәгълүм булганча, Россия үзен Федерация дип са-

ный. Тик ул Федерация күктән иңмәгән бит. 1918 елның гыйнварында аны большевиклар игълан итте. «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе» Россия империясендәге бөтен халыкның тигез хокуклы икәнлеген таныды. Димәк, бу документ кабул ителгәннән соң алар үз язмышларын үзләре хәл итәргә хаклылар. «Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнгән халыклар хокукы декларациясе»нә нигезләнеп, Россия ирекле халыклар союзы итеп игълан ителде.

Алай гына да түгел, Россия Конституциясенә кергән шушы документның соңгы пунктында, республикалар Федерациядә катнашыргамы, катнашкан очракта ни рәвешле катнашырга икәнлеген үзләре билгели алалар, диелгән. Димәк, Россия ирекле Федерация итеп кенә түгел, ә төрле рәвештәге субъектлар керергә мөмкин булган асимметрияле Федерация итеп игълан ителгән.

Татарстан делегациясе бер елдан артык сөйләшүләр дәверендә шушы документларга таянып эш итте. Ниһаять, Россия делегациясе моның дөреслегенә ышанды, чөнки башкача юл юк иде. Әгәр Россияне Федерация итеп игълан иткән документлар бүгенге көнне танылмый икән, димәк, Федерацияне өр-яңадан төзергә кирәк була. Чыннан да, нигә соң әле федератив килешүне Федерацияне тудыручы, аңа нигез ташы салучы документ итеп төземәскә? Югыйсә Россиянең бүгенге федератив килешүе карт атаның балалары арасында төзелгән документны хәтерләтә. Ак сакаллы зирәк ата өстәл башында, ә үз акылларына утырып өлгермәгән сакаллы сабыйлар аннан мәрхәмәт көтеп арырак утыралар сыман. Юк инде, мондый документ белән әллә кая китеп булмас. Чөнки өстәл кырындагы балалар җитлеккән, күптән балигъ булган. Алай гына да түгел, үз балалары, хәтта оныклары да өлгергән. Бүген алар белән башкача сөйләшү таләп ителә.

Татарстан исә үзе белән хокукый нигезгә, Россияне федератив дәүләт итеп игълан иткән документларга таянып сөйләшүне хуп күрә. Ул кемнең дә булса хокукларына кул сузмый. Аның үз хокуклары бар. Ул бары тик шуларны тануны гына дәгъвалый. Тигез хокуклы сөйләшүне генә таный. Аның белән башкача сөйләшергә берәүнең дә хакы юк. 1990 елның 30 августыннан башлап, ул инде шушы юлга турылыклы булып килә. Аны куркытып та карадылар, янадылар да. Ләкин ул курыкмады. Курыкмас та дип ышанырга кирәк. Әмма төрлечә куркытулар, янаулар хәзер дә дәвам итә. «Бердәм һәм бүленмәс Россия» тарафдарлары Татарстанның үзендә дә юк түгел. Алар хокук саклау органнарына үтеп кереп, гаделлек яклыларны әзәрлеклиләр. Моңа да чик куелыр дип ышанабыз. Шикләнмәсеннәр бәгъзе әфәнделәр, безне куркытып булмас. Безнең халык тыныч, ләкин бирешә торганнардан түгел. Без кем өстеннән булса да өстенлек эзләмибез. Ләкин үзебез белән сөйләшкәндә, йөзгә-йөз карашып сөйләшергә кирәк, дип саныйбыз. Шулай булгач, Б. Ельцин өстәл башында хуҗа булып утырырга тиеш түгел.

Ә утыруын дәвам итсә? Бу һич кенә дә урынсыз сорау түгел. Чөнки, күргәнебезчә, ул әле шулай утыруын дәвам итә һәм өстәл башыннан төшәргә җыенмый да кебек. Бу очракта мин Россия Конституциясе проектларын истә тотам. Бик кызык хәл килеп чыга: Россия Югары Советы тарафыннан төзелгән комиссиясенең рәисе Борис Николаевич Ельцин үзе. Инде тагын бер вариант — Президент проекты дип аталганы алга сөрелә. Бер-берсе белән ике проект сугыша. Әмма икесенең дә рәисе — Б. Ельцин. Моны ничек аңларга кирәк икән?

Билгеле булганча, Ельцин белән Горбачев «сөзешә» башлаган вакытларда, халык депутатлары съезды Борис Николаевичны яклап чыкты һәм Югары Совет Рәи-

се итеп сайлады, демократик хәрәкәт аны үзенең байрагына әверелдерелде. Ләкин, Б. Ельцин Президент булып сайлангач, аның яңа тарафдарлары барлыкка килде. Г. Бурбулис командасы Р. Хасбулатов командасы белән сыешып яши алмады. Шунлыктан Б. Ельцин үзе җитәкчелек иткән Конституция комиссиясеннән читләште. Р. Хасбулатов белән О. Румянцев эшне Б. Ельцин командасындагы кешеләрдән үзгәрәк алып бардылар.

Б. Ельцинның яңа командасы, яңа проект төзеп, аны Россия Конституциясенең Югары Совет тарафыннан төзелгән проектына каршы куйды. Әмма бүген күп кенә экспертлар бу проектлар арасында әллә ни аерма юклыгын күрсәтәләр. Әмма көрәш дәвам итә. Җирле советларның күпчелеге Югары Совет проектын, җирле администрация Президент проектын яклый. Ләкин проектларның берсе дә Б. Ельцинны өстәл башыннан төшәргә өндәми. Аларның икесе дә Россияне «бердәм һәм бүленмәс» итеп күрә. Ә бит Россия составындагы республикаларның күпчелеге үзләре өчен өстән билгеләнгән хокукларга риза түгел. Ике проект буенча да алар суверенлыкларын югалталар. Ике проект буенча да республикалар, крайлар һәм өлкәләр аталары табын тирәсенә җыйган балаларны хәтерләтәләр. Инде шулай икән, Б. Ельцин һаман да өстәл башында утырачак булып чыга. Ә бит моңа хәтта өлкәләр дә риза түгел. Алар да үзләренә хокук даулыйлар. Алар, ни өчен республикалар зур хокукларга ия дә, без хокуксыз, диләр. Сүзләрендә дөреслек юк түгел һәм менә ни өчен — алар чын мәгънәсендә Мәскәүдән идарә ителәләр. Байлыкларына Мәскәү чиновниклары хуҗа. Әнә, күршебез Самара өлкәсенә генә күз салыйк. Ул да, Татарстан кебек, элеккеге хисап белән санаганда 3—4 миллиард сум акчаны бернинди компенсациясез үзәккә күчереп бара. Самараның үзендә иркенләп сатып алырлык сөт тә булмый килде. Әлбәттә, Самара өлкә-

се моңа риза түгел. Ул гынамы соң, башкалар да ризасызлык белдерәләр. Вологда өлкәсе дә үзенең суверенлыгын игълан итте. Себер өлкәләрен әйтеп тә торасы юк. Күрәсез, өлкәләрнең сүзләрендә дөреслек һәм гаделлек бар. Ләкин бу тулы дөреслек түгел. Чөнки республикаларның да бернинди хокуклары юк бит. Яңа Конституция кабул ителгән очракта, алар элеккечә Россия провинциясе булып калуларын дәвам итәчәкләр.

1917 елда, инде үзенең соңгы көннәрендә, Вакытлы хөкүмәт: Россия децентрализацияләнгән булырга тиеш, дип белдерде. Алай гына да түгел, хәтта «бердәм һәм бүленмәс Россия» идеясен нигезләүче П. Милюков та, безнә әнә шул идея харап итте, дияргә мәҗбүр булды. Димәк, рәис өстәле башында утыруны тик килешү нигезендә генә аклап була.

Бүген Ленинга мөрәҗәгать итү модада түгел. Ләкин мин аның дөрес һәм гадел фикерләреннән берсен искә төшереп китүне кирәк саныйм. Бердәмлек ирешмәслек нәрсә түгел, ул булырга мөмкин, тик аңа ирешү бары килешү юлы белән генә эшләнергә тиеш, дигән иде ул. Бүген дә шундый хәл күзәтелә. Россия бердәм була ала. Ләкин моңа ирешү өчен аңлашу һәм килешү кирәк. Әгәр дә кайбер республикалар Федерациягә керергә теләмиләр икән, үз ирекләре. Кайсыларыдыр аңа өлешчә генә керергә тели икән, монысын да тик үзләре генә хәл итәргә тиеш. Бу аларның Россияне Федерация дип игълан иткән вакытта танылган хокуклары.

М. Горбачевка табышмак итеп әйтелгән СССР гимны сүзләрен мин инде китергән идем. Анда да республикаларның ирекле икәнлекләре әйтелгән. Әмма бүген СССР юк, ул турыда сөйләп тору кирәк түгел, диючеләр булыр. Анысы да дөрес. Тик шуны онытмаска кирәк, СССР ул Россиянең яшәү рәвеше генә иде. Аңа

кадәр империя РСФСР исеме белән яшәде. Ә чынлыкта бу — шул ук империя.

Хәзер дә бер нәрсә игътибарны җәлеп итә. 1922 елда СССР үзен Россия Федерациясенең варисы рәвешендә дөньяга таныта. Бу чыннан да шулай. Варис буларак, ул республикаларның РСФСР Конституциясендәге суверен хокукларын, аларның Союздан чыгарга хокуклы икәнлекләрен үз Конституциясенә дә язып куя. Варис икән, ул хокук өлкәсендәге барлык нәрсәләргә дә варис булырга тиеш бит. Башкача булырга мөмкин түгел. Әгәр дә син варис икәнсең, аның бөтен барлыгын үзеңә ал, инде син кирәкләрен генә алып, кирәкмәгәннәрен чыгарып ташлый алмыйсың. Шулай булгач, Россия Конституциясенә иреклелек, тигез хокуклылык принциплары бернинди икеләнүсез язылырга тиеш. Башкача булса, Россиянең киләчәге юк. Ул бердәм дәүләт буларак яшәүдән туктаячак.

Әгәр инде бүгенге Россия шушы принципларны танып, аларны үз Конституциясенә кертсә, ул вакытта Россиянең торгызылуына, аның яңа рәвештәге демократик дәүләт булуына өмет кала. Әгәр дә шушы принциплар кабул ителмичә, Россиядәге республикалар ирексез булып кала икән, бу төрмә озак яши алмас. Аның бөтенләй чәлпәрәмә килүе бар.

Россиядәге хәлләр турында сүз алып барганда, дөньяда барган процессларны исәпкә алмау зур хата булыр иде. Шунлыктан Федерациянең язмышына дөнья күләмендә күз ташлау кирәктер. Әйтик, Югославия Федератив дәүләт буларак юкка чыкты һәм ул инде элеккечә һичкайчан аякка баса алмаячак. Ни өчен? Чөнки бу дәүләттә хаким булган серб милләте үзен чын мәгънәсендә зирәк һәм олы ага итеп күрсәтә алмады, һәммә җирдә кан коелуга сәбәпче булды. Чехословакия дә федератив дәүләт буларак юкка чыкты. Ләкин аның кайчан да булса теге яки бу ысулда берләшүе мөмкин. Чөнки бу ике халык, ягъни чехлар бе-

лән словаклар аерылышуның иң матур алымын сайладылар, бер-берсенә изге теләктә булып аерылыштылар. Канада да федерация буларак таркалу юлында. Күпчелекне французлар тәшкил иткән Квебек провинциясе аның составыннан аерылып чыгу юлларын эзли. Күргәнегезчә, хөрмәтле укучылар, бар җирдә дә федерацияләр бетүгә таба бара. Россия дә бу төп юнәлештән читтә кала алмаячак. Минемчә, аның бер өлеше федератив (бусы Россиянең үз регионнарына кагыла), икенчеләре конфедератив рәвештә яшәүгә йөз тотар. Күпмедер вакыт шушы процессларның үзләренә юл сала алмый азаплануы ихтимал. Ләкин шунысы ачык, бу тенденцияне берничек тә туктатып булмас.

«Милләтләрнең Британия бердәмлеге» дигән дәүләтләр оешмасы бар. Россияне шул рәвештә үзгәртергә мөмкин. Әгәр бу юл Россия өчен, чыннан да, кулай була икән, ул яшәячәк. Ләкин өстәл башында рәислек итеп утыру тик килешү нигезендә генә булырга мөмкин. Менә шуны бүгенге Россия җитәкчеләре аңласа икән. Әгәр дә Борис Ельцин, өстәл башыннан чыгып, башкалар каршына килеп утырса, бу процессның алга баруы өчен иң кулай шартлар барлыкка килер иде. Россиядә әле барысы да булуы мөмкин. Югославиядән дә дәһшәтлерәк канлы сугыш килеп чыгыу да, Чехословакиядәге кебек, кыска вакытка аерылышу процесслары да булуы мөмкин.

Татарстан белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләр кемнәр өчендер өлге була алыр иде, Татарстан һич тә Россияне таркатырга җыенмый. Киресенчә, әгәр бу ике республика үзара дустанә һәм тигез хокуклы мөнәсәбәтләр урнаштыра алалар икән, бу башка республикаларга һәм халыкларга да яхшы мисал булыр. Россия Конституциясе әнә шул юнәлештә камилләшсен иде. Бу — заман таләбе.

БЕЗ БЕРДӘМ, БӘХЕТЛЕ МИЛЛӘТ БУЛЫРГА ТИЕШ

(Әңгәмә)

— Индус әфәнде, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты 1992 елда оешты. Бу, әлбәттә, күп вакыт түгел, шулай да яңа структураның кирәкме-юкмы икәнлеген ачыкларга мөмкиндер бит?

— Ул бик кирәк һәм узып киткән ел моны бөтен тулылыгы белән исбатлады. Язмыш борынгы татар халкын бөтен дөнья буйлап «сипте». Миллионлаган кеше бүген тарихи тамырларыннан читтә яши, милли мәдәният казанышларына һәм ана теленә сусап яши. Алар һәммәсе Татарстанга рухи Ватан итеп карыйлар. Туган йорт белән элемтә урнаштырырга һәм аны ныгытырга омтылалар. Конгресс әлеге омтылышларның никадәр көчле һәм эчкерсез булуын күрсәтте, ә аннан соңгы вакыт аларның тотрыклы һәм дәвамлы икәнлекләренә инандырды. Дөньяның кайсы да булса почмагыннан татар милләте вәкилләре килмәгән көн юк: кичә, мәсәлән, мин Ерак Көнчыгыш татарлары белән очраштым, бүген — Омск һәм Киевныкылар белән Ерактагы һәм якындагы кардәшләр белән элемтә тоту, Конгресс билгеләгән бурычларны — консолидация һәм милли яңарыш мәсьәләләрен хәл итү өчен яши БТК Башкарма комитеты, ул шул максаттан оешты.

— Һиндидер сер ачам, дип әйтүем түгел, әмма сезнең эшчәнлекне бертавыштан хуплап каршыламадылар бит. Башкарма комитетның, беренчедән, хокукый нигезе юк, икенчедән, ул бөтендөнья татарлары исеменнән сөйләрлек вәкаләтле түгел, өченчедән, гомумән, «кесә» оешмасы дигән фикерләр йөрде. Сез бу уңайдан ни диярсез?

— Безнең законлылык берничек тә шик астына алына алмый. Башкарма комитет — даими рәвештә эшләп килүче, БТК тарафыннан төзелгән эшче орган.

Яхшы эшлибезме, начармы — анысы икенче мәсьәлә. Конгресс кабат җыелгач, хисап тотарбыз. Вәкаләт, вәкилләр мәсьәләсенә килсәк, Конгресс татар тарихында моңарчы күрелмәгән форум булды: анда Рәсәйнең төрле төбәкләреннән, элеккеге союздаш республикалардан, Финляндиядән, АКШтан килгән милләттәшләребез катнашты. Башкарма комитеттагы утыз өч әгъзаның унөче — Татарстаннан читтә яшәүче татарлар вәкиле.

Ә «кесә» турында сөйләп тору да көлке. Хөкүмәт телгә алып әйтерлек матди ярдәм күрсәтсә, рәхәтләнеп кереп урнашырлык бина бирсә иде. Кызганычка каршы, болар берсе дә юк. Булган очракта да бу безнең кайсыдыр ки «кесә»дә утыруыбызга түгел, хакимиятнең Президент Указы нигезендә чакырылган Конгресс ихтыяры белән санлашуына шәһадәт итәр иде. Башкарма комитет әгъзалары арасында югары урыннар биләүче, шул исәптән хөкүмәттә җаваплы вазифа үтәүчеләр булуны мин үзем, гәрчә безне кайчак нәкъ менә шуның өчен гаеп итсәләр дә, уңай күренеш дип бәялим. Бөтен шикләрне читкә куеп, төптәнрәк уйлап карасаң, милли-мәдәни мәсьәләләрне хәл итү безнең хезмәт вазифасына ук кергән, моның өчен тиешле белеме һәм вәкаләте булган кешеләрне тарту файдага гына бит. Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче кардәшләр алдына килеп баскан зур һәм кечерәк күләмдәге мәсьәләләрнең күбесен без үз көчебез белән чишә алабыз. Һәм, әлбәттә, чишелеше җәмәгать оешмаларының берсенең дә кулыннан килмәстәй мәсьәләләр дә бар. Союз таркалганнан соң килеп туган качаклар проблемасы, мәсәлән. Хәзер менә Чаллыда хәлләр катлауланды, йортсыз-җирсез бик күп кеше кайтып тупланды анда. Аларга ничек булышырга? Билгеле, шәһәрнең торак фонды хисабыннан түгел. Бу юл җирле халык белән күченеп кайтучыларны пычакка-пычак китерер иде. Димәк, башка юллар, башка мөмкинлек-

ләр эзләмичә булмый. Шуларның берсе: безгә Уралдан агач һәм әзер йортлар тәкъдим итәләр. Түләп алу өчен акча кирәк, нигез кору өчен урынын билгеләргә кирәк һ. б.— ягъни тагын хөкүмәткә таянасы, ансыз эш барып чыкмый. Шуңа күрә без хөкүмәт белән хезмәттәшлек итәбез, алга таба да шулай булачак. Башкача була да алмый: ул бит каяндыр ташланган десант түгел, безнең үз хөкүмәтебез.

Хакимият белән аралары ал да гөл икән, һичнинди каршылыклар юк икән, дигән сүз түгел әле бу. Башкарма комитетның сәяси карашлары радикальрәк. Без, мәсәлән, хокук саклау органнарын кичекмәстән Татарстан юрисдикциясенә күчерү ягында, ә Югары Совет әлеге мәсьәләне тикшерү юлында дип тә әйтеп булмый хәтта. Без Татарстан Республикасында Рәсәй референдумын уздыруга да каршы идек. Референдум нәтиҗәләре — анда халыкның дүрттән бер өлешеннән дә азрак катнашуы, минем уемча, хаклы булуыбызны раслады.

— Сезнең оешма төзелгәнче милли хәрәкәттә ТИҮ, «Иттифак», «Ватан» җәмгыяте актив эш итәләр иде. Алар арасында үз урыныгыз табылдымы? Үзара мөнәсәбәтләрегез нинди?

— Мөнәсәбәтләр әйбәт, тулы аңлашуга нигезләнгән. Максатыбыз бер бит — милләтне торгызу. Эш һәммәбезгә җитәрлек. Билгеле, һәркайсыбызның үз юнәлеше. Безнең эшчәнлекнең төп юнәлешләре Конгресс документларында һәм Башкарма комитет Уставында билгеләнгән. Алар — этно-региональ мәсьәләләрне хәл итүдә, республикадан читтә яшәүче татарларның рухи мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүдә арадашчылык итү; тел, фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәләрен үстерү максатыннан киң колачлы программалар төзү һәм аларны тормышка ашыру; дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать оешмалары өчен эксперт тикшеренүләре, аналитик тикшеренүләр уздыру, гамәли тәкъдимнәр әзерләү; та-

тарлар яши торган төбәкләрдә социаль информация җыю һәм тарату, шундагы массакүләм информация чаралары белән элемтә булдыру; татар диаспорасы, рәсми булмаган халыкара оешмалар белән даими хезмәттәшлектә тору.

Башкарма комитет урамга чыгып шаулап йөрүләр, митинглар ясау белән мавыкмый. Без милләтнең зыялы өлеше белән эш итәргә тырышабыз, үз аудиториябез каршына милли яңарыш мәсьәләсенә төптәнрәк карау бурычын куябыз. Һәм ул мәсьәләне халыкка һәрьяклап уйланган, фәнни яктан өйрәнелгән хәлдә куярга омтылабыз.

— «Милли мәсьәлә», «яңарыш», «рух», «рухи» сүзләре бик еш кабатланса да, бик хисле яңгыраса да, анык кына төшенчәләр түгел. Сез аларга нинди мәгънә саласыз?

— Дөрестән дә, элеге сүзләр кирәк очракта да, кирәкмәгәндә дә кулланыла. Мондый «мода» иң элек аларның үзләренә зыян сала.

Милли мәсьәлә дигәнебез һәр халыкта үзенчә була. Татарлар өчен бу — милләт буларак сакланып калу, аны заманыбыз казанышлары нигезендә үстерү һәм шул ук вакытта үз йөзебезне, үз сыйфатларыбызны югалтмау.

Минемчә, нәкъ менә хәзер татар милләтенең икенче күтәрелеше башланды. Безнең бурыч — элеге тенденцияне мөмкин кадәр тулырак итеп тормышка ашыру хисабына хезмәт кую.

Инде рухи якка кагылсак, анысы әхлагыбыз белән бәйле. Рухи яңарыш ул — тулысынча яки беркадәр югалган кыйммәтләребезне, халыкның милли холкындагы асыл сыйфатларны кире кайтару, кешенең кешелеген бетерүче, безгә читтән килеп сырышкан эчкечелек, эшлексезлек, ялкаулык, вөҗдансызлык, намуссызлык кебек кимчелекләрдән арыну дигән сүз. Элек боларны социалистик әхлак дошманнары дип йөрттеләр.

Алар — теләсә кайсы әхлакның, рухның дошманнары. Әхлакый сафлану халыкның культурасын арттыруга хезмәт итә һәм, киресенчә, югары культура аерым шәхесне дә, тулы бер халыкны да рухи баета. Бу — аерылгысыз диалектик бергәлек.

— Безнең мескен илебездә ничектер шулай килеп чыга инде: милли яңарыш артында күләгә булып дошман образы калка. Бер полюста бу «жидомасоннар», «татар-монголлар» һ. б., икенчесендә — «урыс колонизаторлары», «шовинистлар». Нәрсәдер *өчен* **берләшү бездә азыр бара, ә менә нәрсәгәдер каршы — бик җиңел.**

— Мин үзем «өчен» яклы. Татарларның уртак тарихи тамырларга, уртак мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә нигезләнеп берләшү уе бер генә халыкның да мәнфәгатьләренә каршы төшми. Анда милли өстенлек, үзен кемнәргәдер каршы кую дигән нәрсәләрнең төсмере дә юк. Без өстенлек дауламыйбыз, безгә тигезлек, чын тигезлек кирәк. Һәр кеше үзен үз милләте кысаларында кеше итеп санасын, кимлек, юксыллык тоймасын. Әлегә бу юк. Тормышта нәрсәгәдер ирешү өчен, хәтта гап-гади генә итеп яшәү өчен дә, татар ике тел белергә тиеш, урыска үзенеке дә җитә. Татарның наданлыгын, культурасыз булуын күрсәтәселәре килсә, «ул урыс телен дә белми бит...» диләр. Нигәдер берәү дә урыс кешесен «ул татарча да белми ләбаса» дип мыскылламый. Әгәр бер халык икенчесенең телен, мәдәниятен танымый, гореф-гадәтләреннән көлә (кычкырып түгел, астыртын гына, әмма барыбер ишетелә) икән, нинди тигезлек турында сүз булуы мөмкин?

Моңа кем гаепле? Җаваплылыкны янәшәбездә яшәүче гади урыс халкына сала алмыйм. Һәм, гомумән, әлеге классик «урыс соравын» төшереп калдырып, икенчесенә тотыну яхшырак булыр: «Нәрсә эшләргә?» Без нәрсәдер эшли башладык инде. Татар теле дәүләт теле дип игълан ителде. Әмма бүгенге көндә бу декла-

рация булудан узмый. Аны чынбарлык итү өчен Татарстанда яшәүче һәркемнең шуны аңлавы зарур. Татар теле бәлагә тарыды. Аны бәладән йолып алу өчен бергәләп көрәшү кирәк. Мин бу мәсьәләдә дә килешү яклы. Бүген миңа кайгы килсә, иртәгә сиңа килүе бар. Урыс мәдәнияте кыен хәлдә калса да бергәләп көрәшербез. Әлегә татар теле аерым яклауга һәм аерым өстенлекләргә мохтаҗ. Тәрҗемәчеләр әзерләү, эш кәгазьләрен татарчалаштыру, иң әһәмиятлесе — республиканың һәрбер гражданына татар телен өйрәтү зур чыгымнар сорый. Мин һәрбер кешене, дим. Чөнки башкача булганда халыкның татарча белмәүче өлеше кимлек хисе кичерәчәк. Ике теллелеккә чын-чынлап күчкәннән соң үпкә-сыктауларның күбесе үзеннән-үзе бетәчәк, аңлашылмаучылык туар җирлек калмаячак.

— Татар милләтен һәм аның киләчәген идеалда ничек итеп күрәсез?

— Идеал — нурга чумган тау түбәсе кебегрәк бит ул. Тау итәгеннән торып шәйләп тә бетереп булмый аны. Әйдәгез, бүген якынрак киләчәк турында сөйләшик. Иң элек бердәмлек кирәк. Кайда гына булмасын, татар үзен үз халкының бер кисәге итеп сизсен, читтәлеген тоймасын, милли мәдәният казанышларыннан файдалана һәм мәдәнияткә үз өлешен кертә алсын. Аннан ары — татар милләте үз цивилизациясен төзәрлек гыйлемле, культуралы милләт булырга тиеш. Беренче карашка гына сәер яңгырый бу. Ә бит бүгенге, безне дә үзенә кушкан цивилизация ниндидер хәрәкәтсез, катып калган чынбарлык түгел. Һәр халыкның һәр буыны теге яки бу күләмдә аның казанышларын үзләштерә, эчтәлеген үзгәртә, баета, үзеннән өстәмәләр кертә. Дөнья җәмәгатьчелегенең бер өлеше буларак, без, татарлар, үзебезне көнчыгыш халкы дип санныйбыз. Көнчыгыш цивилизациясен ни дәрәҗәдә үзләштергән без? Әлегә кадәрге бәйланышларыбыз көчле иде, дип әйтә алмыйбыз. Без бит әле көнчыгыш халкы-

ның иң көнбатыштагысы да. Без үз цивилизациябезне үзебезнең геосәяси хәлебездән чыгып корырга тиеш. Моның нигезе — икътисади һәм мәдәни яктан нык үскән суверен Татарстан!

— Башкарма комитетның гамәлдәге эшләре турында сөйләгезче?

— Мин инде дөнья буйлап чәчелгән милләтебезнең барча төркемнәре белән даими контактларны ныгытуга зур әһәмият бирүебезне әйткән идем. Безгә вәкилләр килә, без иҗат төркемнәре оештырып җибәреп торабыз. Контактлар, гәрчә кешеләргә шатлык-куаныч бирсәләр дә, үзмаксат түгел. Иң мөһиме — алар милләттәшләребезне «барларга» мөмкинлек тудыралар.

Кан кардәшләргә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Чиләбе өлкәсендәге татар авыллары, мәсәлән, экологик һәлакәт зонасына эләгеп, бәлагә юлыктылар. Шундагы хәлне җентекләп тикшереп, тәкъдимнәр әзерләп өлкә хакимиятенә, ул гына булышмаса, Рәсәйнекенә мөрәҗәгать итәргә җыенабыз. Хәрби промышленность комплексының химик корал эшләп чыгаруга кагылышлы караңгы серләрен фаш иткән Мәскәү галиме Вил Мирзаянов «эше»н тикшерүдәге кискен борылыш безнең катнашуыбыз аркасындарак мөмкин булды, дип сөенеп әйтә алабыз. Шушы көннәрдә генә миңа, Мәскәү администрациясе Әсәдуллаев йортын киредән татар җәмгыятенә кайтарырга ниятли, дип ышандырып хәбәр иттеләр. Әлеге йорт аны җәмгыятькә бүләк итеп биргән сәүдәгәр фамилиясе белән атап йөртелә. Йорт инкыйлабка кадәр бүләк ителгән булган, ә совет чорында аны җәмгыятьтән алганнар. Йортны хуҗаларына кире кайтару уе белән моннан берничә ел элек йөри башлаганнар. Хәзер мәсьәлә хакыйкый чишелешенә якынаеп килә.

Татар мәктәпләре, балалар бакчалары ачуга да булышлык итәбез. Саратов үзәгендәге мәктәпләрнең берсе татар гимназиясе итеп үзгәртелде. Хәзер аны ки-

җәйтергә кирәк. Гимназиядә укырга теләүчеләр бик күп, кабул итү конкурс нигезендә алып барыла. Гомумән, милли мәктәпләр, клублар, китапханәләр ачу, газитләр чыгару мәсьәләләре комплекслы хәл ителергә тиеш тә бит, тик милли районнар турында Рәсәй законы булмау эшкә зур комачаулык тудыра. Закон кабул ителү белән татар районнарының этно-мәдәни үсешенә кагылышлы махсус комплекслы программа проектларын тәкъдим итәчәкбез, алар әзер инде. Ә хәзергә программаларны өлешчә тормышка ашыру юлыннан барабыз. Татар мәдәнияте һәм сәнгате әһелләре даими рәвештә татарлар күпләп төпләнгән төбәкләргә барып чыгыш ясыйлар.

— Боларның һәммәсенә акча кайдан табыла?

Башкарма комитетның үз фонды бар. Республикабыздагы күп кенә эре предприятие һәм оешмалар — «Татнефть», «Татглавснаб», «Нижнекамскнефтехим» һ. б. аның исәбенә иганә акчасы күчерделәр. Без бу акчаларны тотмадык, әйләнешкә җибәрдек. Налог сәясәтендә тәртип урнашкач, зур булмаган күләмдә җитештерү эше белән шөгыльләнә башларга ниятлибез. Милли көнкүрешкә, милли киемнәргә кагылышлы фикерләр бар. Урбанизациянең тискәре якларына, тормышның стандартлашуына ничек тә булса каршы төшәсе иде бит. Элгәре халык, артык бай яшәмәсә дә, тормышын үзенчәлекле итеп кора белгән. Менә шул үзенчәлекләрне кире кайтара алсак, күп милләтле Идел-йорт тормышы балкыбрак, яктырыбрак китәр иде.

— Әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт, Индус әфәнде. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты татар милләтенең этно-мәдәни үсеше өчен игелекле эшләрне әле күп эшләячәк, дип өметләнеп калабыз.

Әңгәмәне Римма Гурьянова үткәрде.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз 3

Татар милләтендә яшәү көче бармы?

Татар нинди милләт? 7
Милләтебезгә хас төп сыйфатлар 25
Татар кем җирендә яши? 51
Алтын Урда: миф һәм чынбарлык 60

Көрәшчеләребезне искә төшерик!

Парижда укыган Садри Максуди 71
Бигиевләрнең икенчесе 82
Гаяз Исхакый һәм татар тарихы 92
Мөфти хәзрәт Галимҗан Галиев (Баруди) 102
Азатлык каһарманы 111

Бәйсезлеккә ничек ирешергә?

Азатлык безгә барыбер киләчәк! 119
Курчак автономиядән — бәйсезлеккә 142
Федерация булганмы, бармы, булачакмы? 150
Россиядә яңа милли сәясәт бармы? 159
Россия нинди юлдан китәр? 168
Әллә шатланырга, әллә офтанырга? 178
Аңлап эш итү мәслихәт 189
Төп Законыбызны якларга тиешбез 194
Соңгы сүз — халыкныкы 202
Өлкән һәм кече суверенлык буламы? 212
Тишковка ни җитми? 223
Бәйсезлекнең берничә шарты 227
Милләтнең бердәмлеге — төп шарт 236
Дин һәм бәйсезлек 244
Халкыбызны богауда калдырмыйк! 252
Без көрәшкәндә башкаларга җиңелрәк... 256
Түрдә утыру файдагамы? 263
Без бердәм, бәхетле милләт булырга тиеш 271

Тагиров Индус Ризакович

СТУПЕНИ НЕЗАВИСИМОСТИ

(на татарском языке)

Мөхәррире *С. Шәмси*
Рәссамы *Г. Мартынова*
Бизәлеш редакторы *Д. Җәләлетдинов*
Техник редакторы *Ф. Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *З. Даутова, М. Хәйруллина*

ИБ № 6500

Җыярга тапшырылды 29.11.93. Басарга кул куелды 18.04.94. Форматы 70×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 2. Гарнитурасы «Литературная». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 12,25. Шартлы буяу-оттиск 12,60. Нәшер-хисап табагы 12,64. Тиражы 3000 экз. Заказ П-300.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе. 420111. Казан, Бауман ур., 19.



Индус Ризак улы Таһиров 1936 елны Шөгер районы (хәзерге Лениногорск районы) Иске Шөгер авылында туа. 1955 елны Әлмәт шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлый.

1958—1963 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, соңыннан шунда ук аспирантурада кала, Казанда совет власте урнашуның үзенчәлекләре турында диссертация язып, аны 1967 елда яклый һәм тарих фәннәре кандидаты исемен ала.

1979 елны яклаганган докторлык диссертациясе 1917—1918 елларда Идел-Урал төбәгендә барган милли-азатлык хәрәкәтенә багышлана. Хәзерге көндә ул Казан дәүләт университетында кафедра мөдире, тарих факультеты деканы вазыйфаларын башкара.

И. Таһиров республикабыз җәмәгатьчелегенә танылган галим сыйфатында гына түгел, иҗтимагый хәрәкәттә актив катнашучы кайнар публицист, Татарстан белән Россия арасында сөйләшүләр алып баручы дәүләт делегациясенең даими әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе буларак та билгеле.